Сүз уңаеннан. Әтиебезнең кушаматы «Чудикән Габдулласы» иде. Без кечкенә чакта ул: «Чү, улым!»,– дигән гыйбарәне еш куллана торган иде, мин ул кушаматны шуңа бәйле рәвештә тугандыр дип уйлап йөри идем. Әмма чагыштырмача күптән түгел генә күрше урамда яшәүче Нурсинә әби Хуҗина кызык бер факт бәян итте. Ачлык елларда Америкадан гуманитар ярдәм килгәч, авыл халкын җыеп ашаткан чакта минем эти дә шунда булган (аңа ул вакытта 12 яшьләр чамасы булгандыр инде). Шул ризыкларны кабалана-кабалана ашаганда үзе бертуктаусыз: «Чуды икән бу, чуды икән»,– дип кабатлый икән. Кушамат менә ничек туган булып чыкты...

Гайфулла хаҗиның оныккае Габделбәр Барый улы Сәетгәрәев нефть чыгару мастеры, 7 нче чакырылыш СССР Югары Советы депутаты буларак, ике тапкыр Мәскәү Кремле мөнбәреннән чыгыш ясый. Ике «Почёт билгесе» ордены, «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнә. Кырыктан артык зур-зур рационализаторлык тәкъдимнәре эшләп, үз куллары белән гамәлгә ашыра. Мәскәүдә күп кенә атаклы шәхесләр белән аралаша. Аның иң якын дусты композитор Нәҗип Җиһанов була. Сессияләргә баргач, Чыңгыз Айтматов, Рәсүл Гамзатов белән бер бүлмәдә яши. Планетабызның беренче космонавты Юрий Гагарин белән сөйләшеп торганда төшкән фотосы «Литературная газета»да басылып чыга. Съездлар сараенда Татарстанның 1 млрд. т нефть чыгаруын илнең иң югары мөн-

бәреннән яңгырата. «Татнефть»нең ул вакыттагы генераль директоры Әгъзам Вәлиханов депутатларны Мәскәүгә озатканда: «Габделбәр, безнең уңышларны көчле, горур итеп сөйлә»,– дип, наказ биреп җибәрә.

Район газетасында басылган 20 гә якын мәкалә авторы да ул. Мондый уңышларга ирешү өчен аңа күп кенә туганнарын да онытып яшәргә туры килә. Нефть чыгару рекордлары, бердәм совет кешесен формалаштыру, коммунизм төзү идеяләре күпләрнең аңын томалаган шул ул вакытларда. Габделбәр абый да үзенең истәлекләрен, нәсел шәҗәрәләрен урыс телендә язган, киләчәктә татар телендә укучы табылырына ышанычы булмаган аның. Әмма ләкин мин аның бу ялгыш фикере белән килешмичә, үзенең ризалыгы белән язмаларын әдәби татар теленә тәрҗемә ясаттым (тәрҗемәче – «Бөгелмә авазы» газетасы хезмәткәре Әлфинур Шәвәлиева). Алла насыйп итеп, ул язмалар да китап булып дөнья күрде (Габделбәр Сәетгәрәев. «Хатирәләр». Бөгелмә, 2014 ел). Ялгышларыбызны төзәтү – безнең бурыч! Татар телен югалтуга юл куймабыз!

Гайфулла хаҗиның икенче оныгы Сәетгали Сәетгәрәй улы Зәй-Каратай авылында «Уңыш» колхозы рәисе урынбасары һәм авыл Советы рәисе булып эшли. Зур агартуэшләре алып бара, авылдашларының тормыш-көнкүреш шартларын яхшырту, авылны яшелләндерү буенча шактый эшләр башкара, шулар тирәсендә матур бәйрәмнәр дә үткәрелә. Кыска гына гомерендә дә, якты кояш шикелле, әйләнә-тирәдәге бик күпләрнең күңелен җылытырга җитешкән ул.

Бүген Лениногорск шәһәрендә гомер кичерүче, анда татар халык театрын оештыручы һәм аның җитәкчесе Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Мәдинә Сафиуллина да әби-бабаларының данлы тормышын лаеклы дәвам итә. Аның кызы Диләрә Киев шәһәрендә яши, журналист, «Украина Медиа Холдинг» нәшрияты редакторы, «Татар йорты»ның вокаль ансамбле артисты.

Гайфулла байның тагын бер оныккае Расих Зиннәт улы Яруллин Тайсуган авылында мәчет төзү эшләренә җитәкчелек итә. Тырышлыгы өчен «Татнефть»нең элеккеге генераль директоры Ринат Галиев аңа хаҗга бару өчен акча бүлеп бирә. Казанда мәдрәсә тәмамлап, авыл мәчетендә актив эш алып бара ул. Туган авылында «Бүре чокыры» дигән чишмәне төзекләндерә.

Шулай ук Тукач Гайфулланың дәвамчы оныккайлары Алмаз һәм Миңнәхмәт Сәгъдиевлар – эчке эшләр подполковнигы, Ринат Сәгъдиев полковник дәрәҗәсенә ирешкәннәр. Розалия Яппарова Снежинск шәһәрендә озак еллар сәнгать мәктәбендә директор булып эшләде. Алмаз Вәлиәхмәтов Төркиянең Конья шәһәрендә Сәлҗүк университетында белем алды.

Аллага шөкер, үзем белгән йөзләгән туган-тумача кардәшләрем арасында җинаять эшләп, төрмәгә эләгүчеләр юк, барысы да җәмгыятькә файдалы кешеләр. Шактые үзенең тормышын көйләү белән генә чикләнмичә, башкалар турында да кайгыртып яши, дөньяга яңалык кертә. Ә андый кешеләрнең гамәлләре мактауга икеләтә лаек.

Язмамны үземнең шигырь юлларым белән тәмамлыйсым килә:

Тырыш һәр җирдә дә без,
Матур безнең халкыбыз.
Азат-хөр мәмләкәттә
Яшәргә без хаклыбыз!

КЫЯМ ҖӘГЪФӘРЕВ: АВТОБИОГРАФИК ИСТӘЛЕКЛӘР

Дамир Таҗи

СЕРЛЕ ДӘФТӘРЛӘР ЭЗЕННӘН

Чирмешән районындагы Кармыш авылы мәчетенең тарихын һәм дин әһелләренең язмышын ачыклаганда авылдашым Наил Гөлемов үзенең нәсел шәҗәрәсе турында бик тәфсилләп, бабаларыннан сөйләнелеп килгән истәлекләр белән уртаклашты. Борынгы бабалары Җәгъфәр Мөхәммәтшәриф улы Кармышның беренче мулласы, чукындырылган авылдашларын хак динебезгә кайтарудагы эшчәнлеге өчен гаепләнеп Себергә куылып, юлда гаҗизлектән, салкын җилләрдән туңып үлгән. Бу нәселдән бик күп муллалар чыккан икән. Шуларның берсе Талибетдин Хәйретдин улы унбиш яшендә ул замандагы иң мәшһүр саналган Тайсуган мәдрәсәсенә укырга кереп, шунда шәкерт, хәлфә, казый булып 1898 елга кадәр яши. Тәҗрибәле дин әһелен хәзерге Сарман районы Рангазар авылына имам хатыйп итеп чакыралар. Әле мал тупларга элгермәгән Талипның беренче никахы бәхетле булмый. Байлыкка күмелеп яшәгән, Югары Әхмәт Шәйхелислам ахунның кызы Сәҗидә белән аерылып Кыям исемле уллары әнисез кала. Талип хәзрәтнең калган балалары Түбән Мактамадан Насретдин мәзин кызы Хөмәйра абыстайдан. Талипка чаялыгына төрттереп «мишәр мулла» дигән кушамат такканнар. Наил әфәнде әнә шул Кыяметдиннән энесе Хәсәнгә бик күп кызыклы мәгълүматлар, тарихлар, исемнәр язылган серле дәфтәрләр күчкән диген иде. Без ул дәфтәрләрне биш еллап эзләдек. Бу нәселнең бер генә дәвамчысына да ул дәфтәрләр эләкмәгән, аның барлыгын да белмиләр. Хәтта Хәтер китапларын да актарып чыктык. Кыям Ватан сугышы елларында немецлар ягында оешкан «Идел-Урал» татар-башкорт легионында хезмәт иткән икән. Әсирлектән котылып кайтып 1947 елның 4 июлендә хыянәтчелектә гаепләнеп кулга алына һәм 25 елга хезмәт белән төзәтү лагерына җибәрелә. Бу кеше турында берәр нәрсә язылмадымы икән дип, язучылар Газиз Кашапов, Рафаэль Мостафиннарның җәлилчеләргә багышланган хезмәтләрен дә укып чыктык. Ул гына да түгел әле, имештер, әлеге язучылар, без телгә алган дәфтәрләрне Үзбәкстанда эзләп йөргәннәр дип ишеткәнебез бар. Димәк, алар легионер Кыям турында нидер белгәннәр, ләкин аның исемен китапларында телгә алмаганнар. Чөнки ул «хыянәтче», аның исемен язмаларда искәртү мөмкин булмаган. Фәү-

зия Бәйрәмова мәкаләләрендә дә бу легионер хакында берни күренми. Искәндәр Гыйләҗевнең безнең көннәрдә басылган «Татарский легион «Идел-Урал» исемле китабында «лектор Ягфаров»ның рәсеме бирелгән (соңыннан туганнары рәсемдә Кыяметдин абзыйны танып алалар), башка хәбәр юк. Сарманда яшәүче якын дустым Дамир ага Гарифуллин татар легионерлары турында «Татар егетләре – француз макизарлары» исемле китабын бүләк иткән иде. Аның туган абыйсы татар легионеры Гокәша Хәйруллин шулай ук 25 елга ирегеннән мәхрүм ителгән «гомерлек мәхбүс». Ниһаять шул китапта «Кыям Җәгъфәрев – «Туран кызы» поэмасы авторы дигән бер кечкенә җөмлә бар. Әһә, шигырь язу дрәҗәсендә торган каләм иясе, ул инде гади генә кеше түгел дип уйлап куйдым. Ә аннан соң лектор һәм пропагандист та әле. Аңлатып торасы да түгелдер, «Туран» сүзе үзе үк зур сәясәт, төрки милләтләрнең бер калыпта булып киләчәкләренә бер нигез салу ул. Легионерларны кем ничек кенә сүксә дә, алар Гитлер җиңү яулаган очракта ике дошман арасында калган татар милләте өчен ниндидер бер яшәү җирлеге булдырырга максат иткәннәр. Фашизм тарафдары булу да татар легионерлары өчен ят нәрсә. Шул ук китапта Сармандагы Яхшыбай авылыннан легионер Раян Зәбиров язмышы бәян ителә. Ул 1947 елда Әлмәт районы Салкын Алан авылында укытучы булып эшләгән җиреннән кулга алынган. Аны арбага да утыртмаганнар, ул ютәлли-ютәлли язмышына буйсынып, бу авылдан җәяүләп, үз рәнҗеш-каргышларын алып мәңгелеккә китеп барган, тимерчыбыклы таш келәт эчендә туберкулёздан үлгән. Ул сорау алулар вакытында Кыямнан кала, татар элитасына кергән кайбер исемнәрне дә әйткән. Мәсәлән, Шакир Алкаев – «Идел-Урал» комитетында хәрби бүлекне җитәкләгән; Мичурин – Муса Җәлилнең Моабит дәфтәренә дә теркәлгән Гали Корбанов; Саматов – типография мөдире Рәис Саматов; Сәет Баталов; Анатолий Кадиев – чуваш, «Идел-Урал» газетасында чувашлар, марилар, мордвалар өчен чыгарылып килгән кушымта мөхәррире; Гокәша Хәйруллин; Гарәфи Сәләхов; Мөхәммәт, 1895 елгы, Гани мулла белән бергә йөргән Гаяз Исхакый чыгарган «Милли юл» журналында эшләгән һәм башкалар.

Татар зыялысы Кыяметдин Җәгъфәрев (икенче документларда Җәгафаров), әлбәттә Муса Җәлил, аның көрәштәшләре, «Идел-Урал» җитәкчесе доктор Әхмәт Тимер (1910–2003) белән турыдан-туры аралашканнар. Әхмәт баштан ук, беренче чиратта Кыям, Гайнан, Җәлил, Алиш кебек йөзәрләгән татар зыялыларын бергә туплаган, алардан бер идарә үзәге оештырган. Әхмәтнең әтисе Әлмәт авылы (хәзерге шәһәр) мулласы Рәшит Яруллин, язучы тарихчы Һади мулла Атласилар белән бергә тугыз кеше 1938 елда төрек шпионнары дип гаепләнеп Казандаерткычларча

атып үтерелгәннәр. Вәкаләте зур булган Әхмәт Тимер хәрби әсирләр тотылган 15 ләп лагерьларда йөреп ачлыктан, хезмәттән һәм йогышлы авырулардан үлеп ятучы 2 меңнән артык татар-башкорт, чуваш егетләрен коткарган зат. Алар арасында булачак «Азатлык» радиосы җитәкчесе Гариф Солтанов та бар. Бу кешенең исемен татарның иҗтимагый-сәяси тарихына кертү һәм аклап таныту өчен тарихчы Ф. Бәйрәмова күп көч салды. Әмма, нечкә күңелле һәм бик тә сакчыл, тиз шикләнүчән татар җәмәгатьчелеге моны күп төрле фикерләр белән каршы алды. Легионерларның исемнәрен дөньяга чыгаруы бүген дә җиңел түгел. Иң кызганычы, мөгаен шулдыр. Кайчандыр алман илендә татар-башкорт легионын оештыручыларның берсе, соңыннан бөтен гомерен Төркиядә мөһаҗирлектә үткәргән, тюркология гыйлеме буенча бөтендөнья күләм дан казанган олуг галим белән, татар әдипләре озак еллар Төркиядә очрашып, елашып, аны һәр төрле җыеннарда мактап телгә алсалар да, чит илдә туган илен бер күрергә тилмереп яшәгән акыл иясенең фәнгә керткән хезмәтләрен генә түгел, хәтта автобиографиясен дә кайтара алмадылар. Әлмәттә яшәп туган якны өйрәнүче Роза Абзалова-Сәлманова гына галимнең автобиографиясен Төркиядән алдырып 2012 елда «Ахмет Тимер: возвращение» исемле бик зәвыклы, эчтәлекле китап чыгарды.

ОЧКЫЧТАН ҖИБӘРЕЛГӘН ХАТ

Кыямның кызы Зәкия улы Илдар әфәнде Милушев, бүген Ташкентта яши. Һөнәре буенча авиация инженеры. Россиянең Пермь мотор заводыннан Үзбәкстанда 27 еллап вәкил. Илдар очкычлардагы «кара әрҗә»-дип йөртелгән приборларны укучы белгеч. Күп тапкырлар чит илләргә командировкаларга барып кайта. Ул безгә бик теләп ярдәм итәргә алынды. Үзбәкстанда булган бөтен туганнарын, танышларын әйләнеп чыкты. Әмма серле дәфтәрләр һаман табылмый иде.

Без Илдар әфәнде белән интернет аша бик күп ихлас һәм дустанә әңгәмәләр оештырдык. Ул мәкалә яза башлаганымны белеп, махсус рисалә язды. Ул аны Россия өстеннән һавада очкычта барганда тәгаенләп, безгә җиргә юллады: *«1971 елда сөекле әниебез Зәкия Кыям кызы безне ата-бабаларыбыз ватаны Татарстанга алып барды. Баштан Ташкенттан Уфага барып әнинең дусты Ольга апаларда кунак булдык. Аннан «Алымов» теплоходына утырып Агыйдел аша Кама елгасына чыгып Алабуга пристанена килеп җиттек. Анда Кыям бабай әнисенең улы Мәхмүт абый Харисов белән күрештек. Можга аша поезд белән Казанга килеп төштек. Бу сәяхәттән санап бетергесез тәэсирләр алдык. Иң хәтердә калганы, Муса Җәлил һәйкәлен күрү иде. Әнием бик озак итеп һәйкәлгә карап торды да елап җибәрде. Мин аптырап аңардан нигә ела-*

вын сорадым. Бу шагыйрь абыең белән синең бабаң, минем әтием бергә немец әсирлегендә булганнар. Шул мизгел мәңге җуелмас булып күңелгә кереп калган. Педагог булып эшләгән әнием партбилеты булмаса да коммунизм идеалларына бик ышнучан кеше иде. Шунда да пионер галстугы тактырып, Җәлилнең шигырьләрен алдан ук ятлап әзерләтеп, миннән тантаналы төстә укытты. Бу минуттан мин Муса Җәлил көрәштәшенең оныгы идем. Еш кына туган-тумачалар әллә чынлап, әлә шаяртып гел шуны искәртергә яраталар иде. Шул хакта институтта укыганда да кайдандыр белеп алганнар.

Алтмышынчы елларда миңа 6–7 яшь кенә булса да «Андижан нефтепром»да яшәгән Кыям бабама Татарстаннан бик күп кунаклар килеп-китеп йөриләр иде. Андый вакытта әни мине аның янына уйнарга җибәрми иде, иркенләп сөйләшсеннәр дигәндер. Әмма бабай мине үзе белән паркка әләктереп китә, кунаклары да аңа ияреләр. Алар бик каты, нәрсәләрдер турында бәхәсләшеп, бер-берсенә куллар болгап озак сөйләшәләр иде. Соңырак белдем. Бу кешеләр Муса Җәлилне реабилитацияләү өчен аның хатирәләрен язып алырга килгәннәр икән. Мин еш кына, нигә бабайның орден-медальләре юк дип әнинең теңкәсенә тиеп йөрим. Әни, ул әсирлектә булган, сугышырга өлгермәгән дип миннән котыла иде. Боларны ишеткәч мин бик хисләнәм. Чөнки әсирлек турында совет фильмнары буенча мавыктыргыч бер кызык нәрсә дип кенә уйлыйм. Әбием бабайның кемгәдер гел язуда икәнен әйтә. Бабай җитдиләнеп, кемгә булсын инде, әнә оныкларыма язам дип миңа төртеп күрсәтә иде. Имештер, менә күрерсең әле, алар мине аңларлар, безнең бабай хыянәтче булмаган диярләр.

Шактый еллар узды мин авиация институтына укырга керергә әзерләнеп документлар җыеп йөрим. Минем янга әнинең бертуганы Талмас абый килеп керде. Ул мине кисәтергә килгән икән. Документларда нәселебездә әсирлектә һәм оккупациядә булучылар турында ялгыш кына да авызыңны ачма, бөтен гомерең заяга узар диде. Ул совет армиясенең замполиты, майор дәрәҗәсен алган офицер илдәге вәзгыятьне бик яхшы аңлаган. Соңырак туган-тумачалардан Кыям бабайның көндәлек дәфтәрләре энесе Хәсән Талип улына күчкәнлеген белдем. Ул аларны гарәп графикасыннанкириллга күчереп язарга алган. Совет иле таркалгач чын хакыйкать әйләнеп кайткандай булды. Дөньяга карата икенче төрле караш туды. Мин бабам дәфтәрләрен искә төшереп аларны чынлап торып эзләргә керештем. Хәсән абый гомеренең азагында Азнакай шәһәрендә төпләнеп калмакчы булган. Ләкин ул анда калалмаган, яңадан азиягә китеп шунда җирләнгән. Хатыны Алла Ташкентка улы Марат янына күчкән. Маратны табып дәфтәрләр турында сораштырдым. Ләкин, Марат

тупас төстәрәк җавап кайтарды, минем дәфтәрләр артыннанкилүем аңа ошамады һәм ул, бу язуларның атасының хатирәләре булуын һәм бәлки әле аларны китап итеп чыгару турында да уе барлыгын әйтте. Ни кызгыныч, Марат та озак яшәмәде, йөрәк өянәге белән китеп барды. Әнием Алла ападан сорашып белеште, дәфтәрләр аларда юк икән. Марат минем белән бәхәсләшкән вакытта, дәфтәрләрнең кайдалыгын үзе дә белмәгән икән. Соңыннан бу фатирга Хәсән улы Ринат урнашып алды. Менә шул Ринат Ташкенттан Маргеланга күчкәндә фатирда дәфтәрләрне таба да, аларны җыйнак итеп бер капчыкка салып әнигә китереп китә. Әни ул вакытта бабайның ир туганы, бервакытта да өйләнмәгән, рак белән чирләгән Шәүкәт абый белән яши иде. Авыр вакытлар бит, дәфтәрләр кайгысы югала, онытыла. Шулай да, әни бервакытны бабайның төрмәдә иҗат ителгән 12 битлек шигырьләр дәфтәрен кайдандыр тапты. Ул шигырьләр балаларына һәм оныкларына багышланган иде. Әни аларны безгә укып бик өзгәләнде, җылады. Әниебез хәтер югалту кебек яман чир белән авырый иде. Соңга табарак ул беркемне дә танымый башлап Гөлнара сеңелемдә тәрбияләнде. Бәхетсезлек өстенә бәхетсезлек дигәндәй табиблар Гөлнарада яман шеш авыруы таптылар. Әнинең фатирын сатып, бик күп акчалар бәрәбәренә кыйммәтле дарулар белән аны коткарып калдык. Әни былтыр вафат булды. Кырык көн узмыйча, без аның бер әйберенә дә кагылмадык. Гөлнара, фатирны җыештырганда, капчыкта татар телендә ниндидер дәфтәрләр килеп чыкты, макулатурага тапшырыйммы, әллә килеп карыйсыңмы, аласыңмы дип шалтыратты. Шатлыгымнан тыным кысылып куйды. Менә югалган дәфтәрләр табылды.

Мин яраткан әбием Лотфулла мулла Мәвләвиев кызы Рауза (Шыгай авылыныкы, Сарман районы) аша татар сөйләм телен белдем (искәрмә: нәселләре борынгы татар шагыйре Мәүлә Колыйга барып тоташа). Без аңа «Казан утлары», «Азат хатын» журналларын яздыра идек, һәр атна кич пылау пешереп Үзбәкстан радиосыннан татар концерты тыңлыйбыз. Мин урыс һәм үзбәк телләрен яхшы беләм, ләкин татар телен аңлап бетерә алмыйм. Шулай да дәфтәрләрдә ни язылганына яхшы төшенәм. Монда татар халкының тарихы, нәселебез хәяты чагылыш тапкан. Мине аеруча бабайның немецларда һәм Сталин лагерларындагы тормышы кызыксындырды. Бу хакта бер сүз дә юк. Уйлап карасаң булуы да мөмкин түгел. Булган очракта да хакимияттән бик куркып яшәгән Хәсән абый аны юкка чыгарыр иде. Шулай да әнием һәм әтием Кәрим Али улыннан ишетеп калган идем. Шуны да әйтим әле, әтием Тамбов мишәре, 1944 елда кырым татарлары белән депортациягә эләккән. Имештер бабай, әсирлектә ниндидер хезмәт, әсәр язган, әсирләрдән татар халкының фольклорын,

җырлар, әкиятләр, әйтемнәр җыеп йөргән (искәрмә: бу төрек (татар-редакция) галиме Әхмәт Тимер кушуы буенча эшләнмәде микән?). Исән калуына өметен югалткан бабам әнә шул язуларын әсирлектән котылган бер иптәше аша туганнарына җибәргән. Ләкин алар эзсез югалганнар. Мин бәләкәй чакта кайбер китапларда кайбер әйтемнәр астында К. Җәгъфәрев исемен күргәләгәнемне хәтерлим әле. Кем белә, бәлки ул дәфтәрләр дә кайдадыр ятадыр. Бабайның кайчандыр дәфтәрләр мәсьәләсендә миңа төртеп күрсәтүе очраклы хәл булмаган икән. Бу дәфтәрләр шәхсән үз кулыма кире әйләнеп кайтты. Үзбәкстанда бу дәфтәрләрнең эчтәлеге миннән кала берекмгә дә кызык булмаганын аңладым. Бу дәфтәрләр бабамның туган иленә кайтырга тиеш дигән катгый фикергә килдем. Аның язулары татарларга гына бик якын һәм бик кадерле бит. Бабам тормышымда түземлелек һәм каһарманлык үрнәге булып торды. Кыям бабам һәм Рауза әбием истәлеге итеп аларның иң яраткан җырлары «Сарман вальсын» үзем белән йөртәм. Чит илдә сагынуга һич чарам калмаганда әнә шул моңлы Сарман көенә негрларны биеткән идем. Соңгы елларда Дамир Таҗиев белән бик нык дуслашып, аралашып киттек. Аның белән Әлмәттә дә очрашып көннәр буе сөйләшеп туймадык. Ул бу дәфтәрләрнең татар халкы тарихы өчен әһәмиятле булуын аңлатты. Монда Кармышта унсигезенче гасырда яшәгән Җәгъфәр мулладан алып унтугызынчы гасыр ахырында мәшһүр Тайсуган мәдрәсәсендә шәкертләр тормышы, фаҗигале хәлләр, татар көнкүреше, якын тирә авыллар белән аралашу, билгеле шәхесләр, мәгърифәт-тәрбия, еш кына мәзәкханәләр бик матур итеп публицистик алымнар белән тасвирланган. Рангазар авылы тарихы аның исеменнән, табигатеннән алып, шунда XIX–ахыры һәм XX гасыр башында яшәгән ярлы-ябагай, байлар тормышы, яшәеш, муллаларның үзара тарткалашуы, мәчет-мәдрәсәләр, әхлак һәм әхлаксызлык, сәүдәчелек, хәтта урам-тыкырык, сазлык-таулык атамалары бер бөтен истәлекләр сәхифәсе булып үрелгән һ. б. Татар милләте кешеләре бабамның Сталин төрмәләрендә, ә аннан соң гаиләсеннән аерылып яшәргә мәҗбүр ителгән шартларда, ялгызлыкта язылган бу хезмәтен укучыга җиткерә алсалар иде. Мин бу 9 дәфтәр белән идарә итү хокукын дустым Дамирга тапшырам. 2014 ел».

КЫЯМНЫҢ ТОРМЫШ ЮЛЫ

Беренче никахтан бәхет тапмаган Талип мулла икенчегә өйләнә. Туй буласы көнне белешеп, күршедәге Югары Әхмәт (Сарман районы) авылындагы кодалары үч итеп, аның бер яшьтә тулмаган Кыям улын, тарантас белән алып килеп йорт янәшәсендә үскән шомыртлар арасына утыртып китәләр. Талипның әнисе Гамбәр карчык бала елаган тавышны

ишетеп урамга чыга. Мулланың икенче никахы да чак кына өзелмичә кала. Гамбәр әбисе аны Кармышка алып кайтып берничә еллар тәрбияләп асрый. Талип хәзрәт түзми, Кыямны яшь әни янына алып кайта һәм кая гына барса да үзе белән ияртеп йөри. Баланың күп нәрсәләрдә бик сәләтле булуы күренә. Ул шигырьләрне, догаларны тиз ятлый, матур тавыш белән укый, күргәннәрен сөйләп бирергә ярата. Алты-җиде яшьлек малай өлкәннәрнең сөйләшүенә дә кушылып китә торган була. Авылдашлары бу баланың акылы тулы микән дип аптыраштa калганнар. Ул язарга да җитез, күргән юлларын, хайваннарны, кушаматларны кая да булса язып куя икән.

Кыям Тайсуган мәдрәсәсендә укып Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә бара. Казан тормышы аны бетереп үзенә йота. Ул мәдрәсә тулай торагында яшәп татар театрына тамашага йөри, анда суфлёр да була, пьесалар күчереп тарата. Инкыйлаб еллары аркасында диннән читләшә дә, митингларда катнаша, җәдидчеләр сафына керә, вәисиләр йорты янындагы атышларны күрә. Казандагы мәдрәсәләр дә ябылып бетә. Шуннан соң Минзәләдә педогогика курсларын бетереп Сарман районындагы Иске Кәшер авылында укытучы, татарча спектакльләр куя. Уфада да бераз укып ала. Галимҗан Ибраһимов, Сәйфи Кудаш, Фатыйх Сәйфи кебек әдипләр белән танышып кайта. 1919 елда Теләнче Тамакта культура агарту бүлеген җитәкли, Себергә качып киткән татар меценаты Халфиннар йортында халык китапханәсе, кибетләрендә клуб ача, 1920 елда сәнәкчеләр фетнәсен бастыруда катнаша, хәттә Төркестанга басмачылар белән сугышырга җибәрелә. Анда ул каты авырап китә... Сарман, Нөркәй кооперацияләрендә эшли, яңа су һәм пар тегермәннәре төзеттерә. Әмма ул яңа властька ничек кенә үзенең тугрылыгын күрсәтсә дә, ул баребер мулла малае булып кала. Алда буласы вакыйгаларны тоемлап ул Үзбәкстанга китә....

Сугыш алдыннан Маргеланда үзбәк балаларына тарих һәм география фәннәре укыта. 1942 елда, хатыны Раузаны, балалары Шәүкәт, Зәкия, Рәмзи, Талмасны калдырып сугышка китә. Шул елның 29 августында Гжатск шәһәре өчен барган сугышларда контузия алып, кабыргалары сынып дошманга әсир төшеп, татар-башкорт легионында хезмәт итә. Аннан котылып кайткач тагын лагерь михнәтләре башлана, «хыянәтче» дип аркасына наган терәп кулга алына. Казанда бер елга якын җәзаланганнан соң суд була. Ул Карабаш лагерында чак кына үлмичә кала, үпкәләре шешә, үзендә малярия һәм бронхит. Инвалидлык бирәләр. Амнистиягә эләгеп 1956 елда тоткынлыктан азат ителә. Әмма аңа гаиләсенә кайтып керү бәхете тәтеми. «Хыянәтче»дән йөз чөерәләр, чөнки барысы да укымышлы, дәрәҗәле урыннарыннан колак кагудан куркалар. Тамагын туйдыру өчен нефтепром «Павланташ»ка оператор булып урнаша.

Тормыш көтелмәгән хәлләрдән торадыр мөгаен. Шәүкәт НКВД гаскәрләренә хезмәт итеп зэкларны саклаган. Караганда (Карабаш һ. б.), Җизказган лагерларында совет хакимиятенә каршы сәяси тоткыннар һәрдаим фетнәләр, баш күтәрүләр оештырганнар. Шулай бервакытны коридор буйлап камераларны тикшереп йөргәндә, кемдер карлыккан зәгыйфь елаклы тавыш белән Шәүкәт, Шәүкәт дип аны чакыра. Шәүкәтнең иң нечкә күңел җепләре өзелеп киткәндәй була. Аңа каты кисәтү һәм шелтә белдереп моннан бик ерактагы башка лагерьга хезмәткә җибәрәләр. Шәүкәт бик рәхим-шәфкатьле, туганнарының балаларын үстерешергә булыша, гомере буе бакчада җимешләр үстерә. Язучы Габдрахман Әпсәләмов үзенең «Ак чәчәкләр» әсәрендә Шәүкәт образын файдаланган дип әйтәләр туганнары.

Кыям Раузасын, балаларын бик нык яраткан икән. Үпкәләп ятмый, гаиләсе яшәгән мәхәлләдә акчага вакытлыча фатир алып урнаша. Ул шуннан шыпырт кына кунакка әниләре янына кайткан балаларын күзәтә, йөрәге түзмәгәндә фатирына бикләнеп өзгәләнеп елый. Балалардан өйдә Талмас кына калган була. Ул мәктәпкә киткәч Кыям бакчага кереп Раузага ялкынлы мәхәббәт белән ташып торган татарча җырлар җырлый. Алар яңадан кавышып китәләр. Кыямның тагын биш ел гомере калган була. Ул бик каты тәмәке тарта. Үлеменә дә шул сәбәпче. Аны 1967 елда үзбәк зиратына җирлиләр. Озату мәҗлесенә бөтен туганнары, аны белгән дуслары, үзбәкләр килә...

Без «Кыям истәлекләрен» мөмкин булганча кыскартып, кабатлауларны сызып, кайбер урыннарын төзәтеп, иң кызыклы әһәмиятле бүлекләрен генә укучы хөкеменә тәкъдим итәбез. Гарәп теленнән алынган сүзләрнең мәгънәсен җәяләр эчендә күрсәтеп бардык. Ә Рангазар авылы тарихы, анда Талип хәзрәтнең эшчәнлеге тагын бер аерым хезмәт язуны таләп итә. Анысы киләчәккә калып торыр. Истәлекләрдә милләтебез тарихының чын йөзе тарихи шәхесләр белән бәйләнеп чынбарлыкта, автор үзе күргәнчә бәян ителә.

ҖӘГЪФӘР МУЛЛА

Патша галиҗәнәбләреннән чиксез хокуклар алып Идел буенда Ислам диненең тамырын корытып, татарларны урыслаштырып бетерү өчен үтә явыз гамәлләр кылган Лука Канашевич, халык телендә Аксак Каратун дип йөртелгән христиан миссионеры, 1740–1742 елларда Казан янындагы бөтен мәчетләрне һич бернинди тоткарлыксыз җимереп, ватып һәм яндырып йөри. Бу мәрхәмәтсез вакыйгалар Кармыш авылын да читләтеп үтми. Мөгаен монда Лука үзе дә килеп чыккандыр. Авылны коралланган солдатлар белән уратып алалар. Чукындыруның кайсы елга туры килүе дә билге-

сез. Миссионерлар Кармышка килеп-чыгып йөрүне бөтенләй туктаталар. Авылда мәхшәр башлана. Биш вакыт намаз укыла торган йортны мәсхәрәлиләр, эчендәге әйберләрне сындыралар, тибәләр һәм үзләренең динен иң дөрес хак юл дип халыкка көчләп тагалар. Әмма беркем дә муенына үзе теләп тәре такмый. Гомере буе бөтен нәрсәдән дер калтырап яшәгән халык көчләү, үтерү һәм сөргендә ачка катып үлүдән куркып, эченнән бисмилләсен әйтеп, Аллаһыдан гафу сорап чукынгандай итәләр. Чукындырылганнарның исемлеген төзеп катгый төстә янәшәдәге чиркәүләргә беркетелә. Болар Күтәмә, Кармалка яки Новотроицк чиркәүләре булса кирәк. Кармышның бер ише Аксак Каратунның бу якларга килүен ишетеп урманлыкларга кереп качкан була. Алар арасында дини уку-язуны яхшы белгән Җәгъфәр мулла да бар. Әнә шул рәвешле бер төбәктән күчеп килгән кан кардәшләр арасында зур упкын хасил була. Инде кыз бирү, кыз алу, туйлар уздыру, гыйбадәт кылулар икенчегә әйләнә. Ике исемле татарлар барлыкка килә. Алар юньләп үзләренең урыс исемнәрен әйтә дә белмәгәннәр һәм бу аларга кирәк тә булмаган, үзләренчә, яшертен булса да мөселман гореф гадәтләрен дәвам иткәннәр. Әнә шул чукындырылганнар аркасында авылда азан әйтелми, рәсми төстә намаз укуларга да ирек куелмый. Шул сәбәпле чукынмаганнар үзләренә Түбән Кармыш дигән яңа исем алганнар. Бу аларга дини мөстәкыйльлек бирә. Миссионерларның авылга куелган шымчылары халык эчендә ни булганын, ни сөйләгәннәрне чиркәүгә җиткереп торганнар. Ул хәбәрләр чиркәү әһелләре өчен бер дә куанычлы булмый. Кармышлылар чукынган авылдашларын «мөкерәләр» яки «мәкруһ»лар (начар күрелгән мәҗбүри гамәл мәгънәсендә) дип йөртәләр, «керәшен» дип әйтергә куркалар. Бу авыл халкының бик диндар булулары да урыс золымыннан котылу өчен ничек кенә булса да Ислам диненә тотынып калудан гыйбрәттер. Кулыбызга килеп кергән ошбу көндәлектә мондый юллар бар: «Безнең бабалар Казан артындагы Кармыш шәһәрчегеннән күчеп килгәнгә туры килә. Бөек Болгар дәүләте вәйран ителгәч, әле Казан дәүләте аякка басмаган бер дәвердә Кармыш төрки халыкларга мәркәз булып хезмәт иткән. Шиһап хәзрәт Мәрҗани үзенең үлемсез «Мөстәфадел-әхбәр...» әсәрендә «Вә галикол Олуг Мөхәммәд хан шәһәре Сарайдан матруд булдыгы бәгъдендә Казанга килмәй Нижний вә Кармышта карар тапты» (Искәрмә: без бу юлларны 1989 елда басылган ул китапта күрмәдек, күрәмсең ул гарәпчәсеннән төшеп калгандыр дигән фикергә килдек). Бабаларның Кармыштан качып дәһшәтле 1552 елгы вакыйгаларны кичергәннән соң Кама елгасының сул ягындагы күпчелек татар авыллары шул фаҗигаләрдән соң нигезләнә башлаган. Унҗиденче гасыр башлларында ук Кармыш авылы шул хәзерге урынында торганлыгы анык билгеле» (Д.Т. искәрмәсе: әмма андый документны беркемнең дә күргәне юк).

Җәгъфәр бу кара елларда халык арасында баш булып торганлыгын, курыкмас бер көчле кеше булуын картлар буыннан буынга сөйләп килгәннәр. Беренче муллабыз яңа туганнарга мөселманча исем куйган, үлгәннәрне мөселман итеп күмгән, дини бәйрәмнәрдә гает намазларын укыткан. Ул елларда имамәтчелек кылу өчен урыс хөкүмәтеннән рөхсәт алу кануннары әле кертелмәгән, беркем дә муллалыкка указ сорап урыска ялынып йөрмәгән. Киресенчә христиан дин әһелләре татар авылларында мондый кешеләрне булдырмау өчен зур тырышлык куеп төрле мәкерле чаралар күрәләр. Әмма үз заманына дөрес бәя бирә белгән укымышлы имам мондый гаделсезлектән, хурлыктан читтә кала алмый, корал һәм тәре белән җиңеп булмый торган рухи каршылык оештыра. Авылга поп үзенең сакчылары белән тәресен күтәреп килгәндә өй хуҗасы күрше авылга чыгып киткән була, яисә башка бер урында качып утыра. Бу кешеләр балаларына исем кушу өчен чиркәүгә бармыйлар. Йортта хуҗаны тотсаң да, попның күңеле булсын өчен генә ашык-пошык иконаны яшерелгән урыннан алып түргә элеп куя да, ул китү белән үк бисмилләсен әйтеп иконаны икенче килгәнгә кадәр сәндерәгә атып бәрә, шуннан кала ул аның бер файдасын да белми. Бу кешеләр нәрсә генә әйтсәң дә, белепме-белмичәме гел киресен эшләп торалар. Поп Кармыш урамы буйлап арып-талып «Зягфәр башына нәләт төшсен» дип карганып йөри һәм беркадәр шүрли дә, көтелмәгән хәл килеп чыкса, тиз генә качып китү җае да алдан уйланылып куйган була. Бары тик шул Җәгъфәр генә халыкны котырта, керәшен балаларына мөселман исеме бирә, закон бозып туй никахлары, җеназа намазлары укый, дини мәҗлесләрдә үзенекен өйрәтеп йөри. Ул гына түгел әле, керәшен зиратына күмелүчеләрнең васыятен искә алып, караңгы төннәрдә шуларның туган-тумачалары белән мәрхүмне янәдән җирдән казып алып, табутны ватып ыргыталар да җәсәдне юуып, ләхет алып мөселман зиратына иңдерәләр. Мондый куркыныч эшләр Кармышта шактый еллар дәвам итә. Урыс поплары моны белеп алып бик зур җәнҗал чыгаралар. Керәшен зиратына пүнәтәйләр белән килеп бик күп каберләрне ачып карыйлар. Җәгъфәр мулланың эшләре һәммәсе ачылып китә. Аны кулга алып авылдагы бик күп кешеләрне тикшерәләр. Мулла абзый бөтен эшләрне дә үз өстенә алган булса кирәк, кулларына богау салып алып китеп Казанда суд кылалар һәм гомерлеккә каторга хезмәтенә Себергә җибәрәләр. Ул шунда газапка, карлы-буранлы салкын җилләргә түзмичә юлда үлеп кала. Кайда үлгәне, кайсы елда хөкем ителүе бу көнгә кадәр билгеле түгел.

Җәгъфәр хәзрәтнең авылда калган ятим гаиләсен урядниклар күзәтү астына ала. Аларга укырга, мулла булырга, авылның җәмгыяви эшләрендә катнашулар тыела. Гобәйдулла исемле улы Кармышта яшәп иген игә. Тормышы бик фәкыйрь, өй-йортлары, каралтылары начар булып бик авырлык

белән генә гомер итә. Балалары Фәхретдин белән Сөнгатулла балачакларыннан ук мөмкин булганча хуҗалыкта булышалар. Фәхретдин эре сөякле, таза, озын буйлы ир. Озак еллар патша хезмәтендә, урысның Кавказмы әллә Кырымнымы буйсындыру сугышларында катнашып хезмәт итеп кайтса да егәрлеген югалтмаган. Энесе киресенчә, атасын сөргенгә озаткан патшага хезмәт итүне харам санап, үзлегеннән дини китаплар укып, урыс дөньясының вәхшилегенә төшенеп армиягә бармас өчен авылдан чыгып качкан. Себердә каңгырап, сукбай булып ирекле сәяхәтләрдә авылдан-авылга, шәһәрдән-шәһәргә күчеп килгән Сөнгатулла Троицк шәһәрендә тукталып кала. Шунда мәдрәсәдә укып хәлфә дәрәҗәсенә ирешә. Улы Гайфулла Томск шәһәрендә танылган бай сәүдәгәр булып җитешә...

Искәрмә: Җәгъфәр турындагы мәкалә алар нәселеннән булган Талип хәзрәт Хәйретдиновның (1869–1921) улы Кыям Җәгъфәров (1900–1967) истәлекләренә нигезләнеп язылды. Бу хәлләр турында ерак заманнарда ук сөйләгәннәр. Шулай ук кайчандыр авылыбыз картларыннан ишеткән хәбәрләрне, үзебез белгәннәрне дә шунда язырга булдык. Бик тәгаен булмаса да үз милләте өчен шәһит киткән җанның сурәтен язып карадык. Нәселләренең кайчандыр Россиядән качып (1895 нче еллар) киткән бер нәселендә, кардәшебез Бәһзат Акташта сакланган шәҗәрәдә, мулла абзыйның этисе Мөхәммәтшәриф итеп күрсәтелә. Авылда Җәгъфәрне Пугач фетнәсендә эзәрлекләүдән качып килеп чыккан дип әйтүчеләр дә бар. Имештер ул Балык Бистәсендәге Күгәрчен авылыннан икән. Әмма документаль дәлилләрне күргәнебез юк. Галим Марсель Әхмәтҗановның «Татар шәҗәрәләре» китабының икенче томында, язучы Касыйм Бикколов төзегән Буа төбәгендә Яңа Тинчәле авылы шәҗәрәләрендә Сүнәй баба нәселендә Мөхәммәтшәриф улы Җәгъфәр бар. Монысы күбрәк дөреслеккә туры килә. Шул ук төбәктә, чыгышы белән Түбән Наратбаш авылыныкы шагыйрь Гарифҗан Хәсәнов (1812–1893) шәҗәрәсендә Җәгъфәр Мөхәммәтшәриф исеме күренә. Кармыш авылының 1858 елгы ревизия язуларында Гобәйдулла (1785), Хәйбулла (1789), Хәмидулла (1791), Ибатулла (1799) Җәгъфәревлар теркәлгән. Болар Җәгъфәр балаларымы, әллә оныкларымы дигән сорау безләргә тынгылык бирми. Оныклары дигәндә мулланың 1740–1750 еллардагы чукындыру вакыйгаларын күрүе дөреслеккә бик якын килә. Әгәр аның 1799 елда туган улы бар икән, димәк ул яшерәк, чукындыру вакыйгалары узганнан соң гына имамәтчелек кылгандыр дип әйтеп була. Кармышның 1816 елгы ревизия язуларында аның исеме бетереп күренми.

(Дәвамы бар)

ИСТОРИЯ ВОЗНИКНОВЕНИЯ СЕЛА СТАРАЯ КИРЕМЕТЬ АКСУБАЕВСКОГО РАЙОНА

Р. З. Салиев

Антонация: *В публикации рассказывается об истории возникновения с. Старая Киреметь – родины классика татарской поэзии Хасана Туфана. История села достойна уважения. Нам есть чем гордиться!*

В 2017 г. я издал книгу «История села Старая Киреметь» (Казань, изд. «Яз», 284 с., редактор Нурулла Гариф), где на основе хорошо подобранных архивных материалов и воспоминаний местных жителей рассказывается об истории возникновения и развития села, корни которого уходят в далёкое прошлое…

Ключевые слова: *Киреметь, Карый Оммят, пустоши, «Великая замятня», Ландратская перепись.*

Глубоко в историю уходят корни с. Старая Киреметь. Село в буквальном смысле стоит вблизи древних поселений булгар, то есть в историческом плане расположено в ближайшей округе Биляра – Великого города – столицы домонгольской Булгарии. В 20 км к юго-западу от Старой Киремети расположено с. Шербень. Не лишним будет сказать, что это село в 1996 г. отметило свое 1100-летие. Выходит, от Старой Киремети рукой подать до села, которое старше самой Казани почти на целое столетие. Хотя, по мнению историков, люди здесь жили и раньше, об этом свидетельствуют многочисленные археологические находки. Как мы знаем из истории, до монгольского завоевания в нашей местности было Булгарское государство – одно из крупнейших средневековых государств Восточной Европы. В ее истории запечатлена часть истории народов Среднего Поволжья и Прикамья, прежде всего, татарского народа.

В своей автобиографии Хасан Туфан писал: «Древнейшие курганы, развалины старинной крепости на поле, называемом «казённой поляной», одинокая могила вдоль большой дороги, хранящая тайну когда-то разыгравшейся здесь трагедии,– таковы мои первые детские впечатления о родном крае. Когда-то мой край был одним из центров древней булгарской культуры. С тех пор до нас дошли лишь старинные легенды и предания».

Оказывается, были курганы и развалины старинной крепости…

Если дать волю фантазии, то легко можно представить, как маленький Хисбулла (Хасан) с ватагой деревенских ребят целыми днями пропадал на развалинах этой крепости. Возможно, ребята играли в «войну», может

они искали клад. Я и сам в детстве со старшим братом не раз бывал на этом месте, но, к сожалению, мы развалин крепости не видели. Очевидно, никто не позаботился об их сохранности для потомков. По словам моего отца, в те годы у пахарей был лозунг: «Пахать всегда, пахать везде!» Из «казённой поляны» многие трактора не могли дотянуть своим ходом до МТС, они часто ломались по неизвестной причине. Так,видимо, земля-матушка, сопротивлялась варварскому отношению людей к своей истории. Прозрение как всегда приходит слишком поздно. Очень хочется надеяться, что эти строки прочитает кто-то из археологов и в скором времени на это место прибудет десант. Видно же, что земля Старокиреметская хранит в себе много нераскрытых тайн, нужно только спуститься в глубины культурного слоя. Почему же археологи тянут с приездом? Чтобы определить точный возраст Старой Киремети нужно заложить раскопы по всей деревне. А на радиоуглеродный анализ одной только археологической находки потребуется немало средств, одним словом, большие деньги. Вот поэтому остается только надеяться на чудо…

На картах, отображающих период Булгарского государства, значится город Биляр, но с. Старая Киреметь и других населенных пунктов нынешнего Аксубаевского района мы там не обнаружим, но это не значит, что Старой Киремети не существовало. Точную дату образования Старой Киремети мы не знаем. Документов об этом не обнаружено. Его древность, возможно, удастся выявить по археологическим находкам. Но, к сожалению, эта территория пока полностью не изучена археологами.

Среди жителей чувашской стороны Старой Киремети бытует легенда, что раньше всех тут жили чуваши-язычники, у них была Кереметь – священное место, где они молились семьями перед началом посевных работ. Место это очень почиталось всеми жителями. Но чуваши здесь появились только через сто лет, после завоевания Казанского ханства, после того, как эти земли начали пустовать. В это же время сюда переселялись и татары – они назвали деревню – Татарская Киреметь. В этой легенде упускается из виду очень важный факт, который не отрицают ученые-историки. Это факт заключается в том, что киремети были и у древних булгар, прямыми потомками которых частично являются казанские татары.

Кереметь обычно находится на каком-то возвышенном месте, возле которого обязательно находится источник. Часто для этого выбирали защищенное со всех сторон место. Таким Кереметем была местность вблизи Биляра, превратившаяся в природный храм всего общества Волжской Булгарии. С принятием верховной властью ислама Кереметь приобретает название «Валем/Малем-ходжа». Но возникновение вторичного названия не могло стать запретительным тормозом посещения чувашами, марий-

цами, мордвой и удмуртами этого святилища. С распространением среди народов Среднего Поволжья христианства Русская православная церковь также пытается перетянуть Валем-ходжу на свою сторону. Православные стали посещать святилище в дни церковных празднеств. При молениях вблизи родника ставили иконы, а местность назвали «Святым ключом».

Слово «керемет» происходит через тюркское и персидское посредство от арабского «карамат» – «чудо». В прошлом, в религиозном миропонимании народов Среднего Поволжья Кереметь, например, у татар, в связи с принятием ислама, перешла в иное восприятие – киреметью стали называть родники, которые текут в направлении Кыйблы – Мекки. А у чувашей оно выступало как главное святилище. Главным оно было и в Волжской Булгарии раннего периода.

История основания д. Старая Киреметъ и происхождение её имени восходит к булгарскому и золотоордынскому периодам. «Монда, дөньядагы иң зур шәһәрләрнең берсе булган Биләр тирәсендә кайда чишмә, елга булган, шунда авыллар барлыкка килгән…».

Думаю, сейчас как раз время рассказать уважаемому читателю о Старокиреметском надгробие, о котором писал Хасан Туфан в своей автобиографии…

Это надгробие позволяет уже документально утверждать о времени возникновения Старой Татарской Киремети. Обратимся к источнику 169: *«Старокиреметское надгробие. XIV в. Старая Киреметь, с. Аксубевского района, левый берег р. Киреметь, левого притока р. Шербень, правого притока р. М. Сульча. В 1 км на юго-запад от села, около шоссе есть булгарский надгробный камень (142×69×22 см), разломанный на три куска. На верху камня – арка с розеткой, текст выполнен почерком насх рельефными буквами, сохранность плохая. Дата – 1351 г.»* [Р. Г. Фахрутдинов: 1975, № 126; Ф. С. Хакимзянов: 1978, с. 193.; A. Rona-Tas: 1976. с. 169–170. Этап Улуса Джучи («Золотая Орда») и Казанского ханства].

Одинокое надгробие многие века хранит свою тайну. Имени человека, которому воздвигнут этот памятник, в деревне не знает никто. Наверняка, это был очень уважаемый или даже святой человек. Жители Старой Киремети считают, что Старокиреметское надгробие – это могила древнего татарского воина, погибшего в жестоком бою с врагами. Тогда почему усопшего по мусульманской традиции не увезли на родовое кладбище, а похоронили в чужих краях? Люди всегда останавливаются, увидев это надгробие, и долго читают суры из Корана. Среди жителей деревни распространено мнение, что мольбы возле этого надгробия лучше принимаются Аллахом. По словам старожилов, жители Старой Киремети никогда не слышали и не считали, что это место когда-то было кладбищем, где хоронили умерших жителей деревни. Почему же жители Старой Киреме-

ти хотя и почитают эту могилу, но считают её «чужой», а не своей? Мне кажется, этому есть простое объяснение. Известный ученый-историк Нурулла Гариф считает: *«Ул – зират булырга тиеш. Бүтән җирдә дә бер, яисә ике генә таш торган урыннар бар, әмма, алар барысы да зиратлар. Авыл кешеләре аларны үзләренеке дип санамауларының сәбәбе – чөнки хәзерге авыл кешеләре – алар барысы да «пришлыйлар» («чужойлар»). Әлеге зират атамасы шушы авылга Иске Кирмәт – Иске зират мәгьнәсендә атама биргән дә инде. Тарихчылар бу чорны яхшы белә»*.

Это время в русских источниках получило название «Великая замятня». Во времена «Великой замятни» происходили междоусобные войны. С 1359 по1380 гг. на золотоордынском престоле сменился два десятка ханов, а многие улусы попытались стать независимыми. И Аксак Тимур прошёл войной в этих краях, также прошли Токтамыш и Идегэй. Местное население края спряталось кто-куда или же мигрировало в более благополучные регионы – Предкамье и Предволжье. В одно время эти края совершенно опустели. «Пустоши» возникли и в XVI–начале XVII вв. Все они являются бывшими жилыми поселениями, опустевшими в основном в ходе Казанской войны 1552–1556 гг. Почти все они в течение XVII в. были заселены заново. Когда эти места начали заново заселяться, могильные надгробия ещё сохранялись. Кругом было печальное зрелище: старые кладбища, «порожняя земля» и «пустоши». Название Старая Киреметь было дано вновь прибывшими на эти пустоши жителями, так как они поселились рядом со старым кладбищем. В прошлом названия никогда не давались случайно. Старожилы все еще помнят, что в разных частях деревни, когда-то были еще две старые могилы (одна из них, по преданию, золотоордынского периода). Когда-то у этих могил были каменные надгробия, но в деревне никто не мог прочесть, что написано на этих камнях, так как время наложило на них свой отпечаток.

В настоящее время от этих надгробий, а также от старого кладбищане осталось и следа. Но расположение старого кладбища указано в плане деревни. Съёмка 1857 г. [НА РТ. Ф. 324. Оп. 735. Ед. хр. 1154. Л. 3]. В годы воинствующего атеизма эти могилы и кладбище вспахали под картофельные огороды. Огороды вспахали, но по утверждению тех же старожилов урожай всегда был скудным…

Мне так и хочется сказать, что Старокиреметское надгробие – это паспорт давнего прошлого Старой Киремети. Рядом с этим кладбищем должно быть и древнее поселение. Возможно, однажды мы узнаем тайну этого надгробия и найдем это поселение. Эта тайна уже начинает открываться…

Одна из известных легенд об основании Старой Киремети как раз связана с политикой насильственной христианизации. В 1552 г. Иван Грозный

штурмом взял Казань и начал крестить татар. Мусульманское население бежало куда глаза глядят от произвола русской администрации и политики насильственной христианизации. Самым первым на место нынешней деревни пришел человек по имени Карый Оммят с 18 детьми, он облюбовал эти места и решил превратить эту землю в цветущий сад. В то время здесь была глухая тайга. Они прочистили, прорубили дремучий лес, и на этом месте начали жить. Со временем тут образовалась деревня, которую назвали его именем. Это название постепенно превратилось в Киреметь (Кармят). Посередине деревни текла небольшая река Киреметь (Карый Оммят – Кармят – Киреметь), она была глубокая, и сюда прилетало много лебедей. Вот поп дошел и до Киремети и окрестил всю деревню, но какая-то часть жителей сумела скрыться. Так в деревне появилась Олы и Кече ара. Кече ара – это те, которых окрестили, Олы ара те, кто скрывались и избежали крещения. Но, тем не менее, крещённые жили, как и раньше: в церковь не ходили, не венчались, тайно держались мусульманской веры. Эта легенда путем устной передачи переходила из поколения в поколение. Каждый житель деревни, и стар и млад, хорошо знает ее содержание. Интернет также полон этой легендой, на его безграничных просторах в эту легенду каким-то образом вкралась ошибка. На многих сайтах, где упоминается легенда, написали, что в 1555 г. Иван Грозный взял Казань и начал крестить всех татар. Удивляет, что никто не потрудился исправить досадную ошибку (известно, войска Ивана Грозного взяли Казань в 1552 г.). По рассказам Салих бабая Ахметшина в 1925 г., когда он учился в Чистопольском педагогическом техникуме, им задали домашнее задание: написать историю своей деревни. В то время в деревне жил 90-летний Нафигулла (Няпи) бабай. Вот к нему он и обратился. Нафигулла бабай 15 лет служил в солдатах и ходил он, как под музыку марша. При разговоре вставлял русские слова, был очень интересным собеседником. Вот этот почтенный Нафигулла бабай и рассказал молодому студенту красивую легенду основания деревни. Салих Ахметшин очень внимательно слушал деревенского аксакала и по ходу все записывал в тетрадь. Его записи и по сей день являются одним из источников информации по истории с. Старая Киреметь. Следует также отметить, что он составил более 100 родословных жителей села с охватом в несколько поколений. (Күрэсең, ул бик акыллы кеше булган, урыны оҗмахта булсын!). Мне кажется, в этой красивой легенде поэтическая декоративность заслоняет исторические факты. Думаю, что в легенде часть истории Старой Киремети изложена не совсем достоверно. Факты и документы говорят о другом.

Чтобы убедиться в этом, продолжим «углубление» вглубь веков. Возможно, Карый Оммят и его дети жили в нашей деревне. Никто у них не

отбирает право на жительство, у них бессрочная прописка, но они не являются отцами-основателями нашей деревни. Лучше всего надо читать эту легенду между строк! Посудите сами. Со времени появления легендарного Карый Оммята в деревне Киреметь до Ландратской переписи 1716–1717 гг. прошло 164 года. В переписи 1716 года впервые в исторических документах упоминается деревня Киреметь с татарским населением. Перепись начинается со слов: *«Закамской стороны Киреметь мурзы»*. В переписи черным по белому написано, что в деревне Кереметь жило: *«пятьдесят четыре человека, в том числе женатых – двадцать два, холостых – тридцать два. Пятьдесят три человека, в том числе вдовы – шесть, мужатых жен двадцать четыре человека, девок – двадцать три. Всего мужеска и женска полу сто семь человек»* [РГАДА. Ф. 350. Оп. 1. Ед. хр. 158. Л. 126–128]. Выходит, переписчики-ландраты проявили скупость? В переписи 1716 г. в деревне Кереметъ я сосчитал, что только у трех братьев Мамаделеевых сынов князя Мансыревых в семействах было 20 человек: *«Мардяш мурза Мамаделеев сын князь Мансырев 50, его жена Янайка Нуркина 50, дети уразай 10, Мустай 5. Дочь девка Гульбичка 4. Да на том дворе в особой избе зять его Курманай Сулейманов 30, сын Милюк 5 лет, дочь Адамсалтанайка году. Адар мурза Мамаделеев сын князь Мансырев 40, у него жена Гульназачка Имаева 30, дети Ибрай 10, Смаил году, дочери девки Казычка 10, Шарбанка 5, пасынок Мансур Усманов 12. Да в особой избе брат его родной Таберка 35. У него жена Гульчарперка Кармышева 30, дочери девки Ураздавлетка 5, Зеняпка 3, да приемыш Степан Ишбулдин 20 лет…»* Далее в переписи перечисляются татары – жители Старой Киреметi. Их 87 человек. Кстати, как видим, у Мардяша и Адара Мамаделеевых указаны их мурзинское достоинство, а у их родного брата Таберки оно не указано и ссылки на фамилию Мансырев уже нет. То есть, утрачена связь с более глубоким достоинством. Дети Мардяша и Адара тоже без приставок «мурзы». Но их потомки свое достоинство доказывали уже к концу века. Порассуждать здесь можно много. Отмечу только, что в Ландратской переписи возрасты жителей Киремети указаны прописью. Я решил их показать для удобства цифрами.

Вернёмся к Карый Оммяту. Получается, что многочисленные дети Карый Оммята в течение 164 лет не заботились о продолжении своего рода? Этого не может быть! Как не крути, Карый Оммят не является основателем с. Старая Киреметь. Также можно уверенно утверждать, что Мардяш мурза и Адар мурза Мамаделеевы и их дети не являются основателями Старой Киремети. Так как существует документ, который позволяет утверждать о более раннем возникновении села – это Старокиреметское надгробие. Не лишним будет, если обратимся к одному достоверному источнику – это кни-

га «Истәлекләр» Хасанжана Ахмерова имам–хатыба с. Старая Киреметь в 1906–1917 гг. [Хәсанҗан Әхмеров. Истәлекләр. Казан: «Иман» нәшриәте, 2004]. В своих воспоминаниях на с. 114 он пишет: *«Бер вакыт Казанга барганымда, мөршид Камил Нури хәзрәт Тархани мөхтәрәм остаз Салихҗан хәзрәткә кунак булып килгән. Бездәге хәлләрне сорау соңында: «Кармәтнең исеме, моннан соң «Карый өммәт» булсын»,– дип авылга яңа исем тәкдим иткән иде».* Из воспоминаний можно установить, что Х. Ахмерову такое предложение было сделано в начале XX века. По легенде Карый Оммят в 1552 г. основал деревню, которую назвали его именем, которая постепенно превратилась в Киреметь. У меня возникает интересный вопрос: «Зачем муршид Камил Нури хазрат Тархани предлагает назвать деревню «Карый өммәт?» Выходит, никакого превращения имени Карый Оммят в Киреметь (Кармят) до этого не было? Наша деревня изначально получила название Киреметь (Кирәмәт, Кармәт). Очевидно, легенда появилась в позднее время. Нафигулла бабай был не только интересным рассказчиком, но и мог сочинить красивую легенду о возникновении деревни. Эта легенда нравится всем, ей либо верят, либо слишком сильно верят. Современные легенды сочинялись по тому же принципу, как древнегреческие мифы, которые дошли до наших дней. Легенда продолжает жить, потому что в неё люди верят. И все же Карый Оммят бабай, о котором сложена легенда, получил от жителей деревни Старая Киреметь (Иске Кармәт) паспорт на бессмертие. Его имя в списке легендарных людей и его образ по-прежнему притягивает наши взоры,так как легенда всегда берет верх над историей. Есть и другая легенда происхождения названия деревни. Раньше нашу деревню также называли Вершинная Киреметь, а со временем стали называть Баш Кармят, потому что рядом стали появляться и другие деревни – Чувашская Киреметь (на другом берегу речки Киреметь), Русская Киреметь в трёх километрах и Новая Киреметь в семи километрах. Реальная история Старой Киремети такая же красивая и интересная, как и легенды о ее возникновении.

Литература:

1. Ахмеров Хәсанжан. Истәлекләр. Казан: «Иман» нәшриәте, 2004.

2. Карта археологических памятников Волжско-Камской Булгарии с X века по первую половину XV века. Из книги Р. Г. Фахрутдинова «Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория». Таткнигоиздат, 1975.

3. Национальный архив Республики Татарстан (НА РТ). Ф. 324. Оп. 735. Ед. хр. 1154.

4. Российский государственный архив древних актов (РГАДА). Ф. 350. Оп. 1. Ед. хр. 158.

АВЫЛЫМ ФАҖИГАСЕ

Т. Ә. Биктимирова

2017 елның 23–24 маенда Азнакай шәһәрендә «Көнчыгыш Татарстанда кеше һәм табигать. Югалган һәм тарихи авылларны өйрәнү, торгызу һәм саклау проблемалары» дигән темага Бөтендөнья Татар конгресы белән берлектә фәнни-гамәли конференция үткәрелде. Аны оештырган Азнакай районы башлыгы Марсель Зөфәр улы Шәйдуллинга һәм Ш. Мәрҗани ис. Тарих институты элеккеге фәнни хезмәткәре Альберт Әхмәтҗан улы Борһановка катнашучыларның рәхмәтләре чиксез иде. Конференция халыкара дәрәҗәдә үткәрелде. Аңа Россия төбәкләреннән һәм чит илдән килгән галимнәрнең уртак фикере, бәһасе бер булды: бу форум бик кирәкле һәм кичектерергә һич тә ярамый торган актуаль чара. Шунысы да мөһим, Азнакайда мондый конференция инде икенче тапкыр үткәрелде. Тагын бер тапкыр рәхмәт оештыручыларга. Барыбызны да уйланырга, үткәннәребезгә кайтырга һәм тарихыбызны хөрмәтләргә этәрде ул чара.

Мин Әтнә районы Яңа Шимбер авылы кызы. Авылыбызда яшәүчеләр күбесе өлкән кешеләр, аларның елдан-ел саннары кими бара. Яшьләр китә. Конференция барышында да, үземнең моннан 4–5 ел элек, урам уртасына басып, «авылым бетәсең бит, күпме кешеңне югалттың бит инде»,– дип кычкырып елаганымны искә төшереп утырдым. Елаучы кеше мин генә түгелдер дип уйлыйм...

Тагын бер истәлек. Монысы Ш. Мәрҗани исем. Тарих институтында эшләгән вакытым белән бәйле. Һәр ел саен безгә (ягъни институтка) районнардан укучыларның тарихка багышланган фәнни эшләрен бәяләү өчен җибәрәләр иде. Конкурсларның берсендә җиңеп чыккан Әхмәдуллина Асиянең (Казан, Яңа Савин районының 155 гимназия укучысы) «Чебенле авылы сагышы (әнием хатирәсе)» дигән чыгышы үзәгемне өзде...

... Чебенле авылының фаҗигасе, ялгышмасам, XX гасырның 70 еллар азагында «Түбән Кама сусаклагычы» төзелү белән бәйле. Бик күп авылларны, су астында каласы булгач, күченергә мәҗбүр итәләр ул чакта. «Туган нигезләре белән мәңгелеккә аерылу минутларын бигрәк тә әби-бабайлар авыр кичергән,– дип сөйләде Асия. – Җиргә ятып, сабый балалардай үкси-үкси: «Без беркая да китмибез. Шушында тудык, шушында үстек, шушында үләбез...»,– дип елаганнар алар.

Ничекләр түзделәр икән алар. Өсләренә үкереп, шаулап су диңгезе килгәндә, йөрәкләре ничек ярылмады икән? Әнием сөйләгәндә, кызганудан үземне кая куярга да белмәдем».

Югалган авыллар хакында тагын да булгалады әле укучыларның фәнни эшләре. Әмма Чебенле фаҗигасен укучы белән бергә кичердем, бергә кайгырдым. Татарстаныбызда югалган авылларның саны бүгенге көндә 1200 дән артып киткәнен белми идем әле. Бу хакта әле быел гына «Исчезнувшие населенные пункты Республики Татарстан» дигән белешмә чыкты. Кызыксынучылар алып укый ала. Туган авылым – Яңа Шимберне дә шундый язмыш көтми микән дип борчылам. Чөнки көн итәр өчен иң кирәкле ризык, чәй, сөт кебек әйберләр алырга кибете дә юк бит хәзер авылымның. Яшәүчеләрнең күбесе өлкәннәр. Сыер асрый алмаучылар да бар.

Ә бит Яңа Шимбер авылы (тарихка «Борисовский Отар» исеме белән дә кереп калган) тирә-якта исеме чыккан хөрмәтле авылларның берсе булган. Казан татарларының мәдәниятен, гореф-гадәтләрен өйрәнүче атаклы галим, Казан университеты профессоры, ректоры Карл Фукс (1776–1846) «Шимбер җыены» хакында, аны игътибарга алып: «1834 елның 8 нче июлендә булды» дип язып калдырган. Бу җыенда Яңа һәм Иске Шимбер, Югары һәм Түбән Көек, Ары авыллары кешеләре катнашкан. Тирә-як авылларыннан кунаклар җыелган. Җыен Ары белән Югары Көек арасында, Яңа Мәзекәү (Мазиково) авылы янында, Ибраш елгасы буенда булган. Җыенга шушы төркемдәге авылларның иң өлкәне исеме бирелгәне билгеле бит инде.

Әйтеп үтик, Яңа Мәзекәү авылы янында җыен үткәрелгән җир Шимбернең үз җире булган.

Олуг тарихчыбыз Марсель Әхмәтҗановтан борынгы тарихыбыз, авылыбызның килеп чыгышы хакында сораганым булды. Ул безнең яктагы авылларны Казан ханы Мөхәммәдәмин (1469–1518) чоры белән бәйләп аңлата. Ханлыкның чикләрен ныгыту нияте белән Кубань якларыннан нугайларны чакырган бу,– ди ул. Хәзер «Кала тавы» дип йөртелгән калкулыкта крепость та төзелгән булуын әйтә. Якташларым бу тарихның дөреслегенә шикләнми. Алла насыйп итсә, тарихыбызга карата материалларым байтак җыелды, авылыбызның тарихын язарга да өметләнәм.

Әмма шунысын да әйтеп китәм, без бала вакытта әбиләребез җыелып шушы Кала тавы дигән җиргә баралар, безне дә үзләре белән алалар иде. Андагы каберлекләр янына утырып «безнең борынгы бабаларыбыз монда яталар бит инде»,– дип дога кылдылар алар. Ел саен үткәрелгән бу җыенның үзенә күрә исеме дә бар, ул «Тегермән алды» дип аталган иде. Дөрес, тау итәгендә тегермән дә бар, күңелгә бер матурлык өстәп торган кебек кереп калган, аны «Җапый тегермәне»,– дип йөртәләр иде.

Шунысы куанычлы – болай җыелышып изгеләр рухына дога кылу әле дә уздырыла, тик нигәдер исеме хәзер, ялгышмасам «Әләшә» икән. Ни генә булса да, матур гадәт, оештыручыларга олы рәхмәтебез булсын.

Бераз читкә киттем. Кала тавы кальгасы Явыз Иван Казан ханлыгын җимергәч яшәүдән туктаган ахрысы. Яшәүчеләр төрлесе төрле җиргә күчкәннәр булса кирәк. Яңа Шимбер авылына да башта 9 гаилә күчеп утырган. Янәшәбездәге Иске Шимбер авылы Болгар чорында ук булган дияргә нигез бар. Аның борынгы исеме «Мирәтәк»,тик ни кызганыч, тарихчыларның да, археологларның да безнең якка килеп ныклы тикшеренүләр үткәргәннәре юк. Бәлки бу өлкәдә дә фән өчен кызыклы материаллар табылыр иде, һичшиксез.

Шәҗәрәбезне төзү өчен мәгълүматлар эзләгәндә 1716 елда үткәрелгән сан алу (Ландратская перепись) материалларына юлыктым. Борынгы бабабыз Кормаш Аймәковны таптым. Димәк, XVIII гасыр башында туган авылым Яңа Шимбер документларга мөстәкыйль рәвештә керерлек авыл булган икән. 1719 елгы материалларда да Казан өязе Алат юлындагы авыл дип күрсәтелә.

Авылыбызда элегрәк яшәгән өлкәннәр сөйләгәннәргә игътибар итсәк, Яңа Шимбернең яңа җирдәге бәхете бик озакка бармаган дияргә була. Дөрес, Колмак чишмәсе, Алан елгасы бергә кушылып (авылның көнбатыш өлешендә) мул сулы Шимбер елгасына әверелгәннәр һәм елга халкыбызның ихтыяҗын канәгатьләндерә алган. Авылыбызның зур тегермәне дә (әле дә урынын танып була), урманы, җиләкле, чикләвекле урыннары да җитәрлек булган.

Бик озакка бармаган бәхетләре. Казан ханлыгы җимерелүгә авыл җирләрен тартып алып Курск өлкәсеннән русларны күчереп утырканнар. Бу рус авылы Атамыш дип атала иде. Хәзер юк диярлек. Бер йорты калган иде, хәзер ничектер. Авылым кешеләрен, башта 17 хуҗалыкны, мәҗбүри мари авылларына күчереп утырткaннар. Икенче тапкыр (архивта бар) күчерелгән кешеләр саны 104 кеше дип күрсәтелә.

Авылның көнбатышыннан сузылып киткән нарат урманы да киселеп беткән. 1718 елда Казанда Адмиралтейство корылып, агачлар шуның төзелешенә киткән дип сөйли иде өлкәннәр. Авыл кешеләре шул төзелешкә беркетелгәннәр. Урман кисү эшенә 15 яшьтән 60 яшькә кадәр ирләрне 6 айга (1 октябрьдән 20 мартка кадәр) куганнар. Киселгән агачларны Казанга кадәр атлар белән тарттырып алып барганнар. Менә шулай җирсез, авыр хезмәт белән, туганнарыннан аерылып яшәгән авылым халкы.

Бер генә җөмлә белән авылыбыз Казан губернасы, Царевококшай өязе, Күәм (Киме) волостьларына кергәнен күрсәтеп үтәм.

Шулай таланып, талкынып яшәсә дә чукынмаган авылым. Монысы да архив документларында күрсәтелгән. Хуҗалык саны 123–125 йорттан артмаган. Бу саннарны елларга аерып күрсәтсәм, мәкаләм озынга китә.

Аннан соң I Бөтендөнья сугышы, революция вакыйгалары, тагын сугышлар. Авыл читләрендә казылган окопларның чокырлары әле дә күмелеп бетмәгән, эзләре билгеле.

1920–21 еллардагы ачлык, тиф, янгын,– берсе дә авылыбызны читләтеп үтмәгән. Вәрига әбием бу вакыйгаларны күз яшьләресез сөйли алмый иде. Ачлык вакытында әтиемнең әтисе – Сәфәргали бабай авыл Советы рәисе булган икән (комиссар дип йөртелгән). Ул кешеләр өчен ризык сорап Казанга, хәтта Мәскәүгә барган. Әмма 1921 елда ачлыктан 18 яшьлек балалары – Шәмсетдин абый, 1922 елда үзе үлгән. Урыннары җәннәттә булсын. 1921 елда авылыбызның яртысыннан артыгы янып беткән. Ничек аякка баса алган авыл, кайдан көч тапкан, Аллаһе Тәгаләбез генә беләдер.

1931 елның 27 маенда авыл кешеләре берләшеп «Таң нуры» исемле колхоз төзегәннәр. Беренче рәисе – Искәндәров Сафа, хисапчысы – Биктимиров Гәрәй булган. Колхоз төзелгәндә хуҗалыкта атлар, сыерлар бергә туплап асрарлык каралтылары булмаган әле. Нәкъ менә шушы вакытта авыл кешеләре гафу ителмәслек ялгышлык эшләгәннәр. Авылыбызның мулласы Камалетдинның улы, бай тормышлы Әхмәтгалинең бөтен каралтыларын тартып алганнар алар. Муллабызны, Әхмәтгалине бөтен гаиләләре белән Магнитогорскига сөргәннәр (бу хакта газетабызга «Кичер безне хәзрәт» исемле мәкалә язган идем).

Дөрес, бу хәлләр район түрәләре, алай гына түгел, илдә барган сәясәт аркасында килеп чыккан. Әмма кайбер җирләрдә муллаларны саклап кала алган бит кешеләр, аларга рәхмәт. Ә безнең муллабыз – 1873 елдан алып үз вазыйфасын намус белән үтәгән Камалетдин Хөснетдинов, сөрелгән. Дүрт мәртәбә качкан ул Магнитогорскидан. Соңгы качуында авылга кайткан, әче салкында капкасы төбендә утырып өшеп үлгән. Раббем, кичер, бу фаҗига да тетрәндерә бит.

Тарихка Бөек Ватан сугышы исеме белән кергән котычкыч сугышта 109 авылдашыбыз һәлак булган. Җаннары җәннәттә булсын. 1946 елда авылда 90 йорт булган әле. 90 йортлы авыл өчен 109 кешесен югалту...

Соңрак колхозларны берләштерү башланды. Түбән Көек, Иске һәм Яңа Шимбер авыллары «Тельман» исемле колхоз оештырдылар. Хуҗалык амбарлары, ферма биналары Түбән Көеккә күчте. Авылда башлангыч мәктәп (элекке мәчет бинасында), уку йорты гына калды. Яшьләргә клуб та калмады. Урта мәктәп – Күлле Кимедә (бездән 8 км), Әтнәдә (12 км) урнашкан иде. Җәяү йөреп, юк-бар өс-баш белән интегеп укучылар аз булды. Яшьләр шулай төрле төзелешләргә, шахталарга, урман эшләренә язылып китә тордылар. Авыл шулай бетү хәленә житте.

Дөрес, Яңа Шимбердә туган, Республикабызның Эчке эшләр министры булып эшләгән Әсхәт Әхмәт улы Сәфәровның тырышлыгы белән

2003 елда авылга асфальт юл салынды. Рәхмәт, авылыбызның бу баласына. Тик юл да хәлне үзгәртә алмады. Авыл шулай акрынлап бетәрме, калырмы? Кем белә?

Әдәбият:

1. Дерюжев И. О. Очерк 290-летнего состояния г. Царевококшайска и его уезда 1584–1874 гг., помещенный в Казанских губернских ведомостях 1876 г.

2. НА РТ. Ф. 2. Оп. 2. Д. 273. Л. 181.

3. НА РТ. Ф. 299. Оп. 1. Д. 211. Л. 4, 33, 57, 60.

4. НА РТ. Ф. 324. Оп. 733. Д. 10.

5. РГАДА, Ф. 350. Оп. 1. Д. 141. Л. 454–457 об. Ландратская перепись 1716 г. Книга переписная ясачных крестьян (татары, русские) Алацкой дороги.

6. РГАДА, Ф. 350. Оп. 2. Д. 1082. Ревизская сказка Казанского уезда Алатской дороги Борисовских Атар. 1719 г.

7. РГАДА, Ф. 350. Оп. 2. ч. 1. кн. 1176 (IIIревизия), 1762–1764 гг., л. 1–885. Сказки о мурзах и служилых татарах в ведении Адмиралтейства, Алатской дороги Казанского уезда.

8. Шпилевский С. М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии. – Казань, 1877. – с. 478–487.

БАУЛЫ РАЙОНЫ ИСЕРГӘП АВЫЛЫНЫҢ ӘҮЛИЯ КАБЕРЕ ТУРЫНДА

З. Г. Хәбипова

Аннотация: *Мәкаләдә Баулы районы Исергәп авылында урнашкан Әүлия кабере дип аталган каберлекнең килеп чыгышы турында яңа фараз китерелә. Авторның уйлавынча, «Идегәй» дастанында сурәтләнгән Туктамыш ханның Аксак Тимердән җиңелгәннән соң эзәрлекләүдән качу күренеше моңа нигез була ала. Исергәп авылы бик борынгы юл өстенә урнашкан. Авыл нигезләнгәнче үк аның урыны аша Урта Азия якларына, далага күп юлаучылар үтеп йөргән. Шуларның берсе качып баручы Туктамыш хан булуы да ихтимал.*

Төп сүзләр: *Әүлия кабере, Исергәп авылы, ям йорты, «Идегәй» дастаны, Туктамыш хан, билгесез каберлекләр, олы гәүдәле кешеләр, атның тормышта әһәмияте*

* * *

Баулы районының Исергәп авылы – минем туган авылым. Кояш чыгышында Ык әрәмәсе, көньякта калын урман, кояш баешында тау асларыннан мул сулы чишмәләр бәреп чыккан гаҗәеп матур урынга урнашкан ул. «Зур түгел, инеш кенә» булып аккан Томбарлы елгасы безнең авылга кергәч, чишмә сулары белән туенып, күзгә күренеп мул сулыга әйләнә һәм Ыкка барып кушыла. Элек хәтта атлар йөздерәләр иде инешебездә.

Менә шундый урынга килеп утырганнар авылга нигез салучы беренче авылдашлар. Бер тарихи документта бу 1749 елда булган дип күрсәтелә. Авылга нигез салган кешеләрнең башлыгы Исергәп исемле булган һәм кеше исеменнән аталып киткән башка авыллар кебек үк, безнең авыл да шушы исемне үзенеке иткән.

Исергәп... сыендыручы, яклаучы мәгънәсендәге сүз икән. Исеме җисеменә туры килгәнме, әллә авылның урнашкан урыны бик уңайлы булганмы, авыл үскән, зурайганнан зурая барган.

1751 елда авылда 15 ир-ат теркәлгән, җанисәп алуга ни өчендер хатын-кызлар кермәгән.

1795 елда 35 ихатада 229 кеше яшәгән.

1834–42 елларда 530 дан артык кеше исәпләнгән .

1859 елда кеше саны 942 гә җиткән.

1917 елда авылда барлыгы 2578 кеше яшәгәнлеге билгеле. Бу чорда өч мәчетле, базарлы авыл булган инде Исергәп.

Башта күченгән халык Балтач дип исемләнгән калку урынга (икенче исеме – Башкорт ягы), елганың сул ягына күпләп утырса, аннан соң күченеп килүчеләр елга аша җирләргә йортлар салган. Бу урамны Казаннан күченгән кешеләр нигезләгән дип исәплиләр, элек тә, хәзер дә урамны Казан кешесе урамы дип йөртәләр.

Исергәптә урамнар халык сөйләмендә Олы урам, Күпер төбе, Чыпчык, Ур, Әтәмби, Чишмә дип аталып йөртелә. Йортларга газ кертү вакытында авылның паспортын ясарга кирәк булды һәм шул вакытта кайбер урамнар үз исемнәрен документта югалттылар. Әтәмби һәм Чыпчык урамнарын кушып Ленин урамы дип яздылар, Казан кешесе урамы Казан урамы гына булып калды, ә Олы урам һәм Күпер төпләре Советская булып язылды. Ур урамын документта Родниковая дип атаганнар. Тарихи исемнәр аста калып, гадәти «совок» өскә чыкты, әмма халык, урамнар турында сүз барганда, аларны элеккечә атауны дәвам итә.

Авылның төзелешенә күз салсак – ут-күздән саклану өчен урамнар киң итеп алынган, һәр 3–4 йорт арасында елгага төшә торган тыкырык калдырылган, ул тыкырыклар үтәли йөрешле булып, һәркем елгага, я чишмәгә иң кыска юлдан чыга алган. Елга буйларын, чишмәләрне даими чистартып торганнар, суга сукмак беркайчан да өзелмәгән. Безнең татар авыллары йорт тирәләрендәге чисталык, тәртип белән аерылып торалар, йортлар да төрлечә бизәлгән, буялган була. Бу – халкыбызның гасырлар буена тупланган уртак яшәү тәртибе.

Авылның урнашкан урыны гади генә түгел – ул борынгыдан Урта Азия якларына, Бохарага йөри торган юл буенда. Бу юлны Ефәк юлы дип тә, Нугай юлы дип тә йөртәләр. Археологлар табылдыкларга карап, бу юлдан кешеләрнең Мисыр фиргәвеннәре заманында ук йөргәннәре турында әйтә. Бохара, Сәмәрканд якларына күп аяклар таптаган юл икән бу юл. Ныклап тикшергән очракта, әллә нинди серле табылдыкларга да юлыгырга мөмкиндер. Юл төзүчеләр җир казыганда борынгы чүлмәкләр тапканы, аны чүп бит бу дип ватып ташлаганы турында үземнең дә ишеткәнем бар. Эчендә алтыны булса гына табылдык кыйммәтле дип уйлый бит хәзерге адәм баласы.

Авылны нигезләүчеләргә бу борынгы юл, әлбәттә,таныш булган. Ныклап урнашкач, кыш көннәрендә ирләр атлар белән Троицк, Оренбург Бохарага алыш-биреш белән йөргәннәр. Ул яктан мамык җеп, кипкән җимеш, чәй алып кайтып сату иткәннәр. Исергәпкә дә төрле яктан сәүдәгәрләр килү очраклары булган. Дөягә мал төяп бохаралылар килгәнен, кәрванның ваба чире калдырып киткәнен дә яхшы хәтерлиләр иде авылда.

Исергәпнең һәр өендә диярлек туку станоклары булган. Халык тукучылыкны бик дәртләнеп үзләштергән. Хатын-кызлар мамык җептән кызыл

башлы чүпләмле сөлгеләр, ашъяулыклар, башка өй кирәк-ярагы тукыганнар. Туку өчен киндер, йон җепләр дә файдаланылган. Йон тукымадан тула оек, тупас киндер тукымадан капчыклар, торыпшалар теккәннәр (Торыпша – әйбер каплау өчен кулланыла торган зур җәймә). Болар барсы да базарга сатуга да чыккан. Әбиләребез тукыган сөлге-ашъяулыклар үткәннәрнең истәлеге булып әле дә күпләрдә саклана булыр. Әлбәттә авыл халкында тукучылыктан тыш башка һөнәр-кәсепләр дә булган. Бу турыда аерым язарга кирәк. Ә тукучылык турында кыскача тукталып үтүем сәүдә мөнәсәбәтләренең авыл халкы тормышына нинди үзгәреш керткәнен искәртү өчен генә. Революция, гражданнар сугышы, ачлык еллары сәүдә юлларын япса, утызынчы елларда югарыдан кушу буенча,туку станокларын җыеп яндырганнар. Шулай итеп халыкта тукучылык һөнәре юкка чыккан.

Авылыбызның тарихын бераз яктыртканнан соң, бер истәлекле урын турында язып үтим.

Томбарлы елгасының Ыкка коя торган тамагыннан ерак түгел сул ярында, калкулыкта, Изгеләр зираты (Әүлия кабере) дип аталган урын бар иде. Бу урын сабан туе юлына якын булганга , ул бик яхшы хәтердә калган. Ак ташлар белән әйләндереп алынган зур түгәрәк иде ул. Уратып алган җирнең эчендә агач юк, үлән генә үсә, анда җирдән чыгап торган ташлар да бар иде кебек. Картлар сөйләве буенча, элеккедә кешеләр бу урынга килеп дога кылганнар, теләкләр теләгәннәр. Ат авырса, кабер тирәсен җиде тапкыр әйләндереп, сәламәтләнүен өмет иткәннәр.

Каберлек урнашкан калкулык бер гектар чамасы җирне били. Ул кояш чыгышында сөзәкләнеп Томбарлы елгасына килеп терәлә. Авыл урамнары калкулыктан кояш баешына сузылган. Элек таулыкны авыл яклап елга буеннан чокып, таш чыгара торган булганнар. Авылда шуннан чыгарган таштан салынган Арыслан байның зур келәте бүген дә исән. Таш чыгаручылар каберлеккә таба казыган. Казыганда кеше сөякләре чыккач, ул юнәлештә казуны туктатканнар дигән сүзләр дә бар. Әмма, бүген таш чыгарган кешеләрнең берсе дә исән булмау сәбәпле, бу сүзләрнең дөреслеген белеп булмады.

Еллар үткән. Дәһрилек чоры изге урыннарны кешеләр хәтереннән җуеп алган. Зират урыны игътибарсыз калган, кайберәүләр бу урынга һәм елга буена чүп түгә башлаганнар. Картлардан кемдер тавыш күтәргән: бердән елга буе, чүп түгәргә ярамый, икенчедән – бу бит борынгы Әүлия каберлеге. Трактор китертеп, чүпләрне күмәргә булганнар. Тракторчы ничек күмә инде? Тау башыннан туфракны эттереп аска төшерә. Шунда трактор көрәгенә зират урыны да эләгә, әйләндереп алган ташлары чүп белән бергә этелеп, урыны җир белән тигезләнә. Бу илленче-алтмышынчы елларда була.

Тагын еллар үтә. Халык дингә кайта башлый. Изгеләр зиратын онытмаган картлар, аның урынын билгеләп, чикләп куярга кирәк дигән карарга киләләр. Бу 2002 елда була. Авылдашлардан Тимерханов Варис, Вәлиуллин Мәскап, Минниәхметов Хаҗиәхмәт һәм Дәүләтов Наил агайлар оештыралар бу изге эшне. Бүген борынгы зират бераз кечерәеп калган, тимер койма белән әйләндереп алынган, истәлек ташы куелган бер каберлек булып тора.

Оештыручыларның берсе Хаҗиәхмәт ага Минниәхмәтов бүген дә исән. Хаҗиәхмәт ага авылның әлеге зиратка якын очында яши. 91 яшь булса да хәтере бик яхшы аның. Борынгыда Ык буенда зур сугыш булганын, бу зиратка шул сугышта һәләк булганнар күмелгән дип картларның сөйләгәнен дә яхшы хәтерли ул. Нинди сугыш, кайчан булган – бу турыда төгәл генә белүче, сөйләүче булмаган. Шуңа тарих белән кызыксынучылар арасында төрле фаразлар бар. Алар турында бераз соңрак тукталырбыз.

Безнең авылга кешеләр 18 гасыр башында килеп урнашкан дип исәпләнә. Бу архивта сакланган документлар буенча. Борынгы каберлекләр, җирдән чыккан төрле табылдыклар шулай ук документ булып тора бит. Ә алар безнең авыл урынында бик күптәннән тормыш кайнаганы турында сөйли. Мисалга, Хаҗиәхмәт ага кешеләр җирләнгән борынгы каберлекнең авыл тирәсендә бер генә булмаганы турында әйтә. Ул тагы ике урынны күрсәтте. Бер каберлек бөтенләй билгеләнмәгән була. Колхоз фермасы өчен силос базы казыган эшчеләр күп кенә кеше сөякләренә тап булалар. Бу кешеләр безгә караганда олы гәүдәле булганнар, сөякләре бик зур иде дип искә ала Хаҗиәхмәт агай. Бу урын әлегә кадәр тикшерелмәгән һәм ташландык хәлдә тора.

Икенче борынгы зират хәзерге Тукай урамының бәрәңге бакчалары артында була. Бу зиратны 1950 нче елларда сөреп, икмәк басуына кушалар.

Хәзер инде Изгеләр зираты турындагы фаразларга тукталып үтик.

Исергәпләрнең бер нәсел тарихын җентекләп тикшергән һәм ул турыда китап язган Марсель Гарипов бу урынга Пугачев явында катнашкан җитәкчеләрдән берәү күмелгән дип бара.

Икенче фараз ераграк чорларга карый. Виталий Козлов каберлекне болгар һәм кыпчак кабиләләре арасындагы сугыш белән бәйли. Имеш, шул сугышта Идегәйнең дәвамчысы булган Әүлия исемле гаскәр башлыгы һәлак булган. Сугышта үлгәннәр белән бергә ул да күмелгән урын бу. Шуңа зиратны Әүлия каберлеге дип тә атап йөрткәннәр. Үзем Әүлия исемле гаскәр башлыгы турында мәгълүмат тапмадым. Татарча әүлия, изге – бер мәгънәдәге сүзләр бит инде. Һәр ике фаразга каршы шуны

гына әйтеп була – каберлек борынгырак чорда барлыкка килгән булырга тиеш. Изгеләштерү өчен борынгылык, легенда кирәк.

Өченче фаразга нигезне безгә «Идегәй» дастаны җиткерә. Дастан нәкъ менә Ык буйлары һәм анда булган сугыш турында бик ачык сөйли бит. Бәлки безнең авылның Изгеләр зираты (Әүлия кабере) барлыкка килү шул сугыш белән бәйләнгәндер? Әсәрне җентекләп укып карыйк әле.

Белгәнебезчә, «Идегәй» дастаны чыңгызыйлардан булган Туктамыш хан һәм аның гаскәр башлыгы Идегәй арасындагы көрәш турында сөйли (XIV нче гасыр азагы, XV нче гасыр башы). Туктамыш хан үзенә хезмәт итүдән баш тарткан өчен Идегәйнең атасын үтерткән була. Туктамыш ханда хезмәт иткән Идегәй, моны белгәч, Аксак Тимер ягына качып китә. Аксак Тимер белән Туктамыш хан арасында зур сугыш була. Идегәй сугышта Аксак Тимер ягында катнаша. Туктамыш хан гаскәре җиңелә. Яу кырыннан качып китәргә дучар ителгән Туктамыш хан сыену урыны эзләргә мәҗбүр була. Дастанда качып барган ханның яшеренер өчен урын эзләве түбәндәгечә бирелгән:

Болгардаен калам бар,
Болгар йортын алырмын,
Болгарда да тынмасам,
Куе урманның төбендә
Куерып аккан Ашыт су,
Кара урманым төбендә
Каралып аккан Казан суы
Казан суының буенда
Капкасы биек таш Казан,
Ул каламны алырмын;
Инде анда да тынмасам,
Чулманны кайта кичәрмен,
Җүкә Таудан үтәрмен;
Җүкә Тавым аръягы –
Ышыктан аккан Ык суы,
Аның да чыгып башына
Даладан дала үтәрмен.

Әлеге юллар Туктамышның уенда төзелгән яшеренү планы. Бик яхшы белә ул бу төбәкне. Әгәр картаны күз алдына китерсәк, качып баручы Туктамыш башта үзен Болгарда, аннан Ашыт суы буенда, Казан каласында һәм бераздан ышыктан аккан Ыкка сыенып барып, далага чыгып киткән итеп күзаллый. Уенда күзаллый. Дала чиксез, кем аның һәр

почмагын күргән-белгән, дөрес бит. Ахыргы уе – далага чыгып, шунда бераз югалып тору, көч җыю хан күңелендә өстенлек ала һәм ул Ык ягына борыла:

Азамат ир Туктамыш
Качып барып ятканда,
Чулманны кайта кичкәндә,
Ыкның башы – җил башы,
Җим далага җиткәндә,– дип әйтелә.

Бераз уй очышын да кушып ул заманнарда ничек юл йөргәннәрен күзалларга тырышып карыйк. Юлчының төп таянычы ат булган, билгеле.

Йөгереклеге сыналган,
Куш йөрәкле яралган
Тукмак яллы туратым
Үз астымда булганда,
Идегәй мине куганда,
Айлык юлым алдан алырмын.

Тын океаннан Әдрән диңгезенә кадәр сузылган Бөек даланы менә шулай куш йөрәкле атлар белән, әйтерсең очкычка утырып үткәннәр ата-бабаларыбыз. Юл йөрү өчен тирә-якның аерым билгеләрен, төсмерен, үсемлекләрен, тауларын, елга- күлләрен сыйфатына тәңгәл атамалар куеп хәтердә калдырганнар. Дастан үз геройлары аяк баскан һәр төбәкне төгәл сурәтләп, хәтергә сеңәрлек итеп тасвирлап бирә: Сары тау, Җүкә тау. «ышыктан аккан Ык», «җим дала» (җим – азыклы, үләнле мәгънәсенә), «Ыкның башы – җил башы» .

Шушы җиргә җиттем дә, «Бу бит безнең, нәкъ безнең Ык буйлары турында»,- дип әйткәнемне сизми дә калдым. Җилле булган өчен нәкъ безнең Ык буйларын хәзер Оренбург трубасы дип йөртәләр дә инде. Кайбер елларда шундый көчле җилләр исә ки, ул түбәләрне кубарып, очыртып алып китә. Безнең Баулы төбәгенең бу сыйфаты да дастанда теркәлеп калган икән.

Ык буеның калын әрәмәсе, андагы сусыл үләнле тугайлар, кош-кортлы дистәләгән күлләр – һәммәсе атлы кеше өчен туктап ял итәргә дә, кирәк икән качып ятарга да менә дигән җай урын. Артыннан куа килгәннәрен сизгән Туктамыш хан шулай итә дә – Ык буе әрәмәсенә кереп чума.

Ку күлленең күлендә
Кау камышта ятканда
Туктамыштай зур ханның
Дөрселдидер йөрәге.

Әйе, куе камышлар белән әйләндереп алган, аккошлар йөзгән (ку-аккош) төнбоеклы гүзәл күл дә бар иде безнең әрәмәдә. Урнашкан урыны да Әүлия кабереннән ике чакырым көнчыгыштарак иде. Дастандагы бөтен тасвирлауларның шулай туры килүе, безгә Туктамыш ханны саклап барган гаскәр белән аны куа килүче Идегәй яраннары арасындагы сугыш нәкъ менә Ык белән Томбарлы елгалары арасында булган дип фаразларга мөмкинлек бирә. Һәрхәлдә, дастан безгә шуны җиткерә.

Дастан – әдәби әсәр. Ул тарихны көне- сәгате белән тулысынча кабатламый. Бу фаразда кимчелек тә бардыр. Чөнки без Аксак Тимер белән Туктамыш арасында сугышның ике тапкыр булганын, икесендә дә Туктамышның җиңелгәнен беләбез. Ә дастанда бер генә сугыш очрагы турында әйтелә. Әмма бөтен нечкәлекләренә кадәр безнең төбәк сурәтләнүе һәм халыкның каберлектә борынгы сугыш корбаннары күмелгән дип хәтерләвенә таянып, бу урынга Туктамыш-Идегәй чоры сугышчылары күмелгән дип фаразларга була. Халык хәтерендә Идегәйнең халыкны яулаучы батыр буларак сакланганын да беләбез. Аның күмелгән урыны дип фаразланган Нарыстау – бүген изгеләштерелгән урын булып тора. Шуңа Әүлия каберлегенең дә Туктамыш хан – Идегәй сугышчыларына нисбәтле булуы бик мөмкин. Бу фаразны көчәйтеп тагын бер фикер әйтеп үтик: мөгаен каберлек авылга кешеләр килеп утырганчы ук булгандыр. Калкулыкка урнашкан, ташлар белән әйләндереп алынган урын үзенән – үзе монда изге кеше(ләр) җирләнгән дигән уй барлыкка китерә бит.

Туктамыш хан, Идегәй чорларын дөрес күзаллау өчен ул заманда ничек юл йөргәннәренә кабат әйләнеп кайтыйк әле.

Баулы якларында авыллар нигезләү турында сүз чыкканда, без аны XVII–XVIII гасырларда булган дип әйттек. Ләкин Исергәп аша үтүче Нугай юлы беркайчан да буш булмаган. Чагыштырсак, юл – үз заманының төбәкләрне бәйләүче хәзерге электрон челтәр вазыйфасын да үтәгән әле. 1332 елда нык зурайган Татар иле (Борынгы карталарда «Великая Тартария») белән идарә итү өчен ям хезмәте кертелә (почта). Ул хәбәр йөртүче чапкыннарга, илчеләргә, хакимият кешеләренә хезмәт күрсәткән. Ямда 20ләп кеше хезмәт иткән, алмаш атлар һәрвакыт әзер торган, шунда ук мөсафирханә һәм юлчыларны ашату өчен бер көтү сарык булган. Болар барсы да халыктан алынган дип яза Адлер Тимергалин. Ям йортлары арасын чапкын бер көндә үтәрлек итеп (50–60 чакырым), сулы, болынлы урыннарга урнаштырганнар дип уйларга кирәк. Безнең Исергәп авылы урынында да ям йорты урнашкан булуы бик ихтимал, урыны бик уңай бит. Зур гәүдәле кеше сөякләре табылу да, авыл урынын бик борынгыдан төрле ыру-кабилә кешеләре үз иткәннәре турында сөйли түгелме?

Һәрхәлдә, галим-археологлар арасында безнең яклар белән кызыксынып, ачыклык кертүчеләр табылыр дип өметләник.

Ниләр генә күрми ир башы да, ат башы дигән сүз бар халыкта. Мең еллар буена бөтен эшләр ат белән эшләнгән. Ат – шушы чиксез дала киңлекләрен иңләүче ирләрнең армас-талмас корабы да, җилкәне дә булып хезмәт иткән кешегә. Ат бик акыллы хайван: ул хуҗасына тугрылыклы, сизгер, сак, үткән юлны бик яхшы хәтерли. Бөек Дала халыклары үз яшәешләрен атка атланып – аркаланып-таянып корганнар. Халыкларның зур күчеше фәкать ат ярдәмендә генә мөмкин булган. Төбәкара сәүдә атлы кешеләр Далада ныклы тәртип урнаштыра алгач кына барлыкка килгән. Далада ат иярли белмәгән халыклар өчен дөнья ябык, ул үз төбәге белән генә чикләнгән.

Бездә атның кешелекне үстерүдә тоткан роле турында мәктәп дәреслекләрендә бөтенләй сөйләнелми, махсус фәнни хезмәтләр дә юк дисәм, ялгышмам кебек. Кешелек өчен юл йөрүдә, йөк ташуда, җир эшкәртүдә, башкача әйткәндә транспортта һәм энергетикада революцион үзгәрешләр керткән «Ат тарихы», иксез-чиксез өйрәнелмәгән тема булып кала бирә.

Без – дөньяны атлы иткән кавем – үзебезнең күп казанышларыбызны өйрәнмичә, белмичә, хәтерләмичә яшибез. Дастан бу бушлыкны тутыра. Ул безне узган атлы тормыш турында хәтерле итә, илләр төзергә ашкынган ир-егетләрнең кайларда башларын салып, ятып калганнарын да безгә җиткерә.

Әдәбият:

1. Идегәй дастаны. Казан, 1994.

2. Тимергалин А. Миллият сүзлеге: Аңлатмалы сүзлек.– Казан: Мәгариф, 2007.

3. Тридцать поколений мусульман от Салмана ходжы до Хабиповых. Составитель – Марсель Гарипов. 2010.

СЕМИПАЛАТИНСК ТАТАРЛАРЫ

И.Г.Гомәров, И.Г.Закирова

Семипалатинск/Семей татарларының тарихы белән кызыксына башлавыбыз буш урында барлыкка килмәде. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты 2016нчы елда беренче тапкыр Россия Федерациясеннән читтә яшәгән татар халкының рухи мирасын өйрәнүгә багышланган комплекслы экспедиция оештырды. Без – Институт галимнәре, Казахстанның Семей (Семипалатинск) өлкәсе татарларының рухи мәдәниятен, тел үзенчәлекләрен, гореф-гадәтләрен өйрәндек. Экспедиция материалларын барлаганда, Семейда яшәүче милләттәшләребезнең тормышы, тарихы турында күбрәк белергә теләп, Октябрь революциясенә кадәр чыккан материалларны барлый башладык. Бу мәкалә шушы эзләнүләр нәтиҗәсендә язылды.

Семей шәһәрнең яңа исеме, ул озак вакытлар Семипалатинск исеме белән мәгълүм. Татарлар шәһәрне «Сими» дип атаганнар. Октябрь революциясенә кадәр чыккан татар вакытлы матбугатында һәм тарихи хезмәтләрдә шәһәр исеме еш телгә алына һәм аның Җидепулат, Семипулат дигән вариантлары да очрый. Шәһәрнең өч гасырлык тарихында татар халкының да күркәм урыны бар. Татарлар Семипалатинскига крепость буларак нигез салынган көннән анда яши башлаганнар һәм бүгенгә кадәр дуслык, бердәмлек, тырышлык үрнәге булып торалар.

1917–1920нче елларда Казахстан Республикасының башкаласы булган Семипалатинск шәһәренең тарихы 1718нче елдан ПетрI нең көнчыгыштагы җирләрне саклар өчен ныгытмалар төзү турындагы указы белән башланып китә. 1714–1720 еллар арасында төзелгән ныгытмаларның берсе Семипалатинск була. Хәрби чик буе ныгытмасы буларак төзелгән крепость 1718елда сафка баса, һәм тиздән Россия, Казахстан, Урта Азия һәм Көнбатыш Кытай арасында мөһим сәүдә ноктасына да әверелә. Семипалатинск төзелә башлауга бирегә сәүдә эшләре дә җанланып китә, 1728елдан халыкара сәүдәне махсус төзелгән таможня контрольгә ала.

Семипалатинскига беренчеләрдән булып килеп урнашкан татарларның күбесе сәүдәгәрләр була. Бу хакта мәгълүмат Н.А.Абрамов хезмәтендә дә саклана. Ул Семипалатинск крепосте салына башлагач бирегә драгуннар, солдатлар һәм казаклар, алардан да алдарак, руслар килгәнгә

кадәр, сәүдә өчен килеп урнашкан татарларның һәм ташкентлыларның аерым бистә булып урнашуын яза.

Бирегә татарлар Казан, Вятка губерналарыннан, Төмәннән күченгәннәр. Аларның кайсы бәхет эзләп килеп чыкса, күбесе авыр тормыштан, 25 еллык солдат хезмәтеннән качып килеп чыга. Октябрь инкыйлабыннан качып, Кытайга күчеп барган юлларыннан тукталып, биредә төпләнеп калган гаиләләр дә булган.

Семипалатинскиның зур сәүдә үзәге булуы, биредә яшәүче татарларның озак еллар төп шөгыле сәүдә булу шул чорга караган язма чыганакларда да теркәлгән. В. В. Радлов Семипалатинскиның Көнбатыш Себернең Кыргыз (казах) далалары һәм Көнбатыш Кытай арасындагы сәүдә үзәге булуын, һәм нигездә сәүдәнең җирле татарлар кулында булуын яза. Галим татарларның бирегә Көнчыгыш Россиядән күчеп килүләрен, соңгы чорларда шәһәрдә татарларның шактый артуын да искәртә. Семипалатинскида халыкара сәүдәнең җанлы булуына, биредә һәрвакыт Төркстаннан һәм Кытайдан килгән дөя карваннарын, Азия мәмләкәтләреннән килгән кешеләрне күрергә мөмкин булуына тарихчы-галим Г. Н. Потанин да игътибар итә. Галим йөк төягән дөянең – чүл корабының шәһәрнең мөселман Шәрык илләре белән сәүдә бәйләнешләренә ишарәләп өлкәнең гербында да күрсәтелүен яза. Дөрестән дә, Семипалатинскиның 1851 елда расланган гербында йөк төялгән дөя, аннан өстәрәк ай белән йолдыз сурәтләнгән була. Америкалы Джордж Кеннан да Семипалатинскның бөтен кыргыз далалары өчен мөһим сәүдә үзәге булуын, аның Ташкентка, Урта Азиягә китә торган сәүдә кәрваннары юлында урнашуын яза.

Татарлар Семейдә нигездә сәүдә белән шөгыльләнә. Семипалатинск шәһәренең Кытай, Урта Азия, Себерне бәйләп торган сәүдә юллары кисешкән уңайлы урында утыруы сәүдә эшләренең шактый тиз җанланып китеп, сәүдәгәрләргә аякка басарга булышкан. Тиздән Семипалатинскның атаклы сәүдәгәрләрен Россия генә түгел, ерак чит илләр, беренче чиратта Европа да таный башлый. Биредә яшәгән атаклы сәүдәгәр – меценатлар, үз чорының алдынгы карашлы кешеләре буларак тарихка кереп калалар. Семипалатинскиның беренче гильдия татар купецларының исеме хәзергә кадәр саклана. Күбесе милләтнең, халыкның белемле-мәдәниятле булуы өчен тырышкан фидакарь затлар булып, кыйблалары байлык туплау булмыйча, фән-белемгә омтылып яшиләр, балалары Европа уку йортларында белем ала. Шунысы да игътибарга лаек, Семейдә яшәүче татар эшмәкәрләре бу традицияне дәвам итә. Гомумән, бу төбәктә яшәгән татарларның төп сыйфаты ярдәмчеллек, кешелеклелек булган. XX гасыр башында Семипалатинскида 70 хәйрия оешмасы булуы һәм аның эшен-

дә татарларның актив катнашуы моның ачык мисалы. Шәһәрнең мәчет-мәдрәсәләре дә иганәчеләр ярдәме белән төзелә һәм эшли.

1776 елда Себер генерал-губернаторлыгында Семипалатинскида яңа крепость төзү турында карар кабул ителеп, аны тормышка ашыру талантлы инженер И. Г. Андреевка тапшырыла. Аның җитәкчелегендә крепость, күперләр, юллар салына. Шул рәвешле, Семипалатинск шәһәренең салынуы әлеге талантлы шәхес исеме белән дә бәйле. 1782 елда крепость шәһәр итеп үзгәртелә.

Җидепулат исеменең килеп чыгуын риваятьләр төрлечә бәян итә. Тарихчылар Җидепулат топонимының килеп чыгуын Җунгар шәһәрчеге булган Доржинкиттагы (Цорджийнкийд) Будда храмнары белән бәйләп аңлаталар. Семей шәһәре янындагы җиде пулат-сарайның харәбәләре XVIII гасыр ахырына кадәр сакланган. 1734 нче елда тарихчы Г. Ф. Миллер бу пулатларның патша Михаил Федорович Романовның 1616 нче елдагы грамотасында «таш мәчетләр» дип искә алынуын яза.

Семипалатинскида татарлар шәһәрнең бер өлешендә аерым бистә булып яшиләр. Сәяхәтчеләр, тарихчылар бу бистәнең төзеклеге, татарларның нык тормышлы булуы белән башкаларга үрнәк булуын язалар. Мәсәлән, Н. А. Абрамов Вятка, Казан, Тубыл губернасының Төмән өязеннән күчеп килгән татарлар һәм ташкентлылар сәнагатьтә, бигрәк тә сәүдә эшендә булдыклы, эшлекле, тырыш һәм житеш тормышлы булуын яза.

Татар халкының нык тормышта, җитешлектә яшәвенә, чисталыгы-уңганлыгы, матур итеп яшәргә тырышуына күпләр игътибар итә. Казах халкының мәшһүр әдибе Абайның татар халкының яшәү рәвеше турында сокланып: «Нугайларга (татарларга) карыйм, алар яхшы сугышчы да була ала, авырлыкларны да күтәрә алалар, үлемне бер хак итеп кабул итәләр, мәдрәсәләрне саклыйлар, динне хөрмәт итәләр, эшлиләр дә, мал да туплыйлар, матур киенәләр, матур итеп күңел ачалар»,– дип яза.

Татарларның гыйлемлеге, белемгә омтылышы да халыкка булган хөрмәтне арттырган. Татарлар килә башлаган вакыттан биредә дә мәчет-мәдрәсәләр төзелә. Экспедиция вакытында информантларыбыз Семипалатинск шәһәрендәге ундүрт мәчетнең уникесе татарлар тарафыннан төзелүен, татар мәчете булуын хәзер дә горурланып бәян итәләр.

Семипалатинск мәчетләре турында төрле чорларга караган мәгълүматлар биредә төрле елларда яшәп киткән, яки килгән шәхесләрнең хезмәтләрендә саклана. Г. Н. Потанин Семипалатинскиның ике өлеш-

тән торуына, татар бистәсенең байрак, иркенрәк булуына игътибар итә. Шәһәрнең татар өлешендә манаралары белән аңа шәрык шәһәрләре кыяфәте биреп дистәгә якын мәчет урнашкан. Дөрес, барысы да агачтан салынган, бары атаклы архитектор Тон проекты буенча төзелгән бик матур бер мәчет кенә таш,– дип яза ул. Этнограф А. К. Гейнс Семипалатинскида 1865 елны булып, ул да шәһәргә биредә яшәгән мөселманнар һәм татар мәчетләре көнчыгыш кыяфәте бирүләрен билгеләп үтә. Ул: «Бу шәһәрдәге иң яхшы бина – Тон рәсемнәре буенча төзелгән мәчет. Мәчетнең архитектурасы искиткеч нәзакәтле һәм җиңел. Аның биек манараларыннан Ерактагы Семитауга кадәр бөтен Семипалатинск һәм аның тирә-ягы күренеп тора»,– дип яза. Шул ук вакыта А. К. Гейнс башка мәчетләрнең күпкә кайтыш булуын да искәртеп үтә. И. И. Завалишин 1864 елда шәһәрдә җиде мәчет булуын яза. Аның берсе, ике манаралы искиткеч архитектуралы таш мәчет, 1862 елда гына төзелеп беткән була. Бу истәлекләрдән күренгәнчә, бик хаклы рәвештә, Семипалатинск шәһәренең төп бизәге, иң күркәм бинасы булып озын – озак вакытлар шәһәрнең җәмигъ мәчете санала.

Тарихи мәгълүматларга караганда, бу мәчет 1858 елдан төзелә башлап, 1862 елга тәмамлана. Мәчет Семипалатинскиның татар сәүдәгәрләре Сөләйманов, Абдәшев, Рафиков һәм Халитов акчасына салына. Проект авторлары архитектор Болботов һәм инженер-поручик Манашев була. 1897 елда сәүдәгәр Халитов акчасына мәчеткә зур ремонт ясала һәм шул вакытта мәчетнең агач манаралары урынына кирпеч манаралар төзелә. Г. Н. Потанин да, А. К. Гейнс Семипалатинскиның җәмигъ мәчетенең архитектор Тон проекты яки аның рәсемнәренә нигезләнеп төзелүен язалар. К. А. Тон (1794–1881) – XIX йөзнең атаклы архитекторы, архитектурадагы «Рус-Византия стиленең» авторы, Император сәнгать академиясе ректоры, атаклы соборлар, тимер юл вокзаллары проектлары авторы. Мәскәүдәге Зур Кремль сарае да аның проекты буенча төзелә. Алдан искә алынган авторларның мәчетнең проект авторы буларак К. А. Тонны күрсәтүләре очраклы түгел дип уйлыйбыз. Архитектор Александр Болботов һәм инженер-поручик Манашев мәчет проектын К. А. Тон эшләрен файдаланып эшләгәнбулырга мөмкин. Мәсәлән, Семипалатискиның Христос терелү соборын Архитектор Болботов К. А. Тон проекты нигезендә, аны шәһәр өчен яраклаштырып эшли. Мәчет проектын эшләгәндә дә шушы ук алым кулланыла ала.

И. И. Завалишин хезмәтенә караганда, татар бистәсендә аерым квартал булып яши торган ташкентлыларның үзләренең аерым, башкалардан аерылыбрак торган мәчете булган. Шул рәвешле, шәһәрдә 1865 елларда сигез мәчет булып, аның җидесе татар мәчете, берсе ташкентлыларныкы

булуы аңлашыла. И. И. Завалишин таш мәчеттә ахун, башка мәчетләрдә муллалар хезмәт итүен дә билгеләп үтә.

Н. А. Абрамов 1861 елда чыккан мәкаләсендә Семипалатинскида ун мәчет булуын яза. Алдагы авторлар шул елларда сигез генә мәчет күрсәтәләр. Мәчетләрнең саны буенча Н. А. Абрамов биргән информация дөрес булырга тиеш. Ул мәчетләрнең ун булып, тугызы агач, берсе таш булуын яза. Әлеге автор Семипалатински турында һәр яктан төгәл мәгълүмат бирергә омтыла. Ерак Америкадан килеп чыккан сәяхәтче һәм журналист Джордж Кеннан да Семипалатинскиның Шәрык шәһәрләренә хас сыйфатларга ия булуын яза.

Бу истәлекләрне укыганда бер әйбер күзгә ташлана. Авторлар шәһәрнең башкалардан төзеклеге, ныклыгы белән аерылып торган өлеше буларак татар бистәсен күрсәтәләр. Татар бистәсенең күрке, аның башкалардан аерылып торган сыйфаты – татар мәчетләре, Семипалатинскиның ак чалмалы муллаларының намазга чакырган азаны. Бу бер чыганактан икенчесенә күчеп һәрберсендә кабатлана торган мәгълүмат.

Татарлар белемгә омтылышлары белән, мәгърифәтле булулары белән бу төбәктә яшәгән башка төрки халыкларга үрнәк булып торалар. Элек электән татар шәкертләре казах далаларына чыгып китеп, балалар укыткан, аларны укырга-язарга өйрәткән, дин сабаклары биргән. Семипалатинскида да мәчетләр белән мәдрәсәләр дә төзелгән. И. И. Завалишин XIX гасыр уртасында Семипалатинскида җиде мәчетнең дә мәдрәсәсе булуын яза. Мәдрәсәдә дә, мәчетләрдә дә татар кешеләре хезмәт куя. Мәдрәсәләрдә татар балалары гына түгел, казах, ташкентлыларның балалары да да белем алган. Казах халкының мәшһүр әдибе Абай да Семипалатинскида Әхмәт Риза мәдрәсәсендә татар мөгаллимнәрендә укый.

Н. А. Абрамов татар һәм ташкентлыларның балаларын укытуга зур игътибар бирүләрен яза. Ул малайларга гына түгел, кыз балаларга да белем бирүләренә дә игътибар итә. 1858 елга уку-укыту эшләренең статистикасы түбәндәгечә була: мәчетләр каршында ачылган җиде мәдрәсәдә (Н. А. Абрамов аларны «сельские школы» дип атый) 371 ир бала белем алган. Шуның өстенә мулла хатыннарында һәм өйдә 150 кыз бала укыган. Н. А. Абрамов татарларда һәм русларда укучы балаларның халык санына нисбәтен дә күрсәтә: православныйлар Семипалатинскида 4405 кеше булып, аларның укучы балалары 300 кеше. 14 кешегә бер укучы туры килә. Мөселманнар 3236 кеше булып, укучы балалар саны 520 дән артык булып, 6 кешегә бер укучы бала туры килә.

В. В. Радлов язуынча, мәктәп-мәдрәсәләрдә укытучылар татар кешеләре булган, укыту процессы да татар телендә барган, шуның нәтиҗәсе буларак, укый-яза белә торган казахлар да язу теле буларак татар телен кулланганнар, яки казах һәм татар телләрен кушып язганнар.

Татар халкы шәһәрдә нык тормышлы булуы белән, ә Татар бистәсе җитешлеге белән аерылып торган. А. Е. Врангель татар өлеше шәһәрнең иң зур мәйданында урнашуын яза. Ул татар өйләрендә тәрәзәләрнең ишек алдына каравына игътибар итә. Бу хатыннар һәм харәм (авторда: гарем) аркасында шулай,– дип яза. Автор «гарем» сүзе белән йортның чит күзләрдән сакланган хатыннар ягын атый. Һәр йорт биек койма белән әйләндереп алынган, алар хуҗаларның тормышын чит-ятларның кызыксынуыннан саклаган,– дип аңлата А. Е. Врангель биек коймаларның вазыйфасын. Әлбәттә, авторның сүзләрендә дә күпмедер өлеш хаклык бардыр. Әмма бу таш коймаларның төп вазыйфасы башка. Немец теленнән алынган сүз белән брандмауэр (ут+стена) дип атала торган бу ике метр чамасы биеклектәге таш коймалар, исемнәреннән үк күренгәнчә, уттан саклану өчен төзелә торган булган. Алар, тоташ агачтан төзелгән шәһәрдә пожардан саклаган, ут бер йорттан икенчесенә күчмәсен өчен киртә буларак төзелгән. Семей шәһәрендә аларның бүгенгә кадәр сакланганнары да бар. Йортлар нык, зур итеп салынган. Ике катлы, беренче каты таштан, икенче каты агачтан салынган йортлар Семей шәһәренең татар бистәсендә әлегә кадәр саклана.

Татар халкы эшен дә вакытында эшләгән, иманлы мөселманнар булулары белән дә тарихка кергән. Шул ук вакытта, Абай искәрткәнчә, алар матур итеп күңел дә ача белгәннәр. Әлбәттә, беренче чиратта иң зур бәйрәмнәр – Корбан һәм Ураза гаете булган. Бәйрәмдә бөтен мөселман халкы берләшкән, татарлар, казахлар һәм ташкентлылар белән бергәләшеп күңел ачкан. Бу бәйрәмнәрнең тәртибен, халыкның бәйрәм халәтен яратып, тәфсилләп Н. А. Абрамов сурәтли. Шушы хезмәт ярдәмендә узган гасырда ике гаетнең бөтенхалык бәйрәме буларак асылы ачыла. Н. А. Абрамов Корбан гаетендә һәр мөселман, гаилә әгъзалары һәм шул гаиләнең мәрхүмнәре санынча бер яшьтән ким булмаган берәр сарык, яки җиде кеше берләшеп, ике яшьтән ким булмаган сыер корбан итәләр,– дип яза. Бу юллардан аңлашылганча, гаиләнең һәр кешесеннән аерым корбан китерелгән. Хәнәфи мәзхәбе буенча, үзенең кереме булган һәр кеше үзе өчен корбан китерергә тиеш. Шәһәр мөселманнары бу кагыйдәне дә җиренә җиткереп үтәгәннәр.

Бәйрәм көннәрендә бай йортларда мул табын хәзерләнгән. Шушы бәйрәмгә бәйле рәвештә Н. А. Абрамов мөселманнарның йорт эченнән дә бераз мәгълүмат бирә. Идәннәргә бәйрәм көннәрендә Бохарада яки

Ташкентта тукылган келәмнәр җәелгән. Келәм өстенә ярты аршин биеклеге (35 см.) өстәл куелган. Өстәл өстендә бәйрәм ризыклары тезелгән. Сарачин бодае (ул заманда «сарачин бодае» дип дөгене атаганнар) ярмасына йөзем һәм өрек салып, атлан май белән пешерелгән пилау/пылау һәр табынга куелган. Итле пилмән, кыздырылган сарык ите дә бәйрәм ризыклары саналган. Н. А. Абрамов камыр ризыкларыннан һәм татлылардан бавырсак, Ташкент һәм Бохара прәннекләрен атый. Өстәлләргә куелган кипкән җиләк-җимеш һәм төрле чикләвекләрнең дә исемлеге зур: кара йөзем, сары йөзем, ак йөзем, өрек, пестә (фисташки) һәм бадәм (миндаль) чикләвекләре, ташкент чикләвеге(-фындык), кандалат(эре он кушып шикәрләнгән пестә). Эчемлектән чәй һәм кымыз эчкәннәр. Гает бәйрәмендә халык кунакка йөрешкән, туганнар, дуслар бер-берсен кунакка чакырганнар, хәл белешкәннәр. И. И. Завалишин алдан әйтелгән сыйлар янына казы, атлан май, бал да куелуын яза.

Корбан бәйрәменең бер күңел ачу чарасы – бәйге (ат чабышы) булган. Бәйге вакытында атка атланган 12–13 яшьлек малайлар Семипалатинскидан 30 чакрым китеп, шунда билгеләнгән бер урыннан бәйге башланган. Ярышта катнашкан атлар саны 30–40 чамасы булган. Финиш урыны да алдан, гадәттә шәһәргә дала ягыннан керү юлында билгеләнгән. Шунысы да игътибарга лаек, ярышучыларның артыннан озын таяклар тоткан дүрт кеше җитез атларга атланып баралар. Бу кешеләрнең максаты – ярышучыларга хәрәмләшергә мөмкинлек бирмәү, бәйгенең гадел булуын күзәтү. Бәйгене бөтен халык кызыксынып күзәткән, беренче килүчеләрне гөрләп каршы алган. Чабышкыларда җилдереп узган малайлар, үзләренең кем атына атланганлыгын кычкырып узып киткәннәр. Бәйгедә беренче тугыз урынга бүләк әзерләнгән. Шуннан чыгып бәйге бүләген дә «тугыз» дип атаганнар. Беренче бүләк сукно яки верверет (вельвет, бәрхет тукыманың бер төре), икенчесе бераз арзанрак бүләк булып, һәр соңгысы алдагысыннан арзанрак булган. Бүләккә шулай ук сукно, плис (бәрхет), ситсы һәм яулыклар да биргәннәр. Гает бәйрәмнәрендә бәйгедән башка да, затлы ияр салынган атларга атланган малайлар урамнар буенча чабып йөргән.

Бәйгедән соң татар, казах һәм ташкентлылар батырлары арасында көрәш башланган. Көрәшне мөселман халыклары гына түгел, рус халкы да яратып тамаша иткән. Бәйрәм көннәрендәге көрәшне карарга 3000 тирәсе халык җыелган.

Өч көн дәвам иткән Ураза гаетен һәм Гает бәйрәмнәре көннәрендә уза торган көрәш Америка журналисты Джордж Кеннан хезмәтендә бәян ителә. Көрәш шәһәрнең көнчыгыш ягында узган. Көрәш мәйданы диаме-

тры 30 фут чамасы (1 фут – 30,48 см, димәк 9 метрдан артыграк) мәйданда барган. Аның әйләнәсен тамашачылар урап алган. Алдагы ике-өч рәт халык чүмәләп утырса, аннан соңгы 3–4 рәт халык басып караган. Аннан соңгылар көрәшне атка атланган килеш тамаша кылган.

Тамашачылар ике лагерьга аерылган, татарлар да, казахлар да үз көрәшчеләренә көч биргән, алар өчен җан аткан. Көрәш белән яшел халатлары белән башкалардан аерылып торган, камыш таяк тоткан дүрт кеше, Дж. Кеннан сүзләре белән атаганда, церемониймейстер, җитәкчелек иткән. Аларның икесе казах һәм икесе татар булган. Ике татар башта үз ягыннан көрәшчене сайлап алган, аның өстенә озын эзәр ташлаганнар (Дж. Кеннанда – sash/кушак дип бирелә. Дж. Кеннан белән көрәшне караган художник Жорж Фрост ясаган рәсемдә көрәшчеләрнең билендә эзәр сурәтләнә) һәм көрәшчене аренага чыгарганнар. Шуннан соң казах ягы татар көрәшчесенә каршы, буе һәм авырлыгы белән туры килгән, үз көрәшчеләрен мәйданга чыгарган. Шуннан соң гына көрәш башланган.

Дж. Кеннан көрәшне җентекләп бәян итә. Беренче көрәшчеләр зәңгәр түбәтәй кигән, кызыл эзәрле, сакал-мыексыз яшь матур кыргыз (ул вакытта казахларны кыргыз дип атау очрый) һәм нык, атлет төзелешле сары түбәтәйле, яшел эзәрле татар була. Бер минут чамасы алар бер берсен сынап карап торалар, шуннан соң гына бер берсенә ябышалар. Һәрберсе бер кулы белән икенчесенең билбавына ябышса, икенче кулы белән көндәшен ныграк эләктереп алырлык урын табарга тырыша. Алар берсенә башлары белән терәлеп, гәүдәләрен билдән туры почмак ясап бөгеп, аякларын киң итеп аерып басалар. Шул рәвешле бер берсенә нык итеп ябышып, бөтен мәйданны урап чыгалар. Казах егете көндәшен аяк чалып егарга тырышса, татар көрәшчесе аны көче белән басарга тырыша. Икесенең дә муеннарындагы, маңгайларындагы тамырлары бау кебек бүртеп чыккан, маңгайларыннан тир тама. Шулай да, көчләре тигез булып берсе берсен күтәреп ала алмыйлар. Шул вакыт татар, көтмәгәндә артка сөрлегеп, үзе белән казах егетен дә тарта, соңгысы тигезлеген югалтмас өчен бер адым алга атларга мәҗбүр була. Шул арада татар көрәшчесе аягына тибеп, шул тибүдән югалып калган кыргыз егетен күтәреп ала да, баш аша күтәреп тә ташлый. Дж. Кеннан үзләренең 4–5 сәгать көрәш карауларын яза. Алар мәйданнан киткәндә дә көрәш дәвам итеп кала. Автор көрәштә татарларның ныграк әзерлекле булуы, әмма көрәшчеләр арасында бернинди үпкә дә, усаллык та булмавына, гомумән көрәшнең гаять мәрхәмәтле асылына, бернинди харәмләшүләрнең күзәтелмәвенә, көрәшчеләрнең көлешеп-шаярып аралашуларына да игътибар итә.



Татарская борьба. (Siberia and the Exile System – Vol. 1 by George Kennan, London, 1891. S. 165).

Семипалатинскида булган шәхесләрнең истәлекләрендә ике гает бәйрәме генә түгел, күпмедер гаилә йола бәйрәмнәренә дә урын бирелә. Мәсәлән, ташкентлыларның туй йоласы А. Е. Врангельнең «Ф. М. Достоевский турындагы истәлекләр» дигән китабында искә алына. Туйда ирләр аерым, хатын-кызлар аерым бәйрәм иткән. Хатын-кыз ягында-

гы туйны автор «хатыннар бәйрәме» дип атый. Туйның өйдә хатыннар бәйрәмен сыйдырырлык бүлмәләр булмау сәбәпле, ишек алдында узган. Җиргә затлы келәмнәр түшәлгән. Хатын-кызлар, чадраларын салып, төркем-төркем булып аякларын бөкләп утырганнар. Автор аларның сөйләшмичә генә утыруларын яза. Бу күренеш хатыннар туе өчен гадәти күренеш булмыйча, аларның ике таныш булмаган ир кеше күзәтү аркасында, оялып-тарсынып утыруларының нәтиҗәсе дип фараз итәбез. Һәрхәлдә, хатын-кызлар, әгәр алар аерым утыра икән, сөйләшүдән, көлешүдән, күңел ачудан тыелмаслар иде.

Н. А. Абрамов татар халкының күңелле, җанлы булуын аерым искәртә. Ирләр өчен аерым бәйрәм ясалган. Кәләш туйда катнашмаган, ул өч көн дәвамында ике дус кызы белән чоланда утырган һәм ураза тоткан. Туй өч көн дәвам итеп, дүртенче көнне генә кияү килгән. Ирләр ягында ахун дога укыганнан соң, поднос тотып килгән кунакларны йөреп чыгалар һәр кеше туйга бүләген – көмеш тәнкәләр сала. Шуннан соң кияү кәләшне үзенә алып китә. Бу китапта сакланган мәгълүматлар буенча, ташкентлыларның татарлар белән тыгыз аралашып яшәве, аларның берсенең дә үзләрен аерып куймавы аңлашыла. А. Е. Врангель ташкентлыларның туй мәҗлесендә 150 татар хатыны чакырылуын яза. Бәйрәмнәрдә ташкентлылар да, татарлар да бергә булган, шуңа күрә күп кенә авторларның аларны мөселман халыклары дип берләштерүе дә очрый, кайбер очракларда ташкентлыларны да татарлар исемлегенә кертәләр, һәм киресенчә татарларны да ташкентлылар белән бутау очраклары булган.

Н. А. Абрамов хезмәтен укыганда татар хатыннарының тагын бер күңел ачу чарасы булуын күрәбез. Хатын-кызларның җәй көне җыелып, берничә тарантас һәм арбаларга төялеп, шәһәрдән ерак түгел урманга барып, ял итү йоласы булган. Алар үзләре белән самоварлар, төрле ризыклар алып барып, көне буе табигатьтә күңел ачканнар. Автор бу күңел ачулар вакытында бернинди шәригатькә ярамаган гамәл кылынмаганны, гомумән татар хатын кызларының намуслы һәм тәрбияле булуын да искәртә. Хатын-кызларның җәен табигатькә чыгу гадәте Завалишинның да игътибарыннан читтә калмаган. Ул татар хатын-кызларының компания булып, шәһәрдән читтә, урманда яки берәр утрауда, иртәнге уннан кояш баеганга кадәр, күңел ачуларын яза. Бу күңел ачуларга ирләр катнашу тыелган. Бары кече яшьтәге ир балаларны гына алганнар. Алар чәй эчкәннәр, татлылар ашаганнар. Әлбәттә автор хатын-кызларның ашау-эчүдән башка нинди шөгыльләре булуын белә алмый. Шулай да алар анда төрле уеннар уйнаганнар дип фараз итәбез.

Гомумән, татар халкында «табигатькә чыгу» күренешен аерым бер йола буларак карарга да мөмкиндер. Ул татарлар яшәгән регионнарда та-

ралган күренеш була. Безнең көннәргә кадәр телдә «сәхрәгә чыгу» һәм «сәелгә чыгу» дигән гыйбарәләр килеп җиткән. «Сәхрәгә чыгу» кояшлы җылы көнне гаилә белән яки бер төркем кешеләрнең табигатькә чыгуын аңлата, «сәелгә чыгу» да мәгънәсе белән якын, ул язын, көннәр җылыткач, күмәкләшеп табигатькә чыгып күңел ачуны белдерә. Бу күренешнең эзләре татар дастаннарында да саклана. Мәсәлән, «Кузы Көрпәч белән Баян-Сылу» дастанында кызларның сәхрәгә чыгып күңел ачуы тасвирлана. Шушы ук дастанда кызларның сәхрәгә чыгып төрле уеннар уйнаганы да тасвирлана.

А. Е. Врангель Семипалатинскида халыкның бәйрәм уңаеннан күңел ачу чараларын бәян итә. Бу – 1855 елның 30 августында Александр Невскийның исем көнен бәйрәм итү. Исем көне Патша Александр II нең дә исем көне белән туры килү сәбәпле, Семипалатинск халкы бу бәйрәмне зурлап, халык күңел ачулары буларак билгеләп узган . Беренче чиратта, хәрбиләр парады оештырылган, барлык хәрбиләр молебендә катнашкан. Шәһәрнең бердән бер скверы булган «Казак бакчасында» алар өчен парад ашы әзерләнгән.

Бу көнне казахлар халыкның күңелен ачу өчен бәйге – ат чабышы оештырганнар, халык аларның бөркет белән бүре аулаганын да тамаша кылган. Бөтен халык, Себер тамашасын – Иртеш буенда оештырылган «йодрык сугышын» карарга җыелган. Бу күңел ачуларда бөтен милләтләр бергә булган. Руслар һәм татарлар, кайсы җәяүле, кайсы атка атланып, ике отряд булып бүленгәннәр. Шунысын да искәртергә кирәк, ике халык ике төркемгә аерылмаган, һәр төркем төрле милләтләрдән оешкан. Шуннан соң, бернинди корал кулланмыйча, бары йодрыклар ярдәмендә бер берсенә һөҗүм итә башлаганнар. Атлылар җәяүлеләр арасына барып кереп, берәрсен әсирлеккә алганнар һәм әсирләрен шундук Иртеш елгасына атканнар. Елгадан коенып менеп, алары да яңадан сугышка кергән. Бу тамаша катнашучылар өчен дә, караучылар өчен дә күңелле булып, шау-шу, көлке белән барган. Тамашачылар кишмиш, өрек, чикләвек ашаган. А. Е. Врангель бәйрәм, бигрәк тә йодрык сугышы турында, «бөтен дөнья хәрәкәттә, көлә, шаяра, шаулый»,– дип яза.

Күпчелек авторлар, бәйрәмнәргә мөнәсәбәтле рәвештә, халыкның шул чордагы көндәлек һәм бәйрәм киеменә дә игътибар итә, бигрәк тә татар хатын-кызларының киеме турында язмалар кызыклы.

Александр Невскийның исем көне уңаеннан җыелган тамашачылар арасында татар һәм казах хатын-кызлары да күп була. Семипалатинскида хатын-кызлар халык күңел ачуларында катнашкан, бәйрәмне тамаша иткән. А. Е. Врангель бу бәйрәмдә үзләренең киемнәре белән татар һәм казах хатыннарының башкалардан аерылып торуына игътибар итә. Шул

ук вакытта, татар хатын-кызлары бөркәнчекле була. Мәсәлән, Н. А. Абрамов татар халкының гәүдә төзелеше нык, дөрес, кием-салымы күркәм, йөзләре матур булуын яза. Татар хатын-кызлары йөзләрен каплап йөргәннәр. Бу максаттан, зур шәлъяулык белән башларын томалаганнар, яки баштан ук халатлары (күлмәк өстеннән кия торган өс киемен халат дип атаганнар) белән бөркәнгәннәр. Хатын-кызларның бөркәнчекләре эченнән кигән бәйрәм киемнәрен барон Врангель тасвирлый. Туйга килгән хатын-кызлар чадраларын салалар. Алар кыйммәтле ефәктән тегелгән һәм алтын җеп (канитель) белән чигелгән затлы күлмәкләр кигәннәр. Күлмәк астыннан киң шароварлар да күренеп торганын искә алганда, күлмәк артык озын булмаган дип уйларга мөмкин. Дөрес, Врангель үзе дә кыска күлмәк дип искәртә. Әмма ул чор өчен кыска күлмәк җирдән бер-ике куләяссы гына өстәрәк тә булырга мөмкин икәнен онытырга ярамый. Әлеге заман татар хатын-кызлары өчен бизәнү дә чит булмаган. Хатын-кызлар мәҗлесләргә барганда битләренә пудра сөрткән, кершән ягынган, тырнакларына кына яккан. Алар битләренә «мушкалар» да куйганнар. Н. А. Абрамов та татар хатыннарының пудра, кершән куллануына, кашларына сөрмә тартуга игътибар итә. Н. А. Абрамов татарларның һәм ташкентлыларның бәйрәм киемнәрен дә тасвир итә. Гает бәйрәмендә мөселман ирләр кыйммәтле ефәк халатлар кигәннәр. Татарлар ак чалма ураган, ташкентлыларның чалмалары чуар булган. Ирләрнең өс киеме булган бәйрәм халатлары төрле ачык яки ачык чуар төсле тукымалардан тегелгән. Хатын-кызларның күлмәкләре парча, канфа (тыгыз, калын кытай атласы), ефәк тукымалардан тегелгән. Күлмәк якалары һәм күкрәге алтын һәм ефәк белән чигелгән, бу чигешләрдә энҗе дә кулланганнар.

Безнең көннәргә кадәр килеп җиткән материаллар, әлбәттә, Семей татарларының тарихи үткәнен тулысынча чагылдыра алмый. Шул ук вакытта, аларда татар халкының тормышын-көнкүрешен төрле яктан яктырталар. Бу язмаларда Семипалатинск татарларының сәүдә эшләре, аларның хәйриячелек эшчәнлеге бәян ителә. Татар халкының мәгърифәтлелеге, балаларын белемле итәргә омтылуы, мәктәп-мәдрәсәле, динле-иманлы булуы башка халыкларда да ихтирам уяткан. Халык эшләп кенә яшәмәгән, матур итеп күңел ачканнар. Шул ук вакытта халыкның чисталыгы, тәртипле булуы, югары әхлагы да без искә алган авторларның игътибарыннан читтә калмаган.

Семипалатинск татарлары иҗтимагый тормышта да актив булган. XX гасыр башында Семипалатинскида татарлар белән бәйле берничә зур вакыйга була. Шуларның берсе татар кешесенең очу аппараты ясап күккә күтәрелеүе. Октябрь революциясенә кадәр чыгып килгән вакытлы матбугатта Семипалатинск татарларының тормышын һәм эшчәнлеген

яктырткан мәкаләләр еш басылган. Мәсәлән, «Шура» журналында Семипалатинскида татар кешесенең очуы хакында берничә мәкалә басыла. Бу вакыйганы тулырак күзаллау өчен 1914 елда журналның тугызынчы санында Закирҗан Алхановбастырган мәкаләдән өзек китерәбез: «Менә бер көнне бөтен Сими халкы сәгатьче Галинең кош булып очканын карарга ашыгалар, Сими елгасы янына хатын-кыз, бала-чага, бай-ярлы, яшькарт һәммәсе ашыгып-ашыгып җыелалар иде. Күп тә үтмәде, сәгатьче Гали аргамакка утырган үзенең каегын арбага салыб килеп тә җитте.

Каек үзе зурлыгында (эченә Гали әфәнде кереп сузылыбрак ятканда сыярлык), канатлары синкәдән[1], каекның гәүдә вә канатлары һәртөрле төскә буялган. Канатларының хәрәкәткә килүе – мотор урынына куйган тәгәрмәчләр аркылы – кул белән әйләндереләчәк иде. Ул, тауның башынарак туктап, каекка сикереп менде дә канатларыны селкеп 15 сажиннар чамасы биеклектән очып та китте. Елганың аръягына барып төште дә, бераз туктап чәчәкләр җыйнап каегына салып, кире очып чыкты һәм шул вакытта ук өенә кайтып китте,– дип Хәкимҗан әфәнде Гаффаров үзенең бала вакытында күргән ошбу вакыйганы сөйләп исемне китерде». Шушы ук елда «Шура»ның унберенче санында Р.Ялкибай «очучы татар» турында икенче мәкалә бастыра. Автор татар халкының никадәр талантлы булып та, эшен күрсәтә белмәвенә ачына: «Монда тәәссеф (үкенеч) ителәчәк урын шул: бу эшләрнең һәммәсенә Гали әфәнде фәкать уен итеп караган. Кирәкле эшкә тәтбикъ итү (яраклаштыру) ягын бердә уйламаган. Шулук коралны ихтираг кылган австрияле нимсә (немец) исә, үз ихтирагы өчен хөкүмәттән ничә меңнәр алган, зур мәбләгъ (сумма) бәрабәренә хәрбия нәзарәтенә (хәрби оешма) сатып үзенең истикъбалене (киләчәген) тәэмин иткән. Безем мохтәригъ (уйлап табучы) Гали – сабын кайнатып сәнгый (ясалган) бал ясап көн күрәдер!»

Икенчесе, Семипалатинск татарларының футбол командасы оештырып, ярышларда катнашуы.

Семипалатинск, хәзерге Семей шәһәрендә татар халкы элеккедән килгән традицияләрне саклап яши. Татарларның Россиянең төрле төбәкләреннән Семипалатинскига күчү процессы XX йөзнең беренче чирекләренә кадәр дәвам итә.

Совет дәверендә югары уку йортын тәмамлап, юллама белән килгән белгечләр дә, чирәм җирләрне үзләштерү вакытында килгән яшьләр дә киң далага, шундый ук киң күңелле халыкка гашыйк булып, биредә төпләнеп калган. Җиде пулат якларында Идел буе татарлары яши. Гасырлар дәвамында себер татарлары да шактый күченгән Семипалатинск якларына. Әмма аларның теле казан татарлары тәэсирендә әдәбиләшкән,

[1] Синкәдән – цинк белән ялтыратылган калай.

халыкның хәзерге сөйләше әдәби телгә якын, татар теленең көнчыгыш диалекты үзенчәлекләре азрак сакланган. Хәзерге вакытта телдә казах теленең йогынтысы да сизелә. Казах теленнән кергән аерым сүзләр еш кулланыла, «ч» һәм «ш» авазлары алмашы күзәтелә.

Татарлар берничә гасыр дәвамында күчеп, Идел буен, Казанны сагына-сагына төпләнеп калган. Шунысы да бар, бер тапкыр да Татарстанга килмәгән апалар-абыйлар, Идел буен, Татарстанны үзенең Ватаны дип саный, бу җирләрне сагынып яши. Совет дәверендә Казан белән Семипалатинск арасы бик «якын» булган. Туганнарына кунакка гына килеп яшәп калган Казан кызлары да күп очрады биредә. Хәзерге вакытта да кыз алмашу, туганлашу процессы дәвам итә.

Татарлар шәһәрдә генә түгел, авылларда да яши. Иркен далаларда киң урамлы татар авылларына нигез салына. Хуҗалыкның нигезен игенчелек, терлекчелек тәшкил итә. Һәр авылда дистәләгән җил тегермәннәре куелган. Тирә-яктан он, ярма тартырырга килгәннәр.

Татарлар бүгенге көндә нигездә Семей шәһәрендә яши. Татар авылларының күбесе беткән. Калган авыллар хәзерге вакытта катнаш татар-казах авыллары. Мәктәпләрдә уку казах телендә. Хәтта татар авылында татар эшмәкәрләре салган мәчетнең тышындагы элмә такталардагы язулар да бары казах телендә генә булуы күңелдә бераз канәгатьсезлек тудыра. Әмма биредәге татарлар бу күренешкә башкача карый. Алар кардәш халыкның мөстәкыйльлеген, үзен саклап калуын, сүзен әйтә алуын хөрмәт итәләр. Шуны да әйтергә кирәк, ике халык сокланырлык рәвештә дус яши. Бер-берсенә хөрмәте зур. Аерым йолалар, бәйрәмнәр уртак булып, аларның кайсы халыкта башлангыч алганын да әйтеп булмый.

Хәзерге вакытта Семей татарлары бөтен йолаларны үтәп, мөмкин кадәр телне саклап, бер-берсенә булышып, дус-тату яши торган зур бер диаспора. Шәһәрдә Татар иҗтимагый үзәге эшли. «Халыклар дуслыгы» бинасында урнашкан Татар иҗтимагый үзәге каршында милли музей бар. Аның җитәкчесе Шәүкәт абый Фәйзуллин Семей татарларының, аерым шәхесләрнең тормышына караган, рухи дөньясын чагылдырган бай материал тупланган.

Шулай да, Семей шәһәре татарларын беренче чиратта җыр, татар көе берләштерә, халыкны нәкъ менә җырга-моңга мәхәббәт саклый сыман тоелды миңа. Ә бу җыр-моңның башында милләтпәрвар Габдулхак Ахунжанов тора. Габделхак абый 1992 нче елда «Татар сәнгать мәктәбе» ача. Зур тырышлык белән аның дәүләт карамагындагы мәктәп булу статусын саклап кала. Биредә балалар төрле уен коралларында уйнарга өйрәнәләр, җырлыйлар, төрле халыкларның биюләрен башкаралар. Татар сәнгать мәктәбендә татар балалары гына түгел, руслар да, казахлар

да, башка милләт балалары да белем ала. Татар моңы, татар җыры аша татарча өйрәнәләр. Татар халкының гореф-гадәтләре торгызыла, саклана. Әлеге мәктәптә белем алучы балалар Казахстаннан тыш, Россиядә дә, якын һәм ерак чит илләрдә дә чыгышлар ясап, мәртәбәле урыннар алалар. Кайберләре укуларын чит илләрдә дәвам итеп югары музыкаль белем алалар. Әмма алга таба кайда гына булсалар да, аларның бирелгән тәрбиясе, белеме тормышта һәрвакыт кирәк. Габделхак Ахунжанов укучыларында музыкага мәхәббәт кенә тәрбияләп калмый, ул аларда үз-үзенә һәм башкаларга хөрмәт, үз көченә ышану, хезмәткә мәхәббәт, авырлыклар алдында туктап калмау кебек сыйфатлар тәрбияли. Мәктәп каршында Габделхак Ахунҗанов оештырган балалар ансамбльләре эшли. Без Семейдә балаларның җәйге каникуллары вакытына туры килдек. Шулай да «Күңелле балачак» ансамбле кызлары – Эльдана, Рената, Дильдана һәм Снежана безгә берничә җырларын башкардылар. Бишенче-алтынчы классларда укучы кызлар татар халык җырларын да, казах җырларын да яратып башкаралар. Кызларның күбесе мәктәпкә килгәндә бөтенләй җырламаган. Көйсезләрне дә көйләп һәм көйле итеп була икән. Габделхак Ахунжанов үз методикасы белән бөтенләй җырламаган балаларның да тавышын ача, көйне ишетергә, тоярга өйрәтә.

Семей шәһәрендә зурлар өчен «Иртеш моңнары», «Истәлек», балалар өчен «Гөрләвек», «Күңелле балачак», «Илһам» ансамбльләре эшләп килә. Семейда 2000 елдан «Көзге Иртыш моңнары» дип исемләнгән Халыкара татар сәнгате фестивале үткәрелә башлаган. Ул да Габделхак Ахунжанов башлап җибәргән чараларның берсе.

Семейда бик күп кешеләр белән аралаштык. Яңа дусларыбыз, яңа танышларыбыз артты.Семей татарлары белән очрашу бездә соклану, якты тәэсирләр уятты. Татарстаннан, Казаннан еракта татар мәдәниятенең зур бер үзәге булып яши торган милләттәшләребезнең тормышына, көнкүрешенә сокланып, алар өчен сөенеп кайттык. Биредә халык традицияләрен, әби-бабаларыбызның гореф-гадәтләрен, рухи-мәдәни хәзинәләребезне яшь буынга, оныкларына, балаларына туган телебездә тапшыралар. Семейдәге милләттәшләребез милли йөзләрен, туган телен саклап яшәве зур ихтирамга лаек.

ПИСЬМО С ФРОНТА

Г. Г. Хафизов

Ключевые слова: *Великая Отечественная война, Сталинград, письмо с фронта, Республика Татарстан, исторический источник*

Сталинградская битва вошла в историю как одно из грандиозных сражений Великой Отечественной войны (19 ноября 1942–2 марта 1943 гг.). Известно, что еще до осенних ожесточенных боев ставка Верховного Главнокомандования СССР разработала план сокрушительной наступательной операции, которая была направлена на окружение и разгром основных сил фашистских войск под Сталинградом. Огромный вклад в подготовку этой грандиозной военной компании, получившей название «Уран», внесли выдающиеся полководцы: Г. К. Жуков и А. М. Васильевский. Для решения поставленных задач были создаваны три новых фронта: Юго-Западный (командующий Н. Ф. Ватутин), Донской (командующий К. К. Рокоссовский) и Сталинградский (командующий А. И. Еременко). 19 ноября 1942 г. началось наступление Юго-Западного и Донского фронтов. Спустя сутки начал наступать Сталинградский фронт. Наступление фронтов развивалось молниеносно, и уже 23 ноября 1942 г. произошло соединение Юго-Западного и Сталинградского фронтов, в результате чего около 330 тыс. вражеских солдат и офицеров под командованием генерал-фельдмаршала Паулюса оказались в окружении. Судьба немецко-фашистских и союзных группировок была предрешена.

На Сталинградском фронте и в боях за Сталинград сражались наши земляки. 14 ноября 1942 г. из Казани в Сталинград был отправлен эшелон с новомобилизованными, где оказался наш земляк Нурмухаметов Ахмед Нургалеевич, который принял непосредственное участие в Сталинградском сражении и погиб там как герой.

Ахмед Нургалеевич родился и вырос в деревне Татарское Исламово Нурлатского района Татарской республики (ныне Зеленодольский р-н Республики Татарстан). Его последнее письмо, отправленное своему отцу, рассказывает о тяжелом положении на фронте, о настроении воинов накануне великих сражений.

Письмо из семейного архива Нурмухаметовых написано на основе арабской графики и требует определенных навыков и знаний правил чтения рукописных текстов. Тескт дается в современной графике.

Орфография текста сохранена.



17. XI. 1942 ел.

Сезгә хөрмәтле вә мәрхәмәтле булып торган кечкенә углың Әхмәттән, гәзиз Әткәем хәзрәтләренә бик сагынып вә бик саргаеп бик күп сәләм теләп калам вә минем сеңлем Кафиягә кечкенә абыегыздан бик сагынып бик күп сәләм һәмдә Мәрьямгә һәр ике баласына янә бик сагынып бик күп сәләм теләп калам һәмдә сеңлем Мөршидәгә һәр ике баласы иләндә бик сагынып бик күп сәләм вә хәмдә тирә-күршеләргә һәр барчаларынада аермача бик күп сәләм диярсез. Сәләм соңында үзем бүгенгә исән-саумын һәмдә без киттек Сталинградка, сугышта калырга һәм барып җитәргә утыз чакрым, әгәр исән булсам, исән чыксам икенче хатны адресы белән салырмын, пока миннән бүтән хат көтмәгез, исән калсам адресын салы-

рмын һәмдә мәгълүм булса Кәримдән һәм Габдулладан хат киләме, алар исәнме,алар хәлен бик беләсем килә һәмдә Хак абый миннән калган иде, аны да алмаганнар микән,мин аның янында кечкенә идем һәмдә эткәем шушы саваплы чак догада торыгыз, исән булсам кайтырмын,исән булмасам бәһил булыгыз, язгучы Әхмәт.

Далее дается перевод письма на русский язык.

7 декабря 1942 г.

Вам с глубоким уважением и почтением пишет младший Ваш сын Ахмет, сердечный привет моему дорогому, достопочтенному отцу, младшей сестре Кафие от брата горячий, пламенный привет, также сестре Марьям и ее двум детишкам шлю сердечный привет, также сестре Муршиде и ее двум детишкам, также всем соседям персонально каждому мое почтение и большой привет. В завершение приветственных слов, о себе сообщаю, что я жив, здоров, едем мы в г. Сталинград, до линии фронта остается тридцать верст пути, если буду жив и останусь после битвы в живых, второе письмо отправлю с новым адресом, пока от меня каких-либо вестей не ждите, если останусь в живых, адрес свой пришлю. Хочу поинтересоваться у Вас о месте пребывания Карима и Габдуллы, где они? Живы ли, здоровы? Как у них дела? Также как дела у дяди Хак, когда я уезжал на фронт, он еще оставался в деревне, как у него дела? Не забрали ли его на фронт? Также в такое тяжелое, судьбоносное для нас всех время, прошу достопочтенного отца находиться в молитвах перед нашим Всевышним Аллахом. Буду жив, приеду, если не суждено, то прощайте. Ахмет.

Применение краеведения в школах.

ЭКСКУРСИЯ КАК СРЕДСТВО ИЗУЧЕНИЯ ИСТОРИИ РОДНОГО КРАЯ

А. Ф. Орлова

Аннотация: *В статье рассматривается школьное краеведение, как компонент исторического образования и как средство комплексного воспитания школьников. Автор указывает на важную роль экскурсии как учебно-воспитательного занятия, и один из методов, который направлен на получение знаний и приобщение учащихся к истории. Содержатся методические рекомендации по разработке и проведению краеведческих экскурсий.*

Педагог – это не только профессия, это социальный статус, которому соответствует поведение в обществе, образ жизни, гражданская позиция. Педагога всегда волнует судьба отечества, своего народа, своей земли. Современная социально-экономическая и политическая ситуация в стране выдвигает множество проблем, в том числе и проблему воспитания патриотизма, который, представая в качестве основы консолидации общества и укрепления государства, является одной из форм соподчинения личных и общественных интересов, единения человека и Отечества. В Законе Российской Федерации «Об образовании» одним из ведущих принципов государственной политики в области образования провозглашен принцип воспитания любви к Родине.

Вопросы воспитания молодежи в духе любви к Родине, воспитания достойных граждан государства, стояли в центре внимания ученых на протяжении всей истории человечества. Сейчас этот вопрос встает особенно остро, поскольку в обществе ощущается «дефицит нравственности».

Патриотизм, как базовая ценность, раскрывается в Федеральном государственном образовательном стандарте в разделе личностные результаты школьника и указывает на воспитание уважения к прошлому и настоящему многонационального народа России; осознание своей этнической принадлежности, знание истории, языка, культуры своего народа, своего края; воспитание чувства ответственности и долга перед Родиной.

Но почему же огромные усилия педагогов не всегда приносят желаемые результаты? Почему наши ученики часто покидают родные места и переезжают в мегаполисы? Основное противоречие патриотического воспитания заключается в том, что оно слабо связано с окружающей жизнью. Любовь к своей семье, своей местности необходимо развивать через деятельность. В этом вопросе наиболее действенным методом является экскурсия по родному краю.

Экскурсия – это специфическое учебно-воспитательное занятие, перенесенное в соответствии с определенной образовательной или воспитательной целью, из класса в какое-либо место: на предприятие, в музей, в поле и т. п. Образовательно-воспитательное значение экскурсий состоит в том, что они служат накоплению наглядных представлений и обогащению чувственного опыта учащихся; помогают установлению связи теории с практикой, обучения и воспитания с жизнью.

Экскурсии – это один из методов, который направлен на получение знаний и приобщение учащихся к истории предков, культуре, воспитание любви и гордости за вклад Малой Родины в историю страны. Экскурсионная работа должна быть тщательно подготовлена и спланирована. Каждая экскурсия должна преследовать определенные цели и задачи, проходить в назначенное время и носить развивающий, обучающий и воспитательный характер. Итогом экскурсии могут стать выпуски газет, выставок, проспектов. Материал, полученный в ходе краеведческой экскурсии, учащиеся могут использовать не только на уроках истории, в краеведческой работе, это могут быть комбинированные проекты разных дисциплин.

В зависимости от объектов наблюдения экскурсии можно классифицировать как производственные, природоведческие, краеведческие, литературные, географические и т. п. По образовательно-воспитательным целям они могут быть обзорными и тематическими.

Любой из видов экскурсий не является самоцелью, а входит в общую систему учебно-воспитательной работы. Заключительным этапом экскурсии является подведение ее итогов в ходе беседы с целью приведения полученных знаний в систему.

В настоящее время наиболее актуален вариант экскурсий для учащихся вместе с родителями, так как родители помогут учащимся в наиболее эффективном усвоении информации, полученной во время экскурсии, и пополнят свои знания новыми сведениями. Такие совместные акции полезны еще и тем, что идет распространение знаний среди населения. Современные молодые люди больше общаются и находят сведения в интернете, где слабо представлена краеведческая тема. В такой форме ра-

боты видится наибольшая продуктивность в воспитании патриотизма. О положительных результатах говорят отзывы родителей.

Литература:

1. Исторический опыт развития экскурсионного и школьного туризма – URL: https://e-koncept.ru/2015/95410.htm.

2. Методика историко-краеведческой работы в школе: Пособие для учителей / Под ред. Н. С. Борисова. М., 1982. Факультативный курс «Краеведение».

3. Першина Ю. В. Изучение исторического краеведения в 5–9 классах – ресурс духовно-нравственного воспитания личности – URL: http://www.schoolpress.ru/products/rubria/index.php?ID=68739&SECTION_ID=45.

4. Ривкин Е. Ю. Организация туристической работы со школьниками: Практическое пособие. – М., 2001.

5. Экскурсии. – URL: http://www.bibliotekar.ru/pedagogika-3-2/7.htm.

ТАТАР ХАЛЫК ЯЗУЧЫСЫ МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ МУЗЕЕ: ЭЗЛӘНҮЛӘР, ТАБЫШЛАР

Ф. К. Дәминова

Татар халкының сөекле язучысы Мөхәммәт Мәһдиевнең туган төбәге – Арча районы Гөбөрчәк авылында музей ачылуга 10 ел тулды.

2000 елда музей өчен язучының 1916 елда төзелгән йорты янәшәсендә район хисабына агач бина төзелеп бетте. Бу йортта язучының апасы Равия Сөнгатуллина яши иде. Музей экспозициясен төзү ТР Берләштерелгән Дәүләт музееның баш рәссамы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Ф. Зыязов, музейның фәнни хезмәткәрләре А. Хайруллина һәм Ф. Дәминовадан торган иҗат төркеменә йөкләнде. Музей нигездә язучының әдәби әсәрләренә таянып эшләнде.

Мөхәммәт Мәһдиев иҗатының үзенчәлеге – әсәрләрендә үз язмышын, тормыш юлын чагылдыруы. Аларда балачак хатирәләре белән бәйле әйберләр аеруча эчке җылылык белән тасвирлана. Язучының апасы белән әңгәмәдән соң әлеге әйберләрнең күбесе бүгенге көнгә кадәр сакланганлыгы мәгълүм булды. Алар арасында әтисенең таягы, әнисенең шкатулкасы. Арча педучилищесында укыганда йөрткән үзенең юл чемоданы да бар иде. Хәтта әтисенең балалары өчен үз куллары белән ясаган сәке дә сакланган. Мунча чардагында Сөнгатулла Баһаветдинов яздырып алган революциягә кадәр чыккан «Йолдыз» газетасы тупланмасы һәм М. Мәһдивнең шәхси китапханәсеннән автографлы китаплар табылды.

1968 елда «Казан утлары» журналы битләрендә М. Мәһдиевнең Арча педагогия училищесында укыган елларына багышланган «Без кырык беренче ел балалары» дип исемләнгән беренче повесте басылып чыга. «Фронтовиклар» романында да татар авылының Бөек Ватан сугышы чоры һәм аннан соңгы авыр еллардагы язмышы чагылдырыла. Аның әсәрләренең геройлары – туган авылының конкрет кешеләре. Болар һәммәсе дә экспозициядә язучының якташларына багышланган материаллар файдалануга этәрде. Шулай ук язучының бертуган абыйсы – фронтовик Рәшит Мәһдиев һәм тылда авыр хезмәттән саулыгын какшаткан апасы Рауза Мәһдиева материаллары да музейда урын алды.

Музейга материаллар туплау максатыннан Үзәк Дәүләт архивына да мөрәҗәгать иттек. Анда М. Мәһдиевнең әтисе Сөнгатулла Баһаветдинов турында документлар сакланган. Сөнгатулла хәзрәт Гөбөрчәк авылының мөхтәрәм мулласы була. Репрессия еллары башлангач, ул кайбер авылдашлары язган донос нигезендә кулга алына һәм шуннан инде яңадан

әйләнеп кайтмый. Аның барлык мөлкәте конфискацияләнә, гаиләсе яңа гына салынган зур йорттан иске йортка чыгарыла. 1953 нче елда (Сталин үлгәннән соң), Балтика флоты кече офицерлар курсында укыганда М. Мәһдиев К. Е. Ворошиловның амнистия турындагы указын укый һәм аңа хат юллый. Тиздән аны «Особый отдел» га чакырып әтисенең 1938 нче елда ук атып үтерелүе турында әйтәләр. Документлардан күренгәнчә, Сөнгатулла Баһаветдинов ахыргача үзен гаепле санамаган. Аның аянычлы язмышын чагылдырган документлар экспозициягә куелды.

Октябрь инкыйлабы һәм совет хакимияте урнашканнан соң, дәүләтнең дингә каршы сәясәте башлана: мәчетләр ябыла, манаралары җимерелә, дини әдәбият яндырыла, меңләгән дин эшлеклеләре бер гаепсез репрессияләнә һәм атып үтерелә. М. Мәһдиевнең әтисе белән бергә, Арча районының төрле авылларыннан берничә дистә мулла шулай ук репрессия корбанына әверелә.

Авыл кешеләре озак еллар өйләрендә дини эчтәлектәге китаплар сакларга куркып җиргә күмгәннәр, чардакларга яшергәннәр. Шулай сакланып калган китаплар музейда урын алды.

Музейның күп өлеше М. Мәһдиевнең тормыш юлына һәм иҗатына багышланган. Биредә аның армиядә хезмәт иткән чорына, студент елларына караган экспонатлар куелган. Экспозициядә язучының иҗат лабораториясен күз алдына китерергә мөмкинлек бирүче әйберләр – мемориаль өстәл, урындык, китап шкафы, өстәл сәгате, каләме, кульязмалары, китаплары урын алган. Музей экспозициясенең ахырында язучының каләмдәшләре, шәкертләре турындагы материаллар, аңа бирелгән күп санлы бүләкләр куелган.

Музей урнашкан бинаның бер өлешен авыл китапханәсе алып тора. Анда да М. Мәһдиев китаплары зур урын алып тора һәм авылдашлары тарафыннан яратып укыла.

Музей төзү – күмәк хезмәт. Бу очракта да музей хезмәткәрләренә язучының туганнары, авылдашлары һәрдаим ярдәм күрсәтте. Мәрхүм булган туганнары Равия апа белән Рәшит абыйга рәхмәтебез дога булып ирешсен. Музей экспонатларын туплауда зур ярдәм күрсәткән җәмәгате Лилия ханым Бәширова-Мәһдиевага, район җитәкчеләре Ринат әфәнде Фазлыйәхмәтовка, Наил әфәнде Назыйровка һәм авылдашларына, якташларына ихлас рәхмәтлебез.

Инде менә 7 ел музей күренекле галим, Татарстанның халык язучысы, Г. Тукай бүләге иясе Мөхәммәт ага Мәһдиевнең иҗатын пропагандалауга зур өлеш кертә. Киләчәктә дә музейга уңышлар юлдаш булсын!

Наше историко-краеведческое наследие.

«МӘЛИКӘ КИТАБЫ» ТАРИХЫ

Ф. З. Яхин

(Дәвамы. Башын карагыз: № 1, 2018).

V

Мәликәнең Габделхәлимгә биргән беренче соравы: «Кайдан киләрсән?» («Кайдан киләсең?»). Егет Төркестаннан икәнлеген әйтергә тиеш, югыйсә. Әмма ул «аталар нәселеннән, аналар көмәненнән килгәнен» әйтеп җавап бирә. Һич шик юк: тапкыр, зирәк җавап! Гади генә сорау шуның белән мавыктыргыч, эчтәлекле, мәгънәле төс ала. Укучыны егет шушы җавабы белән хәйран да итә, аптыраشта да калдыра, сокландыра да.

Габделхәлимнең җавабы дөрес булуын күп очракларда Мәликәнең тиз генә икенче сорауга күчүеннән дә беләбез. Бу ысул хис-фикер ритмикасын тудыра. Беренче булып бирелгән кайдан килүе хакындагы гади сорауга алынган мәгънәле һәм дөньяви белемнәр өлгесе булган җавапка кыз исә дәлил таләп итә. Егет аңа, Коръән аятен искәртеп: «Йәхриҗүмин бинин әс-сальби вәт-тураиб»,– ягъни: «Адәм балаларын туфрактан бар кылдым»,– дигән сүзләрне китерә.

Кыз канәгать кала. Шулай да ике җавап үзара тәңгәл килмиләр, югыйсә. Әмма автор, аларны янәшә куеп, икесендә дә бер үк нәрсә хакында сүз барганлыгы тойгысын уята. Ата-анадан туу белән туфрактан бар кылыну хакындагы шушы ике хәбәрне дә укучы бер үк нәрсәләр икән дип кабул итәргә тиеш. Мондый мантыйк әдәби әсәрләр өчен дә, дин гыйлеменә дә ят түгел. Иң әһәмиятлесе шунда, әгәр дә фикерләрне раслау юллары дөрес, башкалар кабул итә алырлык дәрәҗәдә төзелсә, аларны хакыйкатькә хилафы юк итеп аңлыйбыз. Тормыш чынбарлыгы мисалы белән раслау кирәксә, мәсәлән бу очракта, рәхим итегез: кеше яши, туфракта үскәнне ашый, картаеп үлә, кабат туфракка кайтарыла, беркем дә Марс планетасында тумаган, Айга илтеп күмелмәячәк. Димәк, Җирдә яшәгән – Җирдә кала. Тән өчен бу шулай.

Мәликә икенче соравына күчә һәм: «Кайда барырсән?» («Кайда барасың?»),– дип сорый. Аңа егет: «Ламәкәнга барырмын» (ягъни: «Мәңге

торыр урынга барырмын»),– дип җавап бирә. Шушы рәвешле ул әүвәлдәге дөньяви юнәлештә җавап бирүләрдән дини-мистик өйрәтмәләргә күчә бару юлын сайлый. Кыз өченче соравын бирә һәм егеттән кайда яшәвен сорый. Ул: «Гүрстанда торамын»,– дип җавап бирә.

Аның бу сүзләрен дөрес аңларга кирәк: егет дөньяны гүрстан, ягъни каберлек буларак атый, чөнки дини-мистик карашлар системасында бу дөньяда һәр ни бар – алар үләчәк, бәндәнең һәр адымы, суфичылык шигърияте тасвирлаганча, үлгәннәр туфрагына басып йөрүдән гыйбарәт.

Дөнья йөзен бу рәвешле итеп күз алдына китерү һәм аңлату кайсы мәзһәб яки тарикатькә карый, дигәндә, аны инкарь итүчеләре юк икәнлеген искәртү дә җитә. Диндә, суфичылыкта, аларның һәммәсендә дә, шушы караш нигезендә фәлсәфәләр корыла, урта гасырлар әдәбияты аңа нигезләнеп мәгънәләр чыгара. Әмма аның кайчан барлыкка килүен билгеләү – аерым игътибарга лаеклы мәсьәлә. Әсәрдә егетнең «мәңге торыр урынга», ягъни «ламәкәнга барырмын» дип җавап бирүеннән, димәк, «кабердә торырмын» дигән фикерне аңлыйбыз, мондый карашның дини-мистик күзаллаулар кысасында туганлыгын ачык күрәбез. Кызның бәхәсләшмәве дә әһәмияткә ия. Авторның үзенә дә аның кирәге юк. Чөнки егетнең шушы җавапларында игътикад-иман белән бәйле карашлар алга чыгарыла. Ә иман мәсьәләсендә бәхәс – урынсыз, иманга дәлил кирәкми, ул тел белән әйтеп расланыла. Габделхәлимнең җавабы аның иманы дөрес булуны ачык аңларга ярдәм итә. Фикеренең хикмәте дә менә шушында, фәлсәфәсендә түгел.

Бүгенге ислам дөньясында ике төп мәзһәб – сөнниләр һәм шигыйлар мәзһәбләре генә рәсми танылган, башка мәзһәбләр исә яки беренчесенә, яисә икенчесенә карый. Аларның игътикадта, гыйбадәттә, шәригатьтә аермалыклары берникадәр генә, әмма принципиаль. Ислам дөньясында матуридия, кадәрия, әшгария һ. б. мәзһәбләр дә IX йөздән XII йөзгәчә яшәп, төрле суфичыл юнәлешләрне барлыкка китерүдә нигез ролен башкарганнар. Бу мәзһәбләрне нечкәләп белү әлегә текстология фәнебездә җитенкерәми дә кебек. Шунлыктан әдәби әсәрләрне бәялгәндә эчтәлекләрен дөрес аңлату, мәгънәләрен төшендерү юлында хаталану очраклары аз түгел.

Габделхәлимнән кайдан килүе һәм кайда баруы белән бәйле сорауларга җаваплар алынгач, әсәрнең төп герое Мәликә икенче төркем (аның сорауларын үз төркемләвебезгә нигезләнеп шушылай атыйбыз) сорауларына күчә. Иң тәүдә барлыкка китерелгән җан ияләренең кемнәр булуын сорый кыз. Егет аларның җеннәр икәнлеген әйтә. Кыз дәлил таләп итә. Фәкыйһ бу хакта Коръән аяте барлыгын искәртә: «Ви-җанни халикънаһу мин нарин әс-сәмун»,– ди (ягъни: «Җеннәрне самун утыннан яратты»,– ди).

Алга таба авыр сорау бирәчәген искәртеп, Мәликә егетне максатыннан кире кайтырга өнди, аңа һәлак ителәчәген искәртә. Фәкыйһ моңа каршы шигырь белән җавап бирә. Әсәрдәге ул шигъри юлларның урта гасырчылык традицияләрендә, җитмәсә төрки телдә булуы аерым әһәмияткә ия:

Шөгълəп шәмгы җәмалың бәхрене күргәч, рәван
Җандин пәрванә яңлый кем, кәчдем һәман, –
дип белдерә Габделхәлим.

Алга таба бу шигырь гади укучыга аңлашылырлык дәрәҗәдә гадиләштерелеп аңлатыла: «Ягъни, сән – чырагсән, мән – пәрванәмен, үлсәм – гаҗәп ирмәс»,– рәвешендә.

Бу мисрагның авторын ачыклау кызыклы нәтиҗәләр һәм фикерләр бирер иде. Ул шагыйрь Ә. Яссәви әсәрләренә вәзен һәм кяфияләре белән якын, әмма аны шушы әдипнеке дип кистереп әйтеп булмый, чөнки җыентыкларында мондый шигъри юллар юк, ә охшашлары – җитәрлек. Ничек ямьле итеп әйтә бит: «Нурланып балкып торган чибәрлегеңнең диңгезен күргәч, урынында тора алмаучы җаным күбәләк кебек канатланып очты шунда»,– ди. Бу – сәлҗүкләр чоры шигъриятенә караган, фарсы-гарәп символик күзаллау тәэсирен татыган төрки тел, төрки теленең кагыйдәләре исәпкә алынып, төрки тел табигатендә фарсы теле лексикасында язылган шигъри юллар. Әдәбилек ягыннан шома, матур, килешле, эчтәлекле, бик тә мәгънәле телдә. Автор бу шигырьне укучысы өчен махсус рәвештә гадиләштереп, хәтта, әйтергә кирәк, аңлатып бирүне кирәк тапкан икән, димәк, моның да әһәмияте бар. Ул шигъри тел белән гади сөйләмнең аермасы барлыгы хакында әйтә чөнки. «Син – янучы ут (чыра), мин – күбәләк, (шул утта янып) үлсәм дә гаҗәп түгел» дигән эчтәлектәге шигырьне аңларга тәкъдим итүе, «сиңа мәхәббәтем аркасында янып бетсәм дә ярый» дигән фикерне югары стильдә, итагать белән, аксөякләрчә белдерү юлын да күрсәтүе түгелме авторның? Фарсы сүзе «шәмгъ» төрки сүзе «чырагъ»ка (чыра) алмаштырыла, «пәрванә» (күбәләк) шигырьдәгечә калдырыла, «күчү» сүзе исә «үлү» буларак бирелә. Болар барысы да әдәби ядкәр сыйфатында «Мәликә китабы»ның урта гасырлар чорына караганлыгын фаразлауга этәрә. Әмма шунысы да бар: төрки әдәби теле бездә, татарда, XIX йөзнең соңгы чирегенә кадәр, хәтта ки XX гасырның 14нче елынача, татар милли әдәби теле тәмам гамәлгә кереп җиткәнчегә тикле язмада кулланылышта йөргән. Моңа әдәби ядкәрләрнең наширлар тарафыннан еш бастырылып таратылуы да уңай йогынты ясаган. Татар укучысы өчен бу төрлелек сәер тоелмаган. Шулай да ул, төрки тел, XIX йөзнең соңгы чирегенә генә түгел, хәтта иртәрәк тә ясалма буларак тоела башлаган. Аның яшәү көче төрки халыкларның милләтләргә аерымлана баруы белән бергә

кимүгә таба юл алган. «Мәликә китабы»нда «миллиләшү» бөтенләй дә сизелми. Ул үзенең «чыраг»лары, «пәрванә»ләре, «гаҗәп ирмәс»ләре белән бергә, кайбер урыннарда гади халык вәкиленә катлаулы тоелырга мөмкин төрки сүзләрне сөйләмдәге төркигә «тәрҗемә» иткән, текстны шушы рәвешле «җиңеләйтеп» бирүе сәбәпле «иске чыгтай» дип аталган Ә. Яссәви һәм аның чордашлары теле.

VI

Егеттән имтихан дәвам итә, алга таба аңа Мәликә ягыннан яңа сораулар куела. Кызның: «Камугдин борын ни-шәйне яратты?» (ягъни: «Барчадан алда ни-нәрсәне бар кылды?») – дигәненә каршы Габделхәлим «Кәф» һәм «Нүн» хәрефләрен Аллаһы тәгаләнең бар итүе хакында әйтә. Шушы җавабыннан соң фәкыйһ бу гарәп әлифбасы хәрефләренең «Күн, фәйәкүн!» сүзләрен әйтү өчен кирәк булганлыгын да искәртә. Бу сүзләрнең төрки вариантлары да әйтелә. Ул хәл исә халыкка шушы «бул, булсын» үзләренең бу чорда яхшы билгеле икәнлеге хакында төшенергә мөмкинлек бирә. Әмма шунда кызның: «Кәф» илә «Нүн» нә кылгучы?» – дигән сүзләре ул «Кәф» һәм «Нүн»не затлар, ягъни җан ияләре буларак күз алдына китерүгә этәрә. Фәкыйһ тә җавабында «Кәф» илә «Нүн»не: «Күн, фәйәкүн!» дип торучы торыр» – дип җавап бирә. Бу исә әсәр язылган вакытта «Кәф» һәм «Нүн»нең нәрсә икәнлекләре тәмам ачыкланган, авазлар түгел, бәлки фәрештә кебек терек затлар буларак күзалланганлыгы хакында сөйли. Бусы – бер яктан, ә икенче яктан, гакыйдә гыйлеменең (иман фәлсәфәсенең) катлаулы мәсьәләләренең берсенә бәйле тәгълиматны искә төшерә. Аллаһы тәгаләнең һичбер нәрсәгә бәйсез рәвештә барлыгын дәлилли алар. «Күн, фәйәкүн»гә нисбәтле шушы фәлсәфәне галим Мансур бине Мөхәммәт Матуриди IX гасырның ахырларында–X йөзнең башларында ачыклый һәм Аллаһының мәңгелек хакыйкать булуын акылга ярашлы һәм зиһенгә сыешлы дәрәҗәдә, ягъни рационализм кысаларында чишкән галим санала [Islam ansiklopedisi: 1991. S. 175–176]. Өченчедән, әгәр дә кызның сораулар бирү манерасына игътибар итсәк, әсәрдә бер генә җавап та бәхәс ителми, Мәликә дәлил сораган очракта, Габделхәлим бары тик Коръән аятьләренә генә таяна. Бу факт әсәрнең ислам дөньясында схоластика дәвере чорында язылганлыгын аңлата. Ә Матуриди – дискурс заманы кешесе, сүз сөйләүченең фикер-мәгънәләрне тәртипкә салып бирә һәм белдерә белүен таләп иткән фәлсәфәчеләрнең берсе. Ул чорга әйтелгән сүзнең ачык һәм төгәл, аңлаешлы булуын таләп итү хас. Коръәннән конкрет мисал китерү ярдәмендә хакыйкатьне ачыклау – шул чорның үзенчәлеге. Тарих дәвамында ислам дөньясында мондый дәлилләү манерасы ныгый гына барган. Димәк, «Мәликә китабы» шул дискурс дәверенә якын чорда язылган. Башкача була да алмый,

чөнки аңарда дискурс манералары ачык чагышылыш тапкан. Шулай итеп, автор ул стильдән качарга теләве аркасында вакыйгаларны коры, аз сүз белән бизәксез тасвирлауга махсус рәвештә барган, ә төп өлешне сорау-җавап формасына коруны уңышлы әдәби тасвир чарасы итеп күзаллаган булып чыга. Һәм бу максатына ирешкән дә.

1017нче елда хәлиф Әл-Кадыйр (исеме: Әбу-Габбас Әхмәт, «Кадыйрелбиллаһ», ягъни «Аллаһының кодрәтендә» кушаматы булуы сәбәпле «хәлиф Әл-Кадыйр» аталган, 947–1031нче елларда яшәгән) мөгътазилийә мәзһәбендә булучыларны тынычландыру максатында иман нигезләрен билгеләүче рескрипт фәрманын чыгара һәм шул вакыйгадан башлап «гакыйдә гыйлеме» схоластикага әверелдерелә. Бу исә һәртөрле дискурсларны чикли башлауга китерә. Ә «Мәликә китабы» схоластика юлыннан бара. Тагын да шунысы әһәмиятле – Матуриди фикерләре белән берникадәр дискурста булган әшгарийәләр һәм аның өйрәтмәләрен дин асылы дип аңлатучылар (мөгътазилийәләр) өстеннән 1010нчы елда (Һиҗри исәптә 400нче ел) Пәйгамбәрне үле дип раслаганнары өчен хәлиф хөкүмәтенә шикаять китерәләр. Хәер, бу шикаятьне язган кәррамийәләр да шул ук елда, әшгарийәләр белән бергә бәддогага тапшырыла [Мец Адам: 1973. с.175]. Әшгарийәләр Галине пәйгамбәр, хәтта Аллаһы тәгалә урынына куя башлыйлар [Islam ansiklopedisi: 1973. S.15]. Шулай итеп, хәлиф Әл-Кадыйрның 1017елгы рескрипты вакытында эшләнгән гамәл булып чыга, ислам дөньясын ул тәмам тарткалашулардан һәм таркалудан туктата. Әмма шушы хокукый акт, ягъни рескрипт аркасында фикер үсешенә тоткарлыклар да ясала, куылулар һәм чикләүләр дә башланып китә. Ә «Мәликә китабы»нда шушы чорның рухы бөтен барлыгы һәм тулылыгы белән чагылыш тапкан. Ул мөмкин кадәр дискурска бирелмәскә, фикер киңлегенә генә түгел, хәтта тасвир стихиясенә бирелмәскә тырышып язылган. Бу факт исә китапның язылу датасын ясәвичелек алды елларына, ягъни XIгасырның урталарына нисбәт итәргә мөмкинлек бирә. Чөнки, беренчедән, әсәрдә Пәйгамбәр тере итеп сурәтләнә, ә Ә.Яссәвидә ул тарихти шәхес буларак тасвирлана; һәм икенчедән, «Кәф» һәм «Нүн» мәсьәләсе ачыкланып җитмәгәнлек ул гасырның дин гыйлеменә хас үзенчәлекләрнең берсе – ул да «Мәликә китабы»нда урын ала. Дөрес, алга таба Пәйгамбәр хакында бирелгән сорауларда Мөхәммәт галәйһис-сәламнең ничә яшь яшәгәнлеге хакында сорау бар. Фәкыйһ аның 63яшь яшәвен әйтә, әмма барыбер дә «үлгән» яки «вафат булган» сүзләрен кулланмый. Бу исә авторның шактый сак эш итүе хакында сөйли. Аңарда белем, талант һәм чама хисен тою югары дәрәҗәдә булган.

«Мәликә китабы»нда кыз биргән сораулар берсе икенчесеннән кызыклырак, көтелмәгәнчә. Бу исә әсәрнең укучы күңелен үзенә тарту көчен

арттыра. Ул сораулар һәм җаваплар ислам фәлсәфәсеннән бихәбәр кешеләр өчен аңлаешсыз һәм кызыксыз тоелырга мөмкин. Белеме барлар, бигрәк тә урта гасырлар укучысы аларны хикмәтле буларак кабул иткән, билгеле. XIX йөздә, әсәрнең 1846 нчы елда беренче тапкыр китап буларак басылып чыкканында, аның нинди мәзһәб, нинди фәлсәфә кысаларында язылганлыгын, кайсы дини юнәлешне яктыртуын аңлап эш этми калмаганнар. Бу чорда татарда сәләфийәт мәзһәбе чәчәк ата. «Мәликә китабы» да мең кат үлчәнми-бәяләнми калмаган. Башкача мөмкин дә түгел. Шулай да, әгәр дә нечкәләп бәяли башласак, бу китап эчтәлеге белән сәләфийәтнең игътикад гыйлеменә дә, ислам фәлсәфәсенә дә тәмам ярашып бетми, әмма каршылыкка да килми. Бастырып чыгаручысы Казан өязе Бәрәскә авылыннан (Татарстанның Әтнә районы) Мөхәммәтшакир мулла Габденнасыйр улы [Мәликә китабы: 1846. Б. 16.] боларны гына белми калмаган булыр?

Шунысы әһәмиятле, «Мәликә китабы»нда XI–XII йөзләр кешесе өчен яхшы таныш һәм аермалыклары ачык тоемланган мәзһәбләр көрәшенең хикмәтле каршылыклары да теркәлгән. Әсәрнең авторы, язылган елы күрсәтелмәү дә нәкъ шуның белән бәйле булган. Болай белдерергә аңарда тулы җирлек бар. «Мәликә китабы» дини идарәче даирәләр тарафыннан тыелган кайсы бер мәзһәбнең дә рәсми булмаган фәлсәфәсенең эчтәлеген дә «хикәяләп» бирүгә корылган урыннары белән игътибарга лаеклы. Бу үзенчәлек исә аристократиянең хакыйкатьләрне тарихта саклап калу максаты белән бәйле туган, билгеле. Төркиләр дөньясында дин аксөякләре X йөздә тәмам ныгып җитә, XI йөздә, шушының нәтиҗәсе буларак, Йосыф Баласагуни, Әхмәт Йөгнәки кебек бөек әдипләр әдәби фикер мәйданына күтәреләләр. Әмма идарәче даирәләр, тарихи барыштан һәм шул чорда язылган әсәрләрнең эчтәлегеннән аңлашылганча, хөкемдарлыкта аксөякләр белән артык санлашмый башлыйлар. Җитмәсә 1017 елгы рескрипты хәлиф Әл-Кадыйрның мөгътәзилийә мәзһәбен бәддогага тапшыра. Матуридийәгә дә, башкасына да көн калмый. Шушы рескрипт тудырган схоластик рух ислам дөньясында гасыр уртасына тәмам урнашып җитә. Фикер эзләнүләре әдәбият өлкәсенә күчә бара. Бу исә фәлсәфә фәненең үзенә яшәеш мәйданын эзләвенә бәйле була. Шушыңа бәйле әдәби әсәрдә фәлсәфи фикерне сурәтләү юллары, аны бирүнең стилистик алымнары барлана башлый. Моның үзенчәлекле бер мисалы – «Мәликә китабы». Аның стиле һәм слубы нәкъ шул чорның үзенчәлекләре белән бәйле оешкан. Әсәр бу яклары белән үз заманы рухын күзалларга да ярдәм итә. Мәсәлән, беренчедән, хикәятнең башлам өлешендә экспозициянең реэкспозициягә, ә ул реэкспозициянең төп вакыйгалар белән бәйле экспозициягә күчүе – кыйсса эченә кыйссаны кысалау рәвешендә бирелә. Мондый әдәби формаларны язучыларның гадәт итүләре XI йөз-

нең икенче яртысыннан көчәеп китә [Тамирдари: 2007. с. 106.]. Аннары, икенчедән, «Мәликә китабы»ның теле, аның әдәби үзенчәлекләре аерым игътибарга лаек. 912–1058нче еллар арасында фарсы прозасының беренче дәвере чорына хас үзенчәлекләре фәнгә яхшы мәгълүм. «В целом все языковые особенности прозаического стиля можно свести к следующим моментам,– дип яза бу мәсьәләдә фарсы галиме Әхмәт Таминдари,– незначительное количество арабских слов, применение которых ограничивалось религиозной и политической терминологией, не имеющих персидских эквевалентов; отсутствие лексических и литературных укрошений, неиспользование айатов и хадисов для украшения речи; небольшое влияние арабского стиля не тексты, переведенные с арабского языка; незначительное использование персидских и арабских стихов и поговорк; лаконичность фраз; повторение глаголов и других слов в предложении; создание и использование научной терминологии вместо арабских слов; применение некоторых грамматических и ситексических конструкций, которые отличают литературу этого переода от придыдущих» [Тамирдари: 2007. Б. 102.]. Боларны укыганда «Мәликә китабы» күздә тотылып язылган кебек хис кала. Әмма бер халыкның әдәбиятына хас үзенчәлекләрне икенче халыкның әдәбиятына бәйле механик күчереп кую дөрес булмас иде. Шулай да бу охшашлыкларны да күрми калдыру дөрес юл түгел. Чөнки төрки дөнья ул дәвердә гомумислам мәдәни конгломератының берсе булган. Бер халыкның әдәбиятыннан күренешләр икенче әдәбиятка үрнәк итеп күчерелү дә табигый хәл икәнлеген дә онытмыйк. Ә ислам мәдәнияте кысаларындагы төрки әдәбиятлар бигрәк тә фарсы телле әдәбиятлар белән тыгыз бәйләнештә яшәгәннәр. Әмма бездә фарсы прозасына хас бу стиль газнәвиләр һәм сәлҗүкиләр чорында, бигрәк тә 1058нче еллардан 1156нчы елларга кадәр кергән булса кирәк. Фарсы прозасы үсешенең икенче чоры [Тамирдари: 2007. Б. 102.] беренчесеннән әллә ни кискен аерылып та тормаган. Әмма аның алга үсеше дә күзәтелә: ул гарәп йогынтысы көчәюдән гыйбарәт. «Мәликә китабы»ның телендә гарәп йогынтысы көчле дип әйтеп булмый. Ә менә Коръән аятьләренә урыны-урыны белән тәрҗемәләр бирү, фарсы сүзләре күп катнаштырылган шигъри кисәккә «тәрҗемә-аңлатма» ясау – болар ихтибардан читтә калдырыла алмый. Әсәрнең укучысы кем булачагын, аның катлаулы шигъри стильдән ерак торачагын автор яхшы күзаллап эш иткән.

Безнең төрки-татар әдәбиятында андый әдәби тел (аны хәтта «корама әдәби тел» дияргә була) XII гасыргача, хәтта ки X йөздән әйләнештә булган. Әгәр дә 1070нче елда язылган Йосыф Баласагуниның «Кодатгу билик» («Белем куәте») гомумтөрки әдәбияты ядкәре саналган әсәренә генә игътибар итсәк тә, аның телендә шушы «корама тел» конструкцияләре

очравын күрербез. Ул дастанның теле, андагы гыйбарәләр, аллегорияләр борынгы төркиләр дөньясының идеологиясен, фәлсәфәсен, идеалларын чагылдырган. Аның шушындый әһәмияткә ия булуының төп сәбәбе иске заманнарда китапларның юктан гына язылмаулары хакында да сөйли. «Мәликә китабы» да телендә, стилендә, формасында, кузгаткан фикерләрендә үз чорының үзенчәлекләрен саклый, бу әсәр тарихта юкка һәм юктан гына тумаган, асылсыз ядкәр түгел.

VII

Кыз сорый: «Җефетләрдә каю җефетне яратты?» – дип, ягъни, парлы җан ияләреннән Аллаһы тәгаләнең беренче булып кемнәрне-нәрсәләрне бар кылуы хакында сорый. Фәкыйһ аңа: «Тәблит-Җәблит атлыг кем ирсәне яратты. Беренең койрыкы белән елан дик вә йәнә беренең койрыкы чаян дик, икесен җефет кылды»,– ди. Алга таба бирелгән сораугa җаваптан Тәблит һәм Җәблитнең Шайтанның ата-анасы булулары беленә. Тәблитнең койрыгы еланныкы кебек, ә хатыны Җәблитнеке чаянныкы сыман икән. Әгәр дә иске заман кешеләренең һәртөрле табигый көчләрне мифологик планда, әкияти формада танып-белүләрен һәм аңлатуларын исәпкә алсак, гомумән дә сурәтле-образлы күзаллау кеше аңының үзенчәлеге булуын төшенсәк, Тәблит һәм Җәблит мәсьәләсендә артык бәхәс итмичә, аларның төрки-татарлар җанлы күзаллавында шушындый икәнлекләрен исәпкә алырбыз. Шул ук вакытта аларны каршылыклы, Шайтан белән бәйләнештә күреп, кешелек дошманнары сыйфатында да кабул итәрбез. Иске заманнар аңлавындагы Тәблит һәм Җәблитнең йөзе, буе-сыны һәм башка яклары түгел, бәлки койрыклары сурәте-рәвеше генә китапта искә алынган. Бусы да кызыклы факт. Еланныкы һәм чаянныкы кебек койрыклар башка җан ияләрендә юк, еланнан һәм чаяннан гайре, әлбәттә. Шушы рәвешле сурәтләп бирү, җитмәсә исемнәрен дә искәртү – болар рескриптка кадәрге бәхәсләрдән исән калган берәмлекләрдән, әлбәттә. Алар инде XI гасырның икенче яртысында каләм мәсьәләсендә язылган китапларда искә дә алынмыйлар, алга таба әдәби әсәрләрдә дә бик сирәк очраячаклар, алардан хәтта бөтенләй юкка чыгарылачаклар.

«Мәликә китабы»нда кыз күптөрле мәсьәләләрне кузгата. Шулардан берсе: «Каю намаз торыр: күктән инде, йиргә тимәде?» – дип сорый. Ул – бишенче төркем сораулардан. «Мәликә китабы»нда бүлекчәләрне исемләми генә аеру, ягъни хәзерге китаплардагыча цифрлар белән бүлә бару тәртибе кулланылмаган. Аның тексты тоташ, нокталар һәм өтерләрсез, кызыл юлларсыз ахырынача бара. Әмма әсәрнең эчтәлеге бүгенге көндәгечә, мәгънә-фикер, вакыйга күчеше белән бәйле рәвештә бүлгәләү өчен мөмкинлек бирә. Текстны фәнни-текстологик яктан эшләгәндә бүгенге укучы күнеккән, аның таләпләренә яраклы итеп башкарырга кирәк

табылды. Әгәр дә аны җөмләләргә, абзацларга бүләбез икән, ни өчен бүлекләргә дә аермаска тиешбез?

Егет бу намазның җеназа намазы булуын әйтә. Кыз шунда ук башка төрле, бөтенләй дә бүтән мәсьәләләргә бәйле сорауларны бирүгә күчә. Алар: «Дәрьяларның асылы нә торыр?» – дип башланып китәләр. Бу рәвешле тема үзгәртелеп, көтелмәгәнчә бирелгән сорау урыннары әсәргә әлбәттә шаккату төсмере бирә. Ә егетнең җавапларны оста табуы исә гаҗәпләнү, хикмәт тойгысын уята. Ул: «Нух туфаны торыр» – дип белдерә. Аның җавабы дөресме-юкмы – мондый шик укучыда тумый калмаска тиеш. Сорау-җавап ярышы гомумән дә интригалы булучан, бигрәк тематиканың төрлелеге монда уңышка китерә. «Мәликә китабы»ның авторының боларны яхшы аңлап, белеп эш иткәнлеге сизелеп тора. Тематиканың бер сораудан икенчесенә көтелмәгәнчә үзгәрә баруы, ә вакыт-вакыт аларның бертөрлеләре бергә җыелуы әсәр «вакыйгалары»на пластика бирә. Бу исә хәтта саф фикер үсешен, хәтта, шуның белән бәйле, сафлык хисен тойдыра. Пластика, иплелек – сафлык, итагать тойгысын үстерә түгелме?

Кыз сорый: «Башы юк, җаны юк, дөньяда ут йийде [ашады], су эчте. Ул нә ирер?» Егет аның Муса пәйгамбәр таягы булуын әйтә. Хикмәте шунда, Муса пәйгамбәр, Мисырдан качып китеп, Лут пәйгамбәр белән көтү көтеп йөри, шунда аның кулына көтүче таягы керә. Билгеле булганча, татар кешесе күзаллаган көтүче таягы ыргак башлы, ныклы һәм озын була. Көтүче аның белән көтүне куалап йөртә, кирәк булганда – таягының ыргаклы башы белән сарыкның арткы ботыннан эләктереп ала, ә инешләр аша, чокырлардан чыкканында шул таягын басма итә, яисә аңа таянып сикерә һ. б. Сүз менә шундый таяк хакында бара. Әмма Муса пәйгамбәрнең таягында башка хикмәтләр дә була. Фиргавеннең сихерчеләре кулларындагы бауларын Муса өстенә елан итеп җибәргәндә, ул таяк, аждаһага әверелеп, аларны йота. Иске хикәят китапларында бу таяк хакында кызыклы хәбәрләр табарга була. Аның хикмәтләре турында Коръәннең «Шугарә» («Шагыйрьләр») сурәсенең 62–63 аятьләрендә дә әйтелгән.

Кыз, егеттән җавапны алуга, Аллаһы тәгаләдән ирешкән китаплар хакында сорауга күчә. Бу бүлекчәдә алты сорау бирелә һәм алар һәммәсе дә шул китапларга бәйле. «Асмандин [күктән] ничә китап иңде?» – дип сорый кыз. Егет аларның дүрт йөз дә дүрт китап булуын әйтә. Алга таба аларның кайсылары мәшһүр икәне сорала. Егет туры җавап бирә, дүрт китапның (Тәурат, Инҗил, Зәбур, Коръән) булуын, аларның кайсы пәйгамбәрләргә «иңүен» (Мусага, Гайсәгә, Давытка, Мөхәммәд галәйһүмәс-сәламнәргә) әйтә. Шунысы әһәмиятле, Коръән китабы «Форкан», ягъни «Хакыйкатьне ялганнан, яхшыны яманнан аеручы» исеме белән, суфилар телендәгечә атала.

Кыз шуннан соң пәйгамбәрләр хакында сораулар төркеменә күчә. Алар барысы – җидәү. Җавабында егет 124 000 пәйгамбәр булганлыгын, 313-ен мөрсәл, ягъни «китаплы», ә «ун кәсе» [ун кешесе] – нәби, ягъни «китапсыз пәйгамбәр» дип атаулары хакында әйтеп, ул китапларны Аллаһыдан Җәбраил фәрештә китерүен белдерә. Шунысы әһәмиятле, бу пәйгамбәрләрнең «ойкуда», ягъни йокыда, чагында хәбәр алулары аркасында нәби дип аталуларын да искәртә. Бу, әлбәттә, әһәмиятле, игътибарга лаеклы мәсьәлә, чөнки вак кына күренгән шул үзенчәлекләр артында олы хикмәтләр ята. Нәбилекне әүлиялеккә суфилар янәшә куя. Нәбилекнең нечкә мәсьәләләренә бәйле бәхәсләр мәзһәбләрнең «гакыйдә гыйлеме», ягъни каләм фәлсәфәләре аерымлану дәверендә, төгәл алган – VIII–X гасырларда туганнар. «Мәликә китабы»ндагы фикерләр киңлеге ул йөзьеллыклардан әллә ни иңгә китмәгән. Аның нигезендә инде утырып җиткән сөнни мәзһәбенә хас иман шартлары өйрәтмәләре ята, әмма аңарда матуридийә юнәлешенең фәлсәфи карашлары йогынтысы да шактый сизелә. Дөрес, ул калкытып куелмаган, тирән яшерелгән, әмма «гакыйдә гыйлеме»ннән, ягъни кәлам фәлсәфәсеннән яхшы хәбәрдар галимнәр сиземләр дәрәҗәдә бирелгәннәр. Ә менә Мәликәнең пәйгамбәрләр арасында ничә әфзаль (укымышлы, өстенлекле) булуы хакында биргән соравына егетнең Ибраһим, Муса, Гайсә һәм Мөхәммәд пәйгамбәрләргә бәйле җавап бирүе матуридийә карашларын турыдан-туры өскә чыгара.

Алга таба куелган җиде сорау суфичылыкка багышланган. Җавапларында егет суфилыкның (суфиларча диндар булуның) Идрис пәйгамбәрдән үк килүен әйтә. Ни өчен аңардан соң? Чөнки ул терек хәлендә җәннәткә керә. Суфилар да шулай. Үзләренең гыйбадәтләрендә алар, Аллаһыга ирешеп, аның нурында «эриләр», гыйрфан, ягъни нурлану алалар. Бу гыйрфан – серләрне аңлап алу, тою аркасында, әлбәттә. Хакыйкатькә ирешү – нурлану тойгысын тудыра. Кыз: «Галим кем торыр?» – дип сорый. Җавабында егет Хозер пәйгамбәрне атый. Моның хикмәте аның «тереклек суын» табуына бәйле булса кирәк? Кызның: «Разый кем торыр?» – дигән соравына егет: «Исмәгыйль торыр»,– дип әйтә. Монда исә аның хәтта әтисе кулыннан Аллаһы тәгаләгә корбан булырга әзер торуы, каршылык итмәве исәпкә алынган. Татар әдәбияты ядкәрләрендә Исмәгыйль пәйгамбәрнең бу риза булучанлык, итагать сыйфатлары туктаусыз, бигрәк тә Корбан бәйрәменә бәйле касыйдәләрдә мактала. Аңа соклану, аны өлге итү суфичылык әсәрләре өчен аеруча хас. Ә менә сабырлыкның кемнән килүенә бәйле сораугa егет: «Әйүпдин калды»,– дип җавап бирә. Аллаһы тәгаләнең барлык сыйфатларын да ул нигъмәт, чын итагатьлек, коллык күрсәтеп кабул итүче буларак та Давыт пәйгамбәр исеме белән бергә атала. Кыз бу мәсьәләдә аерым кызыксына һәм: «Нәдин

«нәгамел-габд» атанды?» – дип сорый. Егетнең җавабы: «Әйүп бәлагә сабыр кылды. «Нәгамел-габд» атанды. Давыт нигъмәткә шөкер кылды, «нәгамел-габд» атанды»,– ди. Моның белән «нәгамел-габд» төшенчәсе дә аңлатылып бирелә. «Нәгамь» – гарәп сүзе, «нигъмәт»нең күплек саны, ягъни «нигъмәтләр» дигәнне белдерә. «Габд» – «кол», шулай ук гарәп сүзе. Егетнең биргән җавабыннан аңлашылганча, алар – бәлаләргә сабыр булучылар, Аллаһының биргәненә шөкер итүчеләр. Димәк, нәкъ менә шундый кешеләр «нәгамел-габд» дип аталалар да икән. Бу рәвешле дини-суфичылык терминнарын аңлаткалап алу ягыннан «Мәликә китабы» дидактик әдәбият юнәлешенә дә кереп киткәли. Әмма, тулаем алганда, бу әсәрне матур әдәбиятның дидактик төренә кертеп булмый.

Дидактик әдәби төр безнең татар әдәбияты белемендә аерымланып өйрәнелми, аның барлыгы хакында сүзнең кузгатылганы да юк. Әмма башка халыкларның әдәбиятлары белән бәйле язылган хезмәтләрдә, мәсәлән, фарсы әдәбияты белемендә андый әдәби төр аерым алып тикшерелә һәм өйрәнелә. Дидактик формалар эпик әсәрләрдә кулланылучан булалар. Алар әдәби чигенеш ясау өчен уңай, мәгънә биреп алу, төшенчәләрне, фәлсәфәне аңлау-аңлатуны тәэмин итү өчен дә ул кулай юл.

Кыз алга таба заһитлык, ягъни монахлык белән бәйле сораулар бирә. Алар барысы өчәү. Беренчесе – заһитлыкның үзе хакында, аның Гайсә пәйгамбәрдән гадәт булып калуы белән бәйле икән. Икенчесе – шәкертлек турында, аның Нух пәйгамбәрдән башлап гадәт ителүе хакында, өченчесе – фәкыйрьлек, анысының Яхъя пәйгамбәрдән килүе турында. Заһитлыкның монахлык, диндарлык булуында бәхәс юк. Дөрес, ул сүзне суфичылык буларак та аңларга мөмкин. Әмма заһитлык исә суфичылыкның бер сыйфаты гына, үзе түгел. «Заһит» сүзе «монах» дигәнне белдерә. Ә менә «шәкерт» сүзе нәрсәне аңлата? Әлбәттә бер-бер остаздан гыйлем өйрәнүче кешене бездә «шәкерт» диләр. Ә Нух пәйгамбәрнең шәкертлеге, ягъни остаздан өйрәнүе хакында хәбәрләр нинди? Ул бит «Икенче Адәм» ләкабе-кушаматы белән атап йөртелә, Адәмнең остазы була алмаган шикелле, аныкы да юк түгелме? Димәк, «шәкерт» сүзе бер-бер остаздан гыйлем өйрәнүче дигән мәгънәгә генә ия түгел булып чыга. Аны башкача да аңларга мөмкинлек бар. Дөрес, «шәкерт» сүзе борынгы телебездә «шәгерд» булган. Ул фарсы телендә дә шулай. «Шәгерд» дигәндә – «тәҗрибәсезлек» мәгънәсе дә бар. Чөнки ул башкача ни өчен остаздан өйрәнергә тиеш? Гомумән дә һәртөрле остазлар үзләре янында шәкертләр тотып, аларны эшкә өйрәткәннәр. Ул шәкертләре аларга булышчылык итеп, дәресләрен хезмәтләре белән түләгәннәр. Безнең татар мәдрәсәләрендә һәр атнакич көнендә, ягъни чәршәмбедә, шәкертләре остазларына бер тиен акча белән укытканы өчен хакларын кайтарганнар. Мәдрәсәдә бушка укыту практика-

сы булмаган. Остазына түләрлек акчалары юк шәкертләр аңа хезмәткә ялланганнар. «Мәликә китабы»нда бу рәвештәге шәкертлек хакында сүз бара алмый, билгеле. Чөнки, ул рәвешле булса, мантыйкка сыймый, табигый түгел. Дөрес, борынгы заманнарда, мәсәлән грек философы Сократның да, башкаларның да шәкертләре булган. Нух пәйгамбәр хакындагы хәбәрләр туфан, дөньяны су басу вакыйгалары белән бәйле. Ул исә котылып калу өчен бөек көймә ясаган. Аны эшләү өчен ул башка осталардан түгел, Аллаһының әмере белән Җәбраил фәрештәнең серләрне аңлатуларыннан белеп алган. Шәкертлек, ягъни остазга-өйрәтүчегә ияреп эшкә ябышуны, шәкертлек буларак, Нух пәйгамбәр белән бәйле шушылай аңлату хаклы да кебек тоела. Әллә соң «шөкер итү», ягъни «шакирлек» сүзеннәнме ул «шәкертлек»? Бу очракта: «юк», дибез! Чөнки «шәкертлек» сүзенең борынгы үз әйтелеш варианты – «шәгерд» сүзеннән, ә «шәкертлек» – «остаздан өйрәнүче» дигәннән. Шулай итеп, «Мәликә китабы» безгә Нух пәйгамбәрнең тагын да бер асыл сыйфатын – шәкертлеген ачыкларга булыша. Димәк, бу «шәкертлек» тарихи-фәлсәфи мәгънәгә ия, һәр нәрсәдән мәгънә чыгару һәм өйрәнүне күздә тота.

«Фәкыйрьлек мәсьәләсе»нә килгәндә шул ук хәл, монда да ул тарихи-фәлсәфи мәгънәгә ия, аның эчтәлеге Яхъя пәйгамбәрнең холык-фигыльләрен искә алу белән аңлашыла башлый. Булганга канәгать итү, хәтта бәла-казаны да канәгатьлек белән күтәрү – болар аңа хас сыйфатлардан. Дан, дәрәҗә, байлык, гаилә һ. б. шундый дөньялык бәрәкәтләре Яхъя пәйгамбәрнең күңелен яулый алмаганнар. Яссәвия тарикате нигезендә дә шушы ук фәкыйрьлек идеаллары һәм идеологиясе ята. Без яссәвия тарикате вәкилләрен «типтәрләр» дип беләбез, чөнки алар үзләрен, хәзергечә әйтсәк, «дәфтәриләр» дип йөрткәннәр. Ул атама Ә. Яссәвинең китаплары «дәфтәр» (ягъни «төптәр»//«тифтәр») дип йөртелүдән шулай. Яссәвичеләрнең гыйбадәтләре аның, шәех-хуҗаларының (аларны шәехләрен «хуҗа» дип атаганнарына бәйле «хуҗаганнар», ягъни «хуҗалар» дип йөрткәннәр) «типтәр»ләрендә аңлатып язылган. Сүз Ә. Яссәвинең «Дәфтәри-әүвәл» – «Беренче дәфтәр» исеме белән аталган тарикать гыйлеме китабы хакында бара. Хәер, аның хикмәтләр китабы да «типтәр» атала, ягъни «Дәфтәри-сани» («Икенче дәфтәр») исеме белән. Хәер, бу мәсьәләләргә галимнәр хәзер игътибар да итеп тормыйлар. Шулай да «фәкыйрьлек фәлсәфәсе» безнең татарда идеология рәвешен алып киткәнлеген ачык күзаллап, аның яшәеше XIX йөзнең соңгы чирегенә, хәтта аерым билгеләре белән XX йөз урталарынача нәкъшбәндия тарикате белән бергә яшәп килгәнлеген онытырга ярамый. Әле XX йөз башы «Иман шарты» татар китапларында да халкыбызның яссәвия һәм нәкъшбәндия суфичылык юлларында булуларын аерым күрсәткәннәр.

«Мәликә китабы» фәкыйрьлекне, шәкертлек белән бергә, заһитлык мәсьәләсенә бәйле бүлекчәдә, алга таба да искә ала. Без монда суфилыкка монахлык каршы куела икән дия алмыйбыз. Суфилык белән заһитлык бергә, бер җептә, әмма янәшә искә алынуларына игътибар итәргә тиешбез, дибез. Суфилык, бер яктан, заһитлыкка, әлбәттә, барып тоташа һәм аның да кайбер үзенчәлекләрен үзенә ала. Әмма, икенче яктан, суфилык заһитлыктан шактый киңрәк тә әле. «Мәликә китабы»нда сүз, бәхәс тә була алмый, заһитлык-монахлыкта Гайсә, Нух һәм Яхъя пәйгамбәрләрне өлге итүгә, аларга иярүгә, идеалны алар өлгесеннән табарга өйрәнү хакында мәгънәле сүз алып барыла, ә суфилыкка килгәндә, Идрис, Хозер, Исмәгыйль, Әйүп, Давыт (Дауд) пәйгамбәрләр үрнәк ителә. Суфилыктагы заһитлыкка килгәндә, ул анда турыдан-туры түгел, бәлки диндарлык белән, ягъни эчтәлек белән катнаша. Суфиларның сумгалары, төрбәләре, гыйбадәтләре һ.б. формаль яклары монахлыкка бик аз тартым. Шулай да уртак яклары да аз түгел. Аларны «Мәликә китабы» төгәл күрсәтеп бирә: аскетлык, шәкертлек һәм фәкыйрьлек! Шушы өч сыйфат аларны үзара охшаш итә, әмма суфилык, заһитлыктан аермалы буларак, Идрис пәйгамбәр юлында булуга, ягъни тере килеш җәннәткә керүне, Аллаһыга якынаюны, Хозер пәйгамбәр кебек галимлекне, Исмәгыйль пәйгамбәрдәй разыйлыкны, Әйүп пәйгамбәр сыман балык карынында калып та сабыр булуны, Давыт һәм Әйүп пәйгамбәрләр кебек һәртөрле бәлаләргә сабырлыкны, нигъмәткә шөкер кылуны, ягъни «нәгамел-габд» булуны таләп итә. Монда Ибраһим пәйгамбәр кебек утка төшүләр искә алынмый. Һәрхәлдә Ә.Яссәвидә бу хакта, ягъни Ибраһимны суфиларга үрнәк итү тиешлеге хакында аз искәртелмәгән. Димәк, бу фактлар безне «Мәликә китабы»ның яссәвиягә кадәр язылганлыгын фараз итәргә тагын бер кат этәргеч бирәләр.

Шунысын да истән чыгармыйк: автор китабының ахырына таба, фәкыйрьлек хакында кабат сүз кузгатып, аны кешегә хурлык китерүче буларак бәяли, аның ялган сөйләү, ялган ант эчү һ. б. аркасында килүен белдерә. Мондый урыннары әсәрнең язылу чорын ачык күзаллатуга караганда, эчтәлегенә төшенүгә, аңларга омтылуга күбрәк күбрәк җәлеп итә. Беренче карашка гади тоелган бу халык әдәбияты әсәре иске заманнар татар акылын аңлар өчен аерым әһәмияткә ия. Аның әдәби яктан оста, югары аһәңнәрдә язылмаган булуы түгел, ни-нәрсәләрне, кайсы хакыйкатьләрне үзендә саклавы күбрәк кызыксындырды. Хәер, барча хакыйкатьләрен ачык, дөрес һәм тәмам төшенеп бетерә алабыз дип тә ышанып җитеп булмый. Шулай да һәр туа барган сорауларыбызга җаваплар да табыла төсле. Ышанасы килә.

(Дәвамы бар).

Исторические источники по краеведению.

МАТЕРИАЛЫ ЛАНДРАТСКОЙ ПЕРЕПИСИ 1716–1717 гг. КАЗАНСКИЙ УЕЗД

(продолжение. Начало см.: в №1, 2018)

Арская дарога

Сотня татарина Бектемирки Тогашева

1) Азяк	служилых новокрещеных – 33
2) Азяк	служилых новокрещеных – 20
3) Верхняя Утня	служилых новокрещеных – 19
4) Малая Метеска	татар – 54
5) Большая и Верхняя Метеска	татар – 73
6) Ключ Карачерма	татар – 109
7) Утня	татар – 22
8) Крылай	татар – 76
9) Верхняя Утня	татар – 13
10) Кара Куюк	татар – 24
11) Иябаш	татар – 22
12) починок Варангози	татар – 36
13) Пшалым	татар – 44
14) Пшалым (Верхние Нырты)	татар – 66
15) Нижний Пшалым	татар – 26
16) Кухта	татар – 38
17) Турнали	татар – 36
18) Кармыш	татар – 120
19) Кутяк	татар – 55
20) Казыли	татар – 82
21) сенные Покосы (р. Ашит)	татар – 37
22) Гар (Верхняя Утня)	татар – 16
	= татар – 933,
	из них служилых новокрещеных – 72

Сотня татарина Иштеряка Ирбулатова

1) Енасала	новокрещеных – 67

2) Мичень	новокрещеных – 65
3) Корса	татар – 74
4) Корса усадом	татар – 66
5) Масра	татар – 82
6) починок Масра	татар – 82
7) Муралеевская	татар – 62
8) овраг Сикертан	татар – 5
9) Талкич (рч. Кисмес)	татар – 17
10) Муй Сизе	татар – 28
11) Малый Муй	татар – 34
12) Чму Елга	татар – 52
13) Муй	татар – 49
14) Корса почмак	татар – 21
15) Каинсар	татар – 40
16) Мичень (Мендюш Ключ)	татар – 23
17) по рч. Корса	татар – 30
18) Атар	татар – 25
	= татар – 768,
	из них новокрещеных –132

Сотня татарина Кутлуг Досаева

1) Ново-Мичень	татар – 108
2) Мичень	татар – 77
3) Урак (рч. Мендюш)	татар – 33
4) рч. Едигер и Мичень	татар – 8
5) Верхняя Мичень	татар – 29
6) Изма (р. Сунер)	татар – 26
7) Утерняс	татар – 25
8) Изма	татар – 19
9) Верхняя Шикша	татар – 34
10) Илибер (р. Серда)	татар – 17
11) Вниз Мешы	татар – 19
12) Темершик	татар – 161
13) починок рч. Шикша	татар – 70
14) починок Мешабаш	татар – 27
15) Явлаштау	татар – 30
16) рч. Серда	татар – 29
17) Маметова Пустошь	татар – 97
18) Средние Сабы (Шайтан ключ)	татар – 37
19) рч. Побык	татар – 74
20) Менгер	татар – 62

21) рч. Ур	татар – 32
22) рч. Кажи	татар – 40
23) Юмгалак	татар – запустела
	= татар – 1604

Сотня татарина Альметя Битякова

1) Верхние Белетли	новокрещеных – 13
2) Атар Илга	новокрещеных – 7
3) Верхняя Ошторма	новокрещеных – 13
4) усад рч. Сер душ	новокрещеных – 9
5) починок рч. Уряс	новокрещеных – 31
6) Астан Илга	новокрещеных – 21
7) Верхний Уряс	новокрещеных – 7
8) Мочальное озеро	новокрещеных – 33
9) Юкачи	новокрещеных – 54
10) Ший (Каменный ключ)	новокрещеных – 8
11) Исенбай (Байлянгар)	новокрещеных – 19
	= новокрещеных – 225
12) Итемгян Березник	татар – 51
13) Аман Оштарма	татар – 15
14) Пияр (Ошторма Кукмор)	татар – 40
15) Нурминское устье	татар – 97
16) Люга	татар – 103
17) Арпаяз	татар – 16
18) рч. Асан Илга	татар – 96
19) Другой Кукмор	татар – 24
20) Шунь	татар – 91
21) Помяс	татар – 58
22) Каркаюс	татар – 29
23) Усниур	татар – 21
24) Канауш (Сагмак)	татар – 52
25) Вошторма Куюк	татар – 13
26) Ташлы Елга	татар – 19
27) Барсук Елга	татар – 12
28) Ерыклы Елга	татар – 9
29) Ошторма Камышлы	татар – 59
	= татар – 565

На Горной стороне татар:

1) Атлашев	татар – 23
2) Ташлазан	татар -12
	= татар – 35

Черемис:	
1) рч. Синем	черемис – 3
2) Читан (Васин)	черемис -13
	= черемис – 16
Чуваш:	
1) Дальняя Сорма	...100
2) Старые Шигали	...91
3) починок Истяси	...71
4) Шигали	...472
5) Ахпердина (Мамыш)	...84
6) Вут (новопоселенный)	...40
	= чуваш – 858

Сотня татарина Азичка Байбулатова

1) Шамарданов	новокрещеных
2) Узяк Илга	-
3) Старый Кукмор (р. Нурма)	татар – 55
4) рч. Нурма	татар – 18
5) Шамарданов	татар – 20
6) Искег Елга (Сенных покосов)	татар – 8
7) Иски юрт	татар – 25
8) Верхняя Нурма	татар – 22
9) пустошь Нурма	татар – 25
10) Байлангар	татар – 79
11) Сабанчи	татар – 67
12) конец враг Балыкли	татар – 113
13) устье Нурма	татар – 68
14) Ядигер	татар – 127
15) Тарлов	татар – 79
16) Малый Сердек	татар – 49
17) Кучюкова	татар – 119
18) Кушкан Адаева	татар – 54
19) пустошь Серда	татар – 49
20) Иллиляшемка	татар – 25
21) Верхняя Серда	татар – 15
22) Кетек рч.	татар – 28
23) Новая Вонь	татар – 105
24) по Серде и Текле	татар – 132
25) Адаев	татар – 76
26) Шалче Бура	татар – 28
27) Копка	татар – 91

28) рч. Тойма	татар – 30
29) Ижбахтин	татар – 14
30) Миксар	татар – 35
31) рч.Туренер	татар – 61
32) Княбаш	татар –34
33) Кара Илга	татар – …
	= татар – 1636,
	в том числе новокрещенных – 22

Черемис:

1) Кучукова	черемис – 17
2) Кня	черемис – 42
3) Осторма Кукмор	черемис – 11
	= черемис – 70

Сотня татарина Рыска Байметова

1) Ноcлы	служилых новокрещеных – 5
2) Кукет [Кушкет ?]	[служилых новокрещеных] – 45
3) Черный лес (Горелое место)	[служилых новокрещеных] – 5
4) Апазово (Шунь рч.)	[служилых новокрещеных] – 94
	= служилых новокрещеных – 149
5) Ур	татар – 108
6) Чета	татар – 153
7) Смаиль	татар – 205
8) Кучюк	татар – 70
9) Ур (Урек)	татар – 59
10) Нуринер	татар – 113
11) Тюнтер	татар – 45
12) Янгул	татар – 224
13) Седек (Серденер)	татар – 51
14) Усад за рч. Салауш	татар – 131 (+52)
15) Салауш	татар – 98
16) Новый Салауш (Шошма)	татар – 83
17) Бурнак	татар – 142
18) Малая Нурма (Карелино)	татар – 113
19) Кучюкова (Сосна)	татар – 228
20) Нурма (Чепшар)	татар – 124
21) Большая Нурма	татар – 167
22) починок Тохтамыш	татар – 41
23) Вершина Нурма	татар – 21
24) Большая Нурма (Карамалы)	татар – 26
25) конец поля Большая Нурма (Килево)	татар – 98

26) Ахмановская	татар – 119
27) Яншикова пустошь	татар – 151
28) Тоузаров	татар – 55
29) Арбаш	татар – 105
30) Нижний Ядигер	татар – 49
31) Ядигер	татар – 81
32) Тоузарово (Ключ Куюк)	татар – 108
33) Вотяцкая (рч. Кня)	татар – 53
34) Пшнегер (Баклауш)	татар – 18
35) Сосмак Пшнегер	татар – 53
36) Нус (Понус рч.)	татар – 89
37) Ишнарат	татар – 34
38) Менгер (Марян)	татар – 8
39) Утгу Елга	татар – 21
40) рч. Шошма (обе)	татар – 62
41) полянка Шошма (Урмяк)	татар – 36
42) Кушкет (Унтер)	татар – 65
43) починок Кушкет	татар – 26
44) рч. Кня	татар – ….
	= татар – 3333

Черемис:

1) Вотяцкая	черемис – 11
2) Серда	черемис – 40
3) Серда	черемис – 8
	= черемис – 59

Сотня татарина Енуска Байметова [черемисская сотня]

1) Иж бобья	татар – 45
2) Иж бобья	черемис – 59
3) починок Рушемер	татар – 3
	= татар – 48

Сотня татарина Тюмейка Байбулатова

1) Верхний Еграш	новокрещеных – 19
2) Еграш	новокрещеных – 11
3) Еграш (по Тойме)	новокрещеных – 30
4) починок Гарь (Куркачи)	новокрещеных – 14
5) Камышлы	новокрещеных – 6
6) Атыяс	новокрещеных – 3
7) Токмаклы	новокрещеных – 16
	= новокрещеных – 116

8) Агрыз	татар – 71
9) Иж	татар – 75
10) рч. Кутмес	[татар] – 11
11) Ер (Искашер рч.)	[татар] – 7
12) Ер (Багряш)	[татар] – 28
13) Назер	[татар] – 9
14) Кизильяр	[татар] – 20
15) Шурсак (Шурняк)	[татар] – 24
16) Кишкильде	[татар] – 24
17) Аккозин	[татар] – 10
18) Чишма	[татар] – 28
19) Варзи Омга	[татар] – 29
20) Батыркуль	[татар] –
21) Салауш (рч. Еграш)	[татар] – 31
22) Тердели	[татар] – 8
23) Каранды	[татар] – 10
24) НовыйЧаш	[татар] – 15
25) Кармалы	[татар] – 19
26) Кубяшур	[татар] – 11
	= татар – 459
27) Тансарин	
28) Гухшурма	чуваш – 19

Закамье:

Сотня татарина Абдрзачка Кильдебекова

1) Крилиш	новокрещеных ….
2) Кешкача	новокрещеных ….
3) Нижний Мелим	новокрещеных ….
4) починок Баграш (Сарсаз Тамак)	новокрещеных ….
5) Булда	новокрещеных ….
6) Башкитляр	новокрещеных ….
7) Тлянчи	новокрещеных ….
8) Сарсаз	новокрещеных ….
9) Ахтуба	новокрещеных ….
10) Евлаш баш	новокрещеных ….
11) Мартыш (Бикчюраева пустошь)	новокрещеных ….
12) Сосновый Мыс	новокрещеных ….
13) Айша Буй	новокрещеных ….
14) Бурун-Сафар	новокрещеных – пуста
	= новокрещеных – 411

15) Тауларово	татар – 16
16) Малтабаров	татар – 10
17) по рч. Ик	татар – 13
18) Яковлев	татар – 6
19) рч. Шилка	татар – 24
20) Ахтемиров	татар – 23
21) Шукрали	татар – 6
22) Бугда (Чокыр Илга)	татар – 15
23) Буре (Келте)	татар – 48
24) Ази Елга	татар – 7
25) Кардели (Ялгыз нарат)	татар – 42
26) Шумилина	татар – 1
27) Мелекес	татар – 20
28) Новый Мелекес (Сюнрали)	татар – 7
29) Киндерлекуль	татар – 11
30) Сююндук	татар – 11
31) Аши(т) Теряк враг	татар – 26
32) Зичи Чибашкан	татар – 23
33) Чебарат Елга	татар – 4
34) Большие Букшанды	татар – 20
35) Тавлук Дерюшева	татар – 8
36) Тавлук	татар – 6
37) починок Игин	татар – 13
38) Нижний Кабан	татар – 10
39) Шингачи	татар – 69
40) Толбуга	татар – 8
41) Нижний Мелен	татар – 2
42) Лешад	татар – 12
43) Чершилы	татар – 14
44) Авлаш	татар – 3
45) Елев	татар – 13
46) Ташлы Елга	татар – 27
47) Каинлы рч. Ерыклы	татар – 6
	= татар – 498

Чуваш:

1) Нижнее Байшево	чуваш – 3
2) Ново-Ирня	чуваш – 3
	= чуваш – 6

[Источник: РГАДА, Ф. 350. Оп. 1. Ед.хр. 153]

Зюрейская дорога

Сотня Мамотяка Тохтамышева

1) Чирмеш	татар – 27
2) Бимер	татар – 20
3) Кебечи	новокрещенных – 22
4) Ковали	новокрещеных – 45
5) Атрес	новокрещеных – 13
	служилых новокрещеных – 8
6) Иштери	татар – 40
7) Балыклы	татар – 41
8) Кукча	татар – 23
9) Большая Метеска	татар – 55
10) Кибач	татар – 79
11) Камышлы	татар – 28
12) Верхняя Метеска	татар – 28
	= татар – 326
	= новокрещенных – 88

Сотня Девлятков [нрзб]

1) починок Телези	татар – 18
2) Мамалай	татар – 6
3) Старые Зюри	татар – 18
4) Новые Зюри	татар – 23
5) починок на Гари (Куюк)	татар – 37
6) Саурыш	татар – 11
7) Баландыш	татар – 14
8) Бегеней	татар – 21
9) Качангеево	татар – 30
10) Нижние Шытсы	татар – 35
11) Верхние Шытсы	татар – 22
12) Нырсывар	служилых новокрещеных – 44
	новокрещеных – 80
	= татар – 235
	= новокрещенных – 124

Иштеряка сотня Ишкеева

1) Большая Меша	татар – 29
2) Средняя Меша	татар – 17
3) Малая Мёша	новокрещеных – 40
4) Большой Савруш	новокрещеных – 85
5) Верхний Савруш	татар – 18

6) Другой Савруш	татар – 25
7) Тюбяк	новокрещеных – 10
	татар –34
8) Студеный ключ	татар – 20
9) Исянская (рч. Малые Кибечи)	татар – 17
10) Нысы	татар – 12
11) Трёх-Сосен	новокрещеных – 26
Икшурма	Русских
	] 43
	новокрещенных
	= новокрещенных – 197
	= татар – 163

Рыскова сотня Досаева

1) Карабаян	новокрещеных – 30
2) Большой Меретяк	новокрещеных – 15
3) Малый Меретяк	татар – 6
4) Дюртели	татар – 12
5) Таулы	татар – 13
	= новокрещеных – 45
	= татар – 25

Сотня Бикмамета Калмякова

1) Другая Икшурма	татар – 20
2) Чабъя	татар – 23
3) Арташ два поля	татар – 10
4) Большие Нырты	татар – 23
5) Большие Абди	татар новокрещеных – 101
6) Шапшинар	татар – 26
7) Янделятовская	татар – 14
	= новокрещеных – 101
	= татар – 116

Сотня Кильмамета Азикова

1) Большая Меша	татар – 15
2) Мамли Козаковы Челны	татар – 9
3) Багана	татар – 21
4) Кутлу-Букашевы Челны	татар – 60
5) Тярбердины Челны	татар – 54
6) Бердибяковы Челны	татар – 4
	новокрещеных – 20
7) Урекаевы Челны	татар – 16

	новокрещеных – 30
8) Шумбут-баш	новокрещеных – 51
9) Верхний Шумбут (Тауларово)	новокрещеных – 20
	татар – 14
10) Кебяково (Ямашево)	татар – 53
11) Кукеево (р. Суш)	татар – 25
12) Кучук-Чаллы (Балгазыево)	татар – 57
13) Шигазда (Сатлуганово)	татар – 6
14) Мордовские Чаллы (вниз Шумбут)	татар – 26
15) Урманчеевская	новокрещеных – 35
16) Казаково-Челны	служилых новокрещеных – 19
	новокрещеных – 9
17) Средний Арняш	татар – 23
18) Арташ (починок)	новокрещеных – 52
19) Верхний Малый Черемшан/ Студеный Ключ	чуваш – 95
	служилых новокрещеных – 51
20) Адам су	чуваш – 88
21) Спиркино (Кадратов)	чуваш – 77
	новокрещенных татар – 1
	черемисов – 1
22) Ахбулатово	татар – 37
23) Шарбан	татар – 20
24) Савруш (рч. Адам)	чуваш – 30
25) починок Савруш	чуваш – 107
26) починок Наратлы Илга/ Ниж. Багана	новокрещеных – 9
27) Красное Болото/Багана	новокрещеных
	] 32
	мордвы
28) Теплое Болото	новокрещеных – 22
29) Сулу (Иваново)	….
30) Верхний Машляк	новокрещеных – 28
	= татар – 447
	= новокрещеных – 291

Ямашкова сотня Бектюшева

1) Чабья (Арбаш)	татар – 32
2) Уркуш	татар – 21
3) Арбаш	татар – 17
4) Туркач	татар – 5

5) Чабья	татар – 18
6) Кабык Купер починок	татар – 39
7) Сосновый Мыс	татар – 24
8) Старый Ошлан	татар – 26
9) Туллу[баево]	татар – 19
10) Ускубаш	татар – 44
11) Бастемир	татар – 9
12) Среднее Уску	татар – 6
13) Буклянер	татар – 27
14) Большое Уксу	татар – 62
15) Улуяз	татар – 37
16) Кургунча верхняя	татар – 11
17) Кургунча	татар – 10
18) Белятли	татар – 21
19) Тулбаево	татар – 43
20) Верхний Селенгер	татар – 27
21) Средний Шудигер	татар – 12
22) Шандыр	татар – 22
23) Юкачи	новокрещеных – 6
24) Зюри	новокрещеных – 13
25) Чань	татар – 37
26) Устье Лый рч.	новокрещеных – 28
27) Горелый Ельник	татар – 57
28) Большой Ший	черемис – 55
29) Нижний Ший	черемис – 3
30) Ерыкса (Куюк)	татар – 42
31) Кумазан	татар – 53
32) Верхний Ерыкса	новокрещеных – 25
33) починок Куюк	новокрещеных – 11
34) Нижняя Ошма	татар – 82
35) Умяк (за Вяткой)	новокрещеных – 17
36) Атыяз (за Вяткой) рч. Узян	новокрещеных – 24
37) Шурняк	новокрещеных – 51
38) рч. Ирке (Сарман)	черемис – 10
39) Качи (Тумаш)	черемис – ….
40) Юграш (за Вяткой)	татар – 54
	= новокрещеных – 161
	= татар – 956

Сотня татар Рысака Тыкеева

1) Кушле	татар – 27

2) Сартак	татар – 18
3) Малый Сунь	новокрещеных – 67
4) Нижний Сунь	татар – 64
5) Баскан	татар – 35
6) Малый Берсут	новокрещеных – 38
7) Усули	татар – 11
8) Багильдино (Верхний Сунь)	татар – 77
9) Верхний Сунь	татар – 19
10) Туркач	татар – 22
11) Средний Сунь	татар – 71
12) Нижний Сунь	татар – 36
13) Нижние Яки	татар – 56
14) Верхние Яки	татар – 31
15) Уразбахтино	татар – 28
16) Верхний Берсут	татар – 34
	служилых новокрещенных – 10
17) Сукачи (Белетли)	татар – 52
18) Кулущевская	новокрещеных –
	татар –] 40 на всех трех
	русских –
19) Малый Кирмен	татар – 26
20) Средний Кирмен	татар – 106
21) Ижбердеевская [Ишкеево ?]	новокрещеных – 4
22) Ожмяк	татар – 3
	служилых новокрещеных – 103
	= татар – 704
	= новокрещеных – 149
	= служилых новокрещеных – 117

Сотня новокрещена Ивана Андреева

1) Сейтяк	новокрещеных – 99
2) Черкасс	новокрещеных – 14
3) Село Костин (Кабык-Купер)	Русских ….

Сотня татар Тишки Тенебекова

1) Безяки	татар – 11
2) Пшкашево (Кусинда)	татар – 18
3) Учимек	татар – 5
4) Матчинер	черемис – 12
5) Малая Ерыкса	черемис – 8
6) Ерыкса	черемис – 14

7) Ахтиял (устье Иж)	татар – 18
8) Нарат Чишма (Малый Дрюш – Тогузино)	татар – …..
9) по Бобье (близ д. Тера)	черемис – 21
10) Тогус	татар – 2
11) Баргыда	черемис – 23
12) Ныргындуш	черемис – 7
13) Гази	черемис – 2
14) Окшеик	черемис – 3
15) Амзи (Ялгыз Нарат)	черемис – 7
16) Малый Калмаш	черемис – 2
17) Силиби	черемис – 3
18) Илия баш (Березовое)	черемис – 5
19) у волости Амзи	черемис – 31
20) Сухой Калмаш	черемис – 11
21) Ведрец Калмаш	черемис – 41
22) Сеинь Елга	татар – 33
	= татар – 104
	= черемис – 190

Сотня татарина Тагомайка Бектемирова

1) Шумилина	татар – 6
2) Талук	татар – 21
3) Игинь (Ашири)	татар – 12
4) Новый Сарсаз	татар – 16
5) Култещи	татар – 4
6) Ачисаз	татар – 3
7) Бекмет	татар – 2
8) Шукралеево	татар – 6
9) Ерыклы (Елантау)	татар – 16
10) Чершилы (Кош Елга)	татар – 7
11) Ляки	татар – 2
12) Нижние Зиче	татар – 20
13) Алкина	черемис –10
14) Чик Чишма (Таулы Колкамаш)	татар – 8
15) Шихмомаево	татар – 32
16) Верхние Зичи	татар – 26
17) Нижний Кабан	татар – 17
18) Зичи (Маметово)	татар – 11
19) починок Алансу	татар – 23
20) Кабан Бастарак	татар – 49
21) Евлаш	татар –

22) Ураз Чишма	татар – 6
23) Нижние Лызи	-
24) Пенечи	татар – 19
25) Керкечсу	татар – 37
26) Милень	новокрещеных – 33
	татар – 2
27) Кубал	татар – 16
28) Чевай	новокрещеных – 18
29) Нижняя Урманда	татар – 10
30) Наратлы Кечь	татар – 16
31) Иванаево	новокрещеных –
32) Туркас	татар – 4
33) Бушанда	татар – 5
34) Исенгулово	татар – 6
35) Ургези	чуваш – 2
	= черемис – 10
	= чуваш – 2
	= новокрещеных – 51
	= татар – 402

[Источник: РГАДА. Ф. 350. Оп. 1 Ед.хр. 153]

[Вне сотен]

Служилых новокрещеных

1) Никифорово	служилых новокрещеных – 79
2) Васильево	служилых новокрещеных – 26
3) Пакшина	служилых новокрещеных – 29
4) Суюк Суш (баш)	служилых новокрещеных – 15
5) Верхний Арняш	служилых новокрещеных – 16
6) Дюмдем	служилых новокрещеных – 8
7) Аналан	служилых новокрещеных – 15
8) починок Ново Елово (Степаново)	служилых новокрещеных – 28
9) Большое Елово	служилых новокрещеных – 51
10) Сатлыган Ключ	служилых новокрещеных – 21
	= служилых новокрещеных – 288

Служилых мурз и татар

1) Тавели (Ходяшево)	служилых мурз и татар – 72
2) Янбулатово	служилых мурз и татар – 44
3) Алан	служилых мурз и татар – 39
4) Кадряковы Челны	служилых мурз и татар – 23
5) Ошма	служилых мурз и татар – 29

6) Искубаш	служилых мурз и татар – 17
7) Дюмдем	служилых мурз и татар – 34
8) Челны	служилых мурз и татар – 22
9) Малый Алан Зюри	служилых мурз и татар – 6
10) Верхний Берсут	служилых мурз и татар – 10
11) Адамсу	……
12) Ерыклы (по рч.Кич)	служилых мурз и татар – 80
	= служилых мурз и татар – 376

Сотня Андрюшки Билкина

1) Нижняя Сосна	татар – 20
2) Верхние Чаллы	татар – 27
3) Малые Шипки (Аксарино)	татар – 40
4) Именлибаш	татар – 15
5) Каинлы Бурун	новокрещеных – 10
6) Туба	татар – 32
7) Сурки (Байгулово)	татар] 13 новокрещенных
8) Верхние Шипки (Буляк)	татар – 27
9) Малые Ерыклы	новокрещеных – 7
10) Бикшик Елга	татар – 17
11) Камышлы враг	татар – 21
12) Чебутлы (Узяк Беляк)	татар – 20
13) Яр Купер	татар – 3
14) Тавели	татар – 6
15) Ахтуба	новокрещеных – 95
16) Аднашево	татар – 19
17) Токбулат (по р/Шошме)	татар – 13
18) Кислый Хлеб	татар – 5
19) Богдан (Черемшанов)	татар – 3
20) Алты Чишма	татар – 3
21) Аты	новокрещеных – 18
22) Кич (Елашево)	мордвы – 13
23) Микиткино	чуваш –34
	= татар – 271 новокрещеных – 130 + 13(?) мордвы – 13 чуваш – 34

[Источник: РГАДА.Ф. 350. Оп. 1 Ед.хр. 147].

Текст к печати подготовлен Д. М. Исхаковым.

ТИР ТАМЫЗСАҢ, ҖИР КЫЗГАНМЫЙ

Р. Р. Минһаҗ

Пермь краеның Күңгүр районындагы Тортүз авылы егете Алмаз Хавыев тырышлыгы белән быел март азагында, Октябрь районында, төбәктә яшәүче татар авыллары эшкуарларының икенче җыены булып узды. Алмаз – үзләрендә яшелчә үстерү остасы буларак танылган егет. Казанда үткәрелә торган Бөтенроссия татар авыллары эшкуарлары җыенында ел да яшелчә игү серләре белән уртаклашмыйча калмый ул. Тик җыен мөнбәреннән чыгыш ясарга күп вакыт бирелми. Без аңа, «Туган җир» журналы аша уй-фикерләреңне милләттәшләребезгә тагын да тулырак җиткерә аласың, дип мөрәҗәгать иттек.

– Сүземне ерактанрак башлыйм әле. Минем беренче һөнәрем – инженер-механик. Пермь Авыл хуҗалыгы академиясен бетердем. Дүртенче курста укыганда икенче югары белем алырга булдым. Бухгалтерия, исәп-хисап һәм аудит буенча да белгечлек алып чыктым. Кәгазь эшләрендә тукталып, төртелеп калмас өчен монысы да кирәк. Аннары механика буенча аспирантурада укыдым. 2004 елда С. Петербург аграр университетында кандидатлык диссертациясе якладым. Әле мин 2015 елга кадәр үзебезнең авыл хуҗалыгы академиясендә укыттым, авыл хуҗалыгы машиналары кафедрасы доценты идем. Укыткан вакытта академия исәбенә Самарага (бәрәңге үстерү буенча алдынгы төбәк санала ул), сирәк-мирәк кенә чит илләргә төрле семинарларга, конференцияләргә йөрдем. Шул ук вакытта 2005 елдан туган авылымда кәбестә үстерүгә керештек (мин йөреп укыттым). 2010 елда кәбестәне голланд орлыкларыннан гына үстерә башладык. Хәер, аспирантурада укыган вакытта ук авылда бәрәңге үстерә идек. Без өч бертуган егет. Мин – уртанчысы. Абыем Айнур авылда. Азат энекәшебез – төзүче, ул Пермьдә яши. Төзелеш өчен кирәкле барча сызым эшләрен ул башкара. Мәктәптә укыган вакытта ук без башкалардан күбрәк яшелчә үстердек, әйтик, утыз сутый бәрәңге утырта идек. Тазарак, сәламәтрәк чагында эти дә булышты. Әле ул бер гек-

тар чөгендер дә чәчте. Анда нигездә әти эшләде. Аспирантурада укыган вакытта ук мин кредит алып аны үз стипендиямнән түли идем. Яшелчә игү эшенә дәүләт ярдәменә, грантларга таянып түгел, фәкать үз көчебезгә, мөмкинлегебезгә ышанып тотындык. 2005 елны гектар ярым кәбестә утырттык (ул вакытта иртә өлгерә торган кәбестәнең килосы – унбер сумнан, соң өлгерә торганы 3 сумнан сатыла иде). Быел менә иртә өлгергәнен әүвәл 8 сумнан саттык, аннары бәясе – 6, хәтта 4 сумга кадәр төште. Орлык бәяләре нык күтәрелде хәзер. Тегe заманда бер орлык 30 тиен торса, бүген бер кәбестә орлыгының бәясе – бер сум ун тиен! Дөрес, 2010 елда бөтен Россиядә корылык булганда безне әлеге афәт урап узды. Зыяны булды булуын, ләкин алай ук пошынырлык түгел (2008 елдан башлап су сиптергеч җайланмасы кулланабыз). Су сиптердек. Кәбестәнең килосы 12 сум булды. Ул вакытта «Россельхозбанк» ун процентка кредит бирә иде. Шунда 20 млн. сумлык кредит алып, техниканы яңарттык. Нигә чит ил техникасы кулланасыз дисәгез, бәрәңге һәм яшелчә үстерү өчен Россиядә техника җитештерелми. Шуның өчен барча техника чит илдән.

– Үзебездә яхшы сыйфатлы яшелчә орлыгы юнәтү дә кыенмы?

– Шулайрак шул. Без 2011 елдан кәбестә иккәндә голланд орлыкларын файдалана башладык. Шул ук елны кишер, чөгендер, суган чәчүгә керештек. Бәрәңге мәйданнары да күбәйде. Хәзер ишәйтеп кенә ба-

рабыз. Былтыр 120 га кәбестә иктек. Пермь краенда иң зур мәйданда яшелчә утыртучы без. Татар авылларында эшләүче, яшелчә үстерүче башка хуҗалыклар белән бер кооператив төзедек. Беренче чиратта сәүдә челтәрләренә керү өчен зарур иде бу берләшү. Шулай итеп безнең кооператив – Пермь краенда иң күп яшелчә үстереп сатучы. Бергә кушып исәпләгәндә, 200 ләп гектарда – кәбестә, илле гектарда – кишер, утыз гектарда – чөгендер, шулай ук 200 ләп гектарда бәрәңге игәбез.

– Пермь краеның авыл хуҗалыгына Татарстандагы кебек зур инвесторлар кермәгән, ахыры?

– Чынлап та, бездә башкачарак вәзгыять. Дөрес, бездә дә җир алу ансат булмады. Җир алу өчен край судларына кадәр барып җитәргә туры килде. Чөнки күмәк хуҗалыклар сакланып калды. Хәзер дә эшләп ята алар. 2010 елда яшелчә саклагычлар төзү өчен дә җиребез юк иде. Шул сәбәпле 2017 елдан күрше хуҗалыктан җир сатып ала башладык, арендага алдык. Анда ике яшелчә саклавычы төзедек. Хәзер хезмәткәрләребезгә кышын да эш бар, кышын яшелчәне аралау, эшкәртү белән мәшгульләр. Безнең авыл Пермьнән 120 чакырымда. Якын ара түгел бу. Сәүдә челтәрләренә керүе дә ансат түгел. Хәзер «Магнит» сәүдә челтәре белән генә түгел, «Пятерочка» белән дә килешүләр төзи башладык. Аларның колачы зур, билгеле. Март ахырында теплицада кәбестә орлыклары утырттык. Инде хәзер, май башында, аларны ачык һавадагы мәйданнарга күчереп утыртабыз. Дөресен әйтим: кәбестәне апрельдә, майда сату өчен сакларга өйрәнмәдек әле.

– Игү технологиясе Голландиянеке, Германиянеке дип беләбез...

– Әйе, шулай. Су сиптерү җайланмалары кайтару өчен берничә тапкыр Израильгә дә барырга туры килде. Бер уңайдан анда ничек яшелчә үстергәннәрен карадык. Дөрес, анда табигать бөтенләй бүтән.

– Әлмәтлеләрдән күреп, җиләк үстерүгә дә керешү исәбе юкмы?

– Андый исәп бар. Бер-ике ел элек барып карап та кайткан идем. Якындагы елларда керешмәкчебез. Тик барысына да өлгереп булмый.

– Кадрлар җитеп бетми дип тә чыгыш ясаган идегез. Белгечләрне, махсус белемле кешеләрне әйтүегездер инде.

– Белгеч кенә түгел, хәзер тракторчы табуы да кыенлашты, күпләр кыйбласын югалтты. Яшьләр шәһәргә карый, шартлар чагыштырмача яхшы булса да, авылда каласылары килми. Чөнки шәһәргә барып урнашкан кеше булдыклы санала. Әгәр авылда калсаң, булдыксыз күренәсең. Һаман, авылны макта, шәһәрдә тор, дигән психология яшәп килә. Менә мәктәп укучыларын гына алыйк. Безнең авылда тулы урта мәктәп, йөз иллеләп бала укый. Авылыбыз шактый зур санала, 1200 ләп кеше яши. Әле балалар бакчасында 75 бала йөри. Дөресрәге, Камышлы авылы белән

бергә без, ике авыл кушылган дияргә мөмкин. Су, газ кергән, асфальт юл килгән. Барча инфраструктура бар диярлек. Барда, Әрҗән районнары гына бездән яхшырак яши.

Тик менә соңгы 13 елда мәктәп тәмамлаучыларның берсе дә авылда төпләнеп калмады. Яхшы мәктәп авылны бетерә, дигән гыйбарә никадәр генә сәер тоелмасын, чынбарлыкка туры килә икән. Яхшы укыйлар да, югары белем алалар. Югары белем алгач, шәһәрдә калалар. Бездә нигездә таланты ачылмаганнар эшли дисәм, хакыйкатьтән ерак булмас. Элек бухгалтер, безгә яхшы укыганнар кирәкми, «3»легә, «2»легә укыганнар җитә, дип әйтә иде. Менә хәзер генә аның никадәр хаклы булуын аңладым. Хәзер коррекцияле класста укыганнарны да эшкә алырга туры килә. Тик алар белән ерак китә алмыйсың. Чөнки хәзер техникада эшләү дә югары белемле булуны таләп итә.

– Мәктәбегездә татар теле укытыламы?

– Балалар бакчасында тәрбия эше татарча алып барыла. Башлангыч классларда балаларыбыз татарча укытыла. Аннары, өлкәнрәк классларда, атнага ике-өч сәгать татар теле һәм әдәбияты дәресе керә. 2017 елда Казанда уздырылган халыкара татар теле олимпиадасында безнең укучыбыз Карина Кашапова гран-при яулады. Билгеле, монда татар теле укытучысы Чулпан Нуретдинованың да хезмәте, тырышлыгы зур.

– Яшьләр калмагач, барыбер авылның киләчәге якты, өметле дип әйтеп булмый шикелле.

– Чынлап та, сагайта торган хәлләр бар. Бүген авылыбызда 47 йорт буш тора. Дөрес, яңа йортлар да салалар. Әмма искеләре кешесез.

– Яшелчәче белән сөйләшеп, яшелчә үстерү серләре турында сорашмасак дөрес булмас.

– Яшелчә үстерү серләре тиешле китапларда язылган. Хәзер андый китаплар бихисап. Бары да билгеле. Аның сере бер генә: ничек язылган, шулай эшлә, ягъни технологияне бозма! Куелган таләпләрне үтисең икән, уңыш булачак. Яңгыр яумаса, нишләрсең, диләр. Су сибәсең! Киресенчә, яңгыр яумаса, яхшырак әле! Яңгыр күп яуган очракта аны җирдән җыеп ала алмыйсың. Яңгыр яумаса да, кояшлы көннәр җитә икән, сибәргә су табып була. Бездә бит нигездә кояш, җылы җитми.

КЫМЫЗ ЯСАЛГАН ҖИРЕНДӘ ФАЙДАЛЫРАК

Р. Р. Минһаҗ

Елкы асрап кымыз ясаган замандашларыбыз аз түгел. Әмма алар арасында әлеге эшкә җаны, тәне белән «ябешкәннәре», шәт шул сәбәпле уңышка ирешкәннәре бармак белән генә санарлык. Һичшиксез шуларның берсе – Башкортстан Республикасының Иглин районындагы Олы Теләк авылы эшкуары Хәсән Идиятуллин. Башкалабызда VII татар авылы эшкуарлары җыены барган көннәрдә Хәсән әфәнде белән очрашып, бу мавыгуының ничек башлануы, кымызның хикмәте, файдасы турында сөйләштек.

– Татарстан эшкуарлары да Сездә асралучы татар атларын бик теләп сатып ала дип ишеттек. Белүебезчә, шактый гына атыгызны Әлки районындагы Фәнис Бакиров сатып алган. Тик менә ул әле һаман кымыз ясарга ашыкмый.

– Ашыкмый дип әйтүегез дөрес булмас. Һичшиксез ул кымыз ясаячак. Яхшы кымыз нәкъ менә татар атыннан ясала да инде. Ул шул чаклы үзенчәлекле: кыргыйрак ат булгач, сөтенең сыйфаты, төгәллеге зур. Әлеге атларның кыяфәте, торышы, эчке һәм тышкы табигыйлыгы күбрәк сакланган. Ничә мең ел яшәү дәверендә табигатькә бик нык яраклашкан ул. Шул сәбәпле татар атларыннан ясалган кымыз иң яхшысы дип әйтергә хакыбыз бар. Инде Фәнис Бакировның үзенә килгәндә, ул – бик төпле татар егете. Эшләгән эшен җиренә җиткереп, сыйфатлы итеп эшли торган кеше. Шуңа күрә ашык-пошык кына алынып, күкрәк кагарга ашыкмый. Кымыз ясарга теләүчеләргә мин гел әйтеп киләм: ясагач, башта аны үзегез эчәргә өйрәнегез, аннан соң башкаларны эчәргә өйрәтегез! Менә мин үзем кымыз ясыйм. Аны халыкка тәкъдим иткән чакта әүвәл, туганым, син кымыз эчә беләсеңме,– дип сорыйм. Эчә беләм, диюче бик сирәк. Юк дәрәҗәсендә. Шунысын да белеп тору кирәк: бөтен кешенең дә организмы бер төрле түгел. Ягъни, кемгәдер кымызның әз әчелесе кирәк, кемгәдер – уртача, кемгәдер – нык әчелесе. Аны саклавы да шактый үзенчәлекле.

– Башкортстан ягы элек-электән шифалы кымызы белән дан тоткан. Аерым алганда, Тукайның, кымыз эчеп дәвалану өчен, Агыйделнең аръягына барганы билгеле.

– Татарлар гына түгел, урысның мәшһүр шәхесләре дә безнең якларга шифа эзләп килгән. Әйтик, урыс язучыларыннан Аксаков, Чехов, Толстойның җәйләрен туган ягыбызга килеп шактый көннәр кымыз

эчеп дәваланганы мәгълүм. Нигә соң алар шушылай ерактан килеп бездә эчкән, нигә аны китертмәгән генә?! Кымызны ясаган җирдә эчәргә кирәк. Ясаган җирдә генә аны сыйфатлы итеп эчеп була. Монысы – бер. Ни гаҗәп: күпләр кымызның нинди файда китергәнен аңлап та бетерми. Ягъни юлда аның ачылыгы күтәрелә. Һәр кешенең организмы үзенчәлекле бит. Кымыз бөтен кешегә ярап бетмәскә дә мөмкин. Шуңа күрә мин кымыз сатып алучылардан: «Кем эчәчәк? Кайчан эчәсез? Кайда эчәсез?»,– дип сорыйм. Чөнки эчәр җиргә җиткәнче күпме вакыт үтәчәге дә мөһим. Гомумән, кымыз эчү культурасы булырга тиеш. Әлеге дә баягы Әлки районындагы Әхмәт авылында яшәүче Фәнис Бакировка килгәндә, аның уңышларына бик сөенәм, эшләренең ничек барышына даими күз-колак булып торам. Алар миннән илле бия, айгырлар да алды. Шулардан үрчеп киттеләр. Ялгышмасам, хәзер аларның өч йөздән артык елкы малы бар. Мин аларның утарында кышын, язын, җәен, көзен дә булам. Кайсы вакытта гына килеп карасаң да, маллары көр, каралган. Димәк, егетләр үз эшләрен намус белән, тырышып башкара, бу тармакның киләчәген күреп-тоеп эшли. Авыл хуҗалыгында җиң сызганып тир түгүче күп кенә Татарстан эшкуарларына Фәнисне үрнәк итеп куяр идем. Ул гаиләсе белән эшли. Авыл хуҗалыгы алып бару өчен әллә ни кулай булмаган җирләрдә эшли. Аның көтүлекләре, әрәмә-агачлыклары – шактый ярлы җир. Яхшы җирдә кем дә эшли, яхшы машинада кем дә йөри. Менә шушы җирдә тир түгеп, шуннан табыш алып, илне баетырга һәркемнең дә кулыннан килми. Ә Фәнис булдыра: рәхмәт аңа!

– Менә Сез төрле кешегә төрле кымыз кирәк дидегез. Кемгә нинди кирәклеген ничек ачыкларга соң? Табибларны җәлеп итәргә дисезме?

– Табибларны күз алдында тотуым түгел. Әгәр аларны җәлеп итәргә керешсәң, инде әллә кайчан бия сөтеннән порошок ясап сату ягын карый башлар, дистәләрчә диссертация якланыр иде. Эчеп карау да җитә. Моңарчы эчеп караганы ничегрәк булды,– дип сораша башласаң, гадәттә күбесе,– бик ачы иде, дип зарлана. «Моңарчы эчкәне дә яхшы сыйфатлы булгандыр, әмма аның саклау вакыты узган булгандыр, шуңа күрә әчегәндер»,– дим андыйларга. Унбиш еллап элек мондый бер кызыклы хәл булды. Ул вакытта балаларым бәләкәй иде әле. Бер җирдә, юл буенда, кымыз сатып торабыз. Бервакыт, башка мәшәкать чыкты да, сату урынында балаларның үзләрен генә калдырдым. «Телиме-теләмиме, эчертеп карамыйча, сатмагыз!»,– дидем гадәттәгечә. Юарга – су, кечкенә генә чынаяк бар. Берзаман читкәрәк ерактан килүче бер кеше тукталды. Монголия, Кытаймы – ерактан кайтып барышы икән. Яннарына бардым да: «Минем кымызны эчеп карагыз әле, хәл кереп китәр, кәефегез яхшырыр»,– дип тәкъдим иттем. Хуҗа кеше: «Кирәкмәс! Әллә кымыз эчкәнем юкмы?!

Мин дөньядагы иң яхшы кымызны – Алтай кымызын эчәм, багажнигымда да бар»,– дип бик мактанды инде. Мин дә бирешмим. «Бик әйбәт! Инде минекен эчеп карагыз! Эчеп караган өчен акча алмыйм бит»,– дим боларга. «Безнең Башкортстанда сыйлау – табигый хәл. Сыйлаганда баш тарту килешми»,– дип кыстыйм. Үзе, хатыны һәм ике баласы – дүртәү болар. Салып бирдем, эчте бу. Эчте дә миңа карап тора. Минем кебек илле яшьләрдәге кеше. «Әгәр бу кымыз икән, без моңарчы нәрсә эчтек соң?»,– дип гаҗәпләнде. Гаҗәпләнеп кенә калмады, багажнигындагы теге кымызны алып томырды да, безнекен сатып алды. Күп тә үтмәде, яныбызга тагын бер машина килеп туктады. Шул ук көнне бу. Болар – үзебезнекеләр, башкортстанлылар. Салаватмы, Мәчетле районыннанмы... Боларга да эчеп карарга тәкъдим итттем. Башта баш тартканнар иде. Бераздан, эчеп карагач, кемдә күпме акча бар, дип сөйләштеләр дә, бензин салырлык кына акча калдырып, бөтен кымызны сатып алып киттеләр. Кешене шушылайрак кымыз эчәргә өйрәтергә кирәк! Без бит аны әллә ни күп җитештермибез. Шулай да елына карап 150шәр, 160шар, 170әр бия сауган вакытлар да бар. Кайбер елны уйламаган, көтмәгән мәшәкать чыга да, кырык-илле бия савасың. Кышкылыкка сигез-ун елкы да җитә.

Төбәк тарихы буенча конференцияләр һәм очрашулар.
Хатлар һәм кайтавазлар

Краеведческие конференции и встречи. Письма и отклики.

ХРОНИКА СОБЫТИЙ

16 февраля 2018 г. в г. Сасово Рязанской области прошел информационно-просветительский форум «Духовное наследие сасовских (ценских) татар». Форум проводился Сасовской местной татарской национально-культурной автономией Рязанской области при поддержке администрации города Сасово.

В работе форуме приняли участие учёные из Казани (главный редактор журнала «Туган жир-Родной край» Дамир Исхаков, председатель Общества татарских краеведов РТ Альберт Бурханов, а также аспирант Максум Акчурин, выступившие с докладами), Рязани, Москвы, историки-любители, краеведы, активисты татарских общественных организаций из Сасово, Рязани, Касимова, Темникова, Саранска, представители администрации города Сасово и Сасовского района.

Форум призвал профессиональных историков, занимающихся татарской, постзолотоордынской тематикой, вопросами вокруг этнокультурных групп Мещеры, историей тюркской знати в России, обратить внимание на несистематизированность сведений по различным этнокультурным группам татар Рязанской области и Республики Мордовия.

* * *

24 марта 2018 г. в городе Уфе прошла научно-практическая конференция «Наследие Галимджана Ибрагимова».

Конференция была посвящена к 100-летию образования Республики Башкортстан, 230-летию учреждения ЦДУМ России и приурочена к 80-летию трагической смерти Галимджана Ибрагимова.

Принимавший участие в работе конференции главный редактор журнала «Туган жир – Родной край» Д. М. Исхаков выступил с докладом «Галимҗан Ибраһимовның «Зур Башкортстан» мәсьәләсенә карашларның үзенчәлекләре».

* * *

3–5 апреля 2018 г. в городе Казани состоялся II Всероссийский форум татарских краеведов. На форуме приняли участие 374 делегатов (РТ и РФ).

К открытию форума был утвержден Устав Общества татарских краеведов РТ, а также издан первый номер журнала «Туган жир – Родной край». Собравшиеся делегаты обсудив состояние дел в татарском краеведческом движении, приняли резолюцию форума.

* * *

14 апреля 2018 г. в г. Пенза состоялось торжественное открытие офиса КПЦ им. Х. Д. Тенишевойи прошла Всероссийская научно-практическая конференция с участием более 60 известных ученых, краеведов, представителей государственных и общественных структур, религиозных мусульманских деятелей из Москвы, Казани, С.-Петербурга, Грозного, Махачкалы, Астрахани, Саранска, Пензы, районов Пензенской области и Республики Мордовия. В мероприятиях приняли участие представители Республики Татарстан: председатель Общества татарских краеведов РТ, первый зам. Председателя Совета Всероссийского общества татарских краеведов, заслуженный деятель науки РТ А. А. Бурханов, историк, специалист по истории Сурско-Пензенского региона М. М. Акчурин и старший научный сотрудник Института истории им. Ш. Марджани АН РТ, к.и.н. Б. Р. Рахимзянов.

Миссия названного центра – расширение национальных и культурных связей, формирование и укрепление национальной идентичности у татарской молодежи, содействие всестороннему культурному обогащению жителей города Пензы и региона.

* * *

18 апреля 2018 г. в столице Республики Марий-Эл в г. Йошкар-Ола прошла Межрегиональная научно-практическая конференция «История села – история России. Роль ислама в сохранении духовности татарского народа». Она проходила на базе Республиканского центра татарской культуры.

В работе конференции приняли участие более 100 ученых, краеведов, общественных и религиозных деятелей, представителей госструктур и средств массовой информации из города Йошкар-Ола и районов Республики Марий-Эл, Татарстана и Чувашии. Из заявленных 69 докладов были заслушаны 48 выступлений. Из научных центров и вузов Казани и районов РТ приехали 16 ученых, краеведов и общественных деятелей. Приняли участие представители ВКТ, в том числе Всероссийского общества краеведов в лице заместителя редактора журнала «Туган жир – Родной край», председателя Общества татарских краеведов РТ А. А. Бурханова.

По итогам конференции принята резолюция, участникам из Татарстана были объявлены благодарности Министра культуры, печати и по делам национальностей Республики Марий Эл.

* * *

19–20 апреля 2018 г. в г. Стамбуле, в Турецкой Республике состоялся форум IUluslararasi «Tüıük kültürü ve tarihi sempozyumu».

В работе конференции участвовали казанские ученые доктора исторических наук И. Л. Измайлов, Д. М. Исхаков.

Ими были прочитаны доклады: «Взгляд на проблему кимаков и татар» (Д. М. Исхаков), «Татары в древнетюркское время (V–IX вв.)» (И. Л. Измайлов).

* * *

21 апреля 2018 г. на базе Шугуровской СОШ им. В. П. Чкалова Лениногорского района РТ состоялась II региональная научно-практическая историко-краеведческая конференция учащихся имени «Памяти пяти героев-земляков». Она прошла под названием «Духовное и историческое наследие родного края».

На тему конференции откликнулось около 25 учащихся 7–11 классов города Лениногорска, Лениногорского района и некоторых сельских районов Самарской области. В день конференции Шугуровская школа радушно встретила более 20 участников-исследователей, около 20 учителей-руководителей, а также гостей конференции: председателя Общества татарских краеведов РТ, заслуженного деятеля науки РТ А. А. Бурханова, ветерана труда, председателя Совета Общества ветеранов-краеведов Н. И. Сайдашева, директора Сарабикуловской школы Лениногорского района С. А. Гатину и др.

А. А. Бурханов рассказал об итогах II Форума татарских краеведов, который состоялся в г. Казани 3–5 апреля 2018 г., а также в общих чертах подвел итоги своих научных изысканий на территории Лениногорского района в 2015 г. В заключении А. А. Бурханов от имени руководства Всемирного конгресса татар и Общества татарских краеведов РТ вручил Благодарственные письма и книги 6 учителям Лениногорского района, активно занимающимся краеведением. Книги также были вручены в библиотеку школы.

11 учащихся, представителей школ Лениногорского муниципального образования и Самарской области, награждены дипломами 1,2,3 степени. 9 человек удостоены сертификата участника. Кроме того, были награждены благодарственными письмами организаторы конференции, коллективы образовательных учреждений- участников, члены экспертных комиссий конференции объявлена благодарность научным руководителям участников.

* * *

15–18 мая 2018 г. в г. Горно-Алтайске состоялась Всероссийская научно-практическая конференция «Алтай-Западная Сибирь в XIX–в начале

XX вв: население, хозяйство, культура», посвященная известному ученому и общественному деятелю С. П. Швецову.

На конференции принимал участие главный редактор журнала «Туган жир – Родной край» Д. М. Исхаков, прочитавший доклад «Некоторые проблемы определения этнической принадлежности тюркского населения Саяно-Алтайского нагорья и прилегающих территорий Южной Сибири (по материалам переписей конца XIX–первых десятилетий XX вв.)».

Конференция прошла при участии представителей ряда тюркских народов Южной Сибири, Алтая-Саянской зоны и Казахсатна.

* * *

19 мая 2018 г. в городе Тобольске прошла II Всероссийская научно-практическая конференция «Историко-культурное наследие сибирских татар и коренных народов евразийского пространства: истоки и современность». На конференции выступил с докладом «Неизученные аспекты труда «Джамигут ат-Таварих» сибирского выходца Кадыр-Али бека из клана джалаир» главный редактор журнала «Туган жир-Родной край» Дамир Исхаков.

Параллельно проходил II Международный фестиваль-конкурс историко-культурного наследия сибирских татар и коренных народов евразийского пространства «Сузге-тора».

Учредителем и организатором фестиваля является Региональная татарская общественная организация «Наследие» по Тюменской области (автор проекта Л. А. Шамсутдинова) при соучастии Общественной палаты г. Тобольска, индивидуального предпринимателя Д. Т. Ибрагимова и при содействии:

- Всемирного конгресса татар;
- Министерства культуры Республики Татарстан;
- Депутатов Тюменской областной Думы;
- Администрации г. Тобольска;
- ЦСТК г. Тобольска.

Во II Международном фестивале историко-культурного наследия сибирских татар и коренных народов евразийского пространства «СУЗГЕ-ТОРА» принимали участие гости из Таджикистана, Луганска, Монгольской республики, Республики Казахстан, Республики Татарстан, а также из регионов и республик РФ: Тюменская, Свердловская, Омская, Курганская, Кемеровская, Новосибирская области, ХМАО, ЯНАО, Алтайский край, Республик Тыва, Хакасия, Башкортстан, а также из Горной Шории.

* * *

16–17 мая 2018 г. в городе Азнакаево Республики Татарстан состоялась Всероссийская (межрегиональная с международным участием) на-

учно-практическая, историко-краеведческая конференция «Человек и природа в бассейне р. Ик. История и современность». Она проходила в рамках II Межрегионального Сабантуя-2018 на р. Ик и Международного фестиваля тюркских народов Чатыр-тау-2018, выполнения экологических программ в Азнакаевском районе РТ и подготовки к 100-летию образования Татарской АССР (1920–2020 гг.). Организаторами выступили Азнакаевский муниципальный район РТ, Исполком Всемирного конгресса татар, «Общество татарских краеведов Республики Татарстан», а также Министерство культуры РТ, Академия наук РТ, Всероссийская общественная организация «Ассоциация татарских сел России», Всероссийское общество татарских краеведов и редакция журнала «Безнең мирас».

Были заявлены 58 докладов, заслушаны и обсуждены 52 доклада и сообщений, посвященных проблемам средневековой, новой и новейшей истории территорий бассейна реки Ик, Волго-Уральского региона и Евразии, вопросам изучения истории регионов и населенных пунктов Татарстана и татарского мира, жизни и деятельности выдающихся деятелей и уроженцев регионов бассейна р. Ик, исследованию вопросов взаимоотношений человека и природы в рассматриваемом регионе, а также проблемам музейно-краеведческой и экологической работы и преподавании учебных дисциплин.

К началу конференции был издан сборник докладов и материалов «Человек и природа в бассейне реки Ик. История и современность» (отв. ред.-сост. – А. А. Бурханов. – Казань: Отечество, 2018. 205 с. (26.7 п. л.)).

По итогам конференции была принята резолюция.

Төбәк тарихына караган хезмәтләр турында мәгълүмат. Рецензияләр.

Информация о краеведческих трудах. Рецензии

Яңа китап
«АЛАН – АЛАНЛЫКТА ТУГАН АВЫЛ»

Р. Р. Минһаҗев

Туган як, авыл тарихын яктыртуга багышланган хезмәтләр даими чыгып тора. Шулай да бу хезмәт шактый үзенчәлекле.

Китап авторы – Теләче районының Алан авылы ветераны Фәрит Даутов төп игътибарын саладагы йорт-нигезләрне теркәп-барлап калдыруга юнәлткән. Нәтиҗәдә XX гасырда һәм XXI гасыр башында (бу өч-дүрт буын дигән сүз) авылның 240 йорт-нигезендә кемнәр яшәп киткәнлеге һәм яшәп ятуы тасвирланган. Шуңа күрә бу хезмәтне Алан авылының «нигезләр тарихы» яки тарихтан сәхифәләр дип тә әйтергә мөмкин.

– Татарстан дәүләт архивында Алан авылының кайчан барлыкка килүе турында язмалар табылмады. Анда 1800 нче еллар язмалары табылды һәм алар бу китапта файдаланылды,– дип архив документларына таянганын да, авыл картлары сөйләгәннәрне дә искә төшереп язганын хәбәр итә ул. Авылдашлары хәтерендә Аланга нигез салучы Габделмәмҗәр картның шәҗәрәсе сакланып калуы – куанычлы хәл. «Бу мәгълүматлар Аланның икенче мәчетендә имам булып эшләгән, гыйлемле кеше – авыл тарихы турында бай мәгълүмат туплаган Вәлиулла хәзрәт истәлекләренә, шушы истәлекләр турында аның малае Сабирҗан бабайның атасыннан калган язмаларын күрсәтеп сөйләгәннәренә таянып язылды. Ул язмалар сары тышлы амбар кенәгәсеме, әллә саргаеп беткән язмалар тутырылган папкамы икәнен инде хәтерләмим, хәзер юкка чыккан»,– дип яза Фәрит ага.

Автор шушы хатирәләргә таянып авылның барлыкка килү тарихын ачыкларга тырышкан. Алан, Казан басып алынгач, эзәрлекләнүләрдән качып баручылар тарафыннан нигезләнгән дигән фикергә килгән ул. Бик тырышканда, Петербург, Мәскәү архивларына барып «чокчынганда», билгеле, тагын да тирәнрәк төшәргә була. Әмма монысы инде Фәрит Даутов башлаган эшне дәвам итүчеләргә кала. Һәрхәлдә, китапта узган гасырның болгавыр 1920–1930 нчы еллары, сугыш еллары шактый тулы сурәтләнгән. Гомумән, бу якты дөньяда 88 ел гомер сөргән ил агасының дәүләт яшәеше турында уйланулары, милли мәнфәгатьләрне кайгыртуы белән дә әлеге хезмәт игътибарга лаек.

Татар рухы

Татарский дух

СЕБЕР ИЛЕНӘ СӘЯХӘТ

М.Х. Сәгыйдуллина

Кырыс табигатенең үзенчәлегенә хәйран калып, матурлыгыннан хозурланып, кыргый җанварларның һәм кешеләрнең бер-берсенә булган мөнәсәбәтләреннән сокланып күренекле татар әдибе Шәйхи Маннур үзенең «Агымсуларга карап» исемле автобиографик әсәрендә себер татар авылындагы тормышны «Өркемәгән кошлар иле»дип бәян итә.

Себер татар авылындагы гади халыкның көнкүрешен, тормышын, гореф-гадәтләрен, ул елларның күренекле шәхесләрен ничек бар шулай тасвирлап һәм беренчеләрдән булып бөек татар дөньясына таныткан язучының исемен шактый еллар Тугыз авылына килеп эшләп китүе хакында телдән – телгә, буыннан-буынга күчеп хикәят ителеп килде.

Әдипнең иҗады белән якыннан таныш булган каләмдәш дусларым инде ничәмә ел әлеге себер авылларының бүгенге көнкүреше белән кызыксынып, Шәйхи Маннур эзләре буйлап сәяхәт итеп, хәтер яңарту хыялы белән янып йөрсәләр дә, фәрештәләрнең «Амин» дигән сәгате генәсукмый торды. Бу юлы Ходайга тапшырып, аларның тәвәкәллеге белән Себер буйлап гизмәгә миңа чыгарга туры килде.

Бер караганда туган якларны әйләнеп, туганнар белән күрешеп, фани дөньядан китеп барган авылдашлар, кардәшләр рухына дога кылып хәтер яңартып кайту саваплы һәм кирәкле эш булса, икенче яктан бу сәяхәт шактый уйланырга мәҗбүр итте. Такыр-токыр Себер юлларын җәяүле дә, җигүле дә урап Шәйхи Маннур тайга арасындагы авылга килеп урнашып, шушы җирлектә агарту эшләре башкарып йөргән. Тик ни кызганыч, мәҗүсилек белән ислам дине нигезләрен берләштереп, табигать кануннарына сыенып гомер иткән кардәшләренә «якты зур гүзәл дөнья»га юл күрсәтергә омтылган күренекле татар әдибен бүген искә алучы да, аның бу җирлектә яшәп, эшләп киткәнен искәртүче берни дә сакланмаган. Һич югында, уч төбе кадәр булса да такта кисәге дә язылып куелмаган. Аяныч һәм кызганыч. 95 ел буе әвеш-тәвеш килгән замана халкымның борынгыдан сакланып калган өлкәннәргә һәм укымыш-

лы әдипләргә булган ихтирамын әллә инде бөтенләй оныттырып бетергәнме? Үзенең батырлыгы, җитезлеге, үткенлеге белән дан тоткан Себер татарларына ярдәм кулы сузган кардәше исемен оныттырга нәрсә этәргеч булды икән?

Саумы, бабамнар нигезе...

Җәйрәп яткан тайга уртасында сызылып киткән кышкы юллар буйлап йөгерек юргалар алга чаптыра. Иңнәренә ап-ак җылы туннар ябынган зифа буйлы Себер агачлары юлчыларны каршы алып горур гына озатып кала. Тайгак юл өстендә шуышып барган ат чанасының зерелдәвек тавышы табигый тынлыкны бозып әледән-әле сихри көйләр тудыра. Ара-тирә ябалак-ябалак яуган ап-ак карлар бу моңлы көйгә ияреп һавада бөтерелеп бии-бии салмак кына салкын җиргә сарыла. Әлеге гүзәл һәм моңсу манзараны хозурланып күзәтә-күзәтә уйларымның чынбарлыктан ераклашканын сизми калганмым. Сырмалы-бормалы юлларга уралып туган уйлар хәтер йомгакларына ияреп тарих битләренә алып кереп киткәндәй булды...

Эх, Себер юллары! Кышкы салкын бураннарда да, язгы ташкын суларда да, гөрселдәп күк күкрәп ишеп-ишеп яуган яңгырларда да, сызгыра-сызгыра уйнаган көзге әче җилләрдә дә күпме шәхесләрне каршы алып озатып куйгансың. Күпме гасырлар юлчыларның сыкрануын, әрнүле моң-зарын, җан әрнеткеч күз яшьләрен, шатлык тулы куанычларын әле дә булса сер бирмичә саклыйсың. Кемнәр генә сине урамаган, кемнәрнең генә эзләре калмаган! Гасыр тузаңнары да, кышкы бураннар да, язгы яңгырлар да ул эзләрне каплый да, юа да алмаган. Ул эзләр мәңгелеккә кеше хәтеренә кереп сакланган. Әйе, хәтер – хәтәр әйбер. Минем күңелдә дә мәрхүм әтием зур илтифат белән сөйләгән бер истәлек хәтер-хатирә булырак саклана. Шушы хыялый хәтер җанга тынычлык бирмичә ничәмә еллар күңелне кытыклап тора...

Атларның пошырынган тавышы кинәт уйларны бүлдерде. Ачык һавада каяндыр үрмәләп килгән төтен исе сизелгәндәй булды. Офыкларга кадәр сызылып яткан юл башында авыл зиратының очы күренде. Бабамнар нигезен саклаган Тугыз авылына аяк басканчы, һәрвакыттагыча, «Лә илләһү..»не тәкрарлап, Ходайдан бу юлы да акыл зиһенлеге һәм күңел зирәклеге сорадым.

Әссәләмәгалейкүм, бабамнар нигезе! Ни хәлләрдә яшисең? Шатлык-куанычларың, борчу-кайгыларың, хәтер-хатирәләрең белән урталашыр балаларың исән-сауларммы? Ходайга шөкер итеп, үлгәннәргә дога кылып, исәннәрнең кадерен белеп кенә тормыш итәләрме?

Саумы авыл! Меңнәрчә чакрымнар узып, Идел буенда, Казансу ярында гомер итүче милләттәшләрнең кайнар сәламнәрен һәм сагыну тулы

йөрәк хисләрен күтәреп кайткан фәкыйрең – бу җирлектә ныклы тамыр җәйгән көчле нәсел агачының нәни бер үсентесе. Синдә туып үсмәсәм дә, әледән-әле синең кочакта узган шау-шулы балачак мизгелләре, бу якларда гөрләп узган бердәнбер Сабантуй бәйрәмнәре, бабамның чабышкы атлары, кичтән-кич кәртнәмнең (карт әби-пробабушка) сөйләгән серле йомаклары (әкиятләре) һәм әти-әниемнең горурланып: «Тугыз авылында Казаннан килгән иң беренче чып-чын татар язучысы избач булып эшләде» дигән истәлекләре күңел түрендә иң кадерле хатирә буларак саклана. Инде 95 елдан артык вакыт узуга карамастан әлеге татар язучысының Себер якларында эшләп киткәнен Казан онытмый. Һич югында, әллә инде үртәләп, әллә инде сагынудан юксынып, үткен каләмле якташлары да гел искә төшереп тора. Ә син аны хәтерлисеңме? Мин бит шушы избачның (ниһаять!) каләм җимеше белән танышып шаклар каттым. Сокландым һәм горурландым!

Юлдан килгән уңайга атлар туктап тормастан гадәткә кергән юлдан олы урам буйлап алга чаптырдылар. Менә агачтан мәһабәт мәдәният үзәге. Алга таба әлләни зур булмаган, әмма җыйнак кына гүзәл бакча, уртасында – һәйкәл. Бакча почмагында бик зур тирәк үсә. Авылда алар өчәү иде. Үзенә күрә сәер генә серләре дә бар ул агачларның, шунлыктан, без, бала-чагалар тирәкләр янына якынлашудан да өркеп тора идек. Хәзер исә берсе генә моңаеп басып тора. Кайчан, кем тарафыннан утыртылган, белгән кеше юк. Алда иркен җәелеп яткан мәйдан – Цагыт. Заманында гөрләп торды бу мәйдан: авыл егетләрен армия сафларына озатып каршу алу дисеңме, сабан туе бәйрәмнәре һ. б. һ. б. Хәзер дә авыл халкының елына бер тапкыр булса ерактан кайткан туганнар, балалар белән җыйналышып сабантуйларын алыштырган «Авыл көне» бәйрәмендә күңел ача торган урын. Кайчандыр әле телгә алган урында Олыавыл булган. Шәйхи Маннур үзе килеп шунда урнашып, агарту эшләрен башкарып йөргән. Тугыз авылы ул чакта берничә кечкенә бистәне берләштереп торды: Игавыл (Җүкавыл), Олыавыл, Аръяк.

Ниһаять, кайтып та җиттек. Зур чана шәлен алыштырган җылы юрган эченнән чыгуга, авыз тутырып Себернең саф һавасын суладым. Юл газабыннан арып оеп каткан тәнгә җан кердемени? Ялт-йолт булып җемелдәп торган ап-ак кардан күзләр камашып, башлар әйләнеп киткәндәй булды. Кышкы авыл үзенә генә хас сокландыргыч матурлык белән һаман бар игътибарны тартып торса да, моңсу кебек тоелды. Кар сырындыларына күмелеп калган йортлары да күзләрен майландырып нәрсәдер өмет итеп баккан шәһәр сәрхүшен хәтерләтә. Мин бәләкәй чакта сагынып ашкынып кунакка кайткан шау-гөр килгән бала-чагалар белән тулы урамнар та тып-тын. Сәвәл вакытында тәрәз артыннан күзләрен офыкка

терәп торучы әби-бабайлар да күренми. Авыл буйлап арлы-бирле йөрүче явыз күренгән сукбайлар да танауларын өскә чөереп, иснәнергә дә иренеп, койрыкларын селки-селки каядыр китеп юлыгалар. Хәтта, тәүлекнең теләсә кайсы вакытында борыннарны кытыкландырып, авызга тәмле сулар китереп урам миченнән аңкыган көлдә пешкән ипи яки шеш балык (ипи мичендә кибеп пешекән табан балыгы), кайнап торган майда кыздырылган табикмәкнең хуш исләре тә калмаган. Юкса бит болар гомер-гомергә авылның әйтеп бетергесез күренми торган үзенчәлекле бизәге булып торды.

Һаваның сафлыгын томаларга тырышкандай моржалардан агылган төтен әчкелдем исләр аңкытып биеккә үрмәләп маташа. Зәңгәрсу төтенне җимертә-җимертә офыктан шәфәкъ нурлары сибелеп, актан киенгән авыл урамнарын бер мәлгә әлҗе-мөлҗе китерде. Кинәт сискәнеп киткәндәй булдым. Их! Онытылган бит, «сәвәл вакытында урамда калырга ярамый»,– дип киңәш итә иде Себер аксакаллары. Күрәсең нәсел нигезен сагыну хисләре өстенлек алганга, ә бәлкем чирек гасыр бу җирлектән аерылып читтә яшәгәнгә күрә, туган туфрак гадәтләре хәтердән уела башлаган. Нишләтәсең, тормыш агышына замана үз таләпләрен кертә. Ә без исә шушы агымнан калышмаска тырышып, бар дөньябызны онытып, ашкынып чабучы замана коллары. Хәерлегә булсын, Ходаем, үзең кичер безнең ялгышларны...

Узганнарны барлап...

Кыргый җанварлар өязе һәм богаулар чыңлавы яңгыраган каторжаннар иле буларак таныш Себер җирен илдә узган замана шаукымнары да читләтеп үтмәде. Аклар белән кызылларның көрәше, ярлы халыкның сәнәк күтәрелеше, артель-колхозлар оешуы, сугыш чоры михнәтләре һ. б. Санап китсәң хәтер йомгакларын җыярга капчыгың да җитмәс. Себер татарлары боларның һәркайсына зур өметләр баглап, киләчәкнең якты булачагына ихластан ышанып, бар көчен кызганмыйча тир түкте, җиң сызганып көрәште, тешен кысып булса да тормышка зарланмыйча, уфтанмыйча тын гына яшәргә тырышты. Ятим калган нәни милләттәшләрен дә онытмады. Махсус ятимнәр йорты оештырып, һәркайсы хәленнән килгәнчә ярдәм итәргә омтылды. Чөнки җирдә кылынган һәр изге гамәл кешегә икеләтә әйләнеп кайтачагын аңлаган кеше күңел түрендә моны олы бер терәк буларак саклый иде. Моннан тыш, халыкның бердәнбер яклаучысы, туендыручысы, кочагына сыендыручысы – Табигать ана һәрчак якында икәнен сискәндереп торды. Бәлкем шуңа күрәдер, катлаулы авыр елларда да себер халкы чыдамлы булды, сыгылып төшмәде: басуда иген сөрде, кырда печән чапты, чатырманлы куе кара тайгада кыргый җанварлар аулады, урман кисте, сумала агызды, төпсез сазлыкларда җиләкләр

җыйды, балык тотты. Ә кичләрен учак, соңгарак «пүзир» (кәрәсин) лампа яктысында кул эшләре белән шөгыльләнде. Үзе дә сөрген җире булуга карамастан күпме тентүләр, югалтулар кичерде.

Дөньялар тынычланып, сәясәтләр тотрыкланып, инде коммунизмга таба юл алганда, барлык хыяллар чәлперәмә килде. Бөек илләрдән саналган Совет иле таркалып, халык берникадәр вакыт бушлыкта яшәде. Күндәм булган себер татарлары барысына түзде һәм, Ходайга шөкер, 70 ел буена халыкны калыпта тоткан социализм богауларыннан котылып бәйсезлек алды.

Бу гамәлләрнең барысы да узып барышлый гына булган кебек күптән инде аттта калды. Ә алда... Алда – яңа тормыш көтә кебек иде...

Заман җиле бил бөктерә, тир түктерә...

Яңа тормыш дигәне дә халык яшәешенә әлләни яңалыклар кертмәсә дә, күзләрне берникадәр дәрәҗәдә ачты. Халык хәзер фәкать үзе һәм үз гаиләсе өчен бил бөгә, тырышып тир түгә. Кем күпме булдыра, шул кадәрле үз шәхси казнасын баета, ягъни эшләвеңә карап кесәсен калынайта. Моннан тыш ул «хуҗа» булуның да тәмен татып өлгерде. Әлбәттә, җиргә, урман-су байлыкларына хуҗа булып эш йөртү җиңел түгел. Шулай да, халык үзенчә, үз көенчә бәйсез, әмма яхшы тормышка талпынды. Мондый гамәл көтелмәгән күренеш булса да, халык аңа тиз арада яраклашты. Совхозлар таркалып, эш урыннарны бетерелгәч, бары тик дәүләт кочагында яшәргә күнеккән шәхесләр өчен яңа тормыш «кыргый» кебек сизелде.

Әкренләп үз җае белән авыллардагы күренешләр үзгәрә торды: урамнарда шәхси җиңел машиналар ишәйде, аннары йөк машиналары, соңга таба тракторлар да барлыкка килде. Хәзер инде интегеп печән да чабасы юк; трактор үзе чаба, үзе җыя, үзе төяп тә куя. Хатын-кызлар тормышы да җиңеләя: заманча техника хуҗалыкта кул эшләрен алыштыра башлады, матур затлы йомшак җиһазлар, шөкер барысы да бар. Хәтта, төргәк тотып күрше-күләнгә йөрү дә юк. Заманча хәл белешәләр – компьютер артында яки кәрәзле телефон аша гына.

Гүзәл көзге артынданиләр бар?

Әйе, бер караганда, саф һавасы бөркеп торган табигать кочагында урнашкан себер татар авылларында милләттәшләребезгә шөкер итеп, рәхәтләнеп яшисе генә кала. Тик бу беренче карашка матур һәм рәхәт итеп күренгән гүзәл тормыш көзгесе артында ни тора? Чыннан да себер татарлары тормышы көнләшерлекме, әллә киресенчә аянычмы?

Себер татарлары – «татар» дигән бөек милләтнең бер кыйпылчыгын тәшкил итсә дә, халык язмышы беркемне дә кызыксындырмады. Мондагы җирле халык ничек көн күрә, белеме, мәдәнияты, милли үзаңы ни

дәрәҗәдә? Бу сораулар бүгенге көнгә кадәр һавада эленеп тора. Ә халык исә үзен борчыган барлык мәсьәләләрен аркасына асылындырып дәшмичә алга омтыла.

Күпме тырышса да артык алга китеп булмас, чөнки бу якларда юллар бик начар. Һәръяклап Рәсәй алга киткән илләрдән саналса да, Себер төбәкләрендәге юлларга кайчан цивилизация килеп җитешер, әйтүе бик авыр. Себер авыллары асфальтның нәрсә икәнен белми һәм кайчан беләчәге дә билгесез. Ярый ла кайбер авылларга балчык өстенә шебенка түшәп юлларны үзләренчә заманлаштырдылар. Яңгарлар яуса, буран котырса авылларга барып җитү хакында сүз буларга да мөмкин түгел. Яз-көз айларында авыллар резервация ролен үти дисәм, якташлар шәт үпкәләмәсләр. Чөнки, район үзәгенә кадәр җитеп тә, авылга кайталмыйча кире китән чаклар булгалады.

Җирле халыкны борчыган тагын бер мөһим мәсьәлә – ягулык. Себер нефть һәм газ иле буларак дөньяга танылуга карамастан, татар авылларына газ кермәгән, әле дә булса йортларны утын ягып җылыталар. Утынны да элекке вакытлардагы кебек кайчан һәм ничек телим, шулай җитештерәм ысулы күптән бетте. Хәзер утын әзерләү өчен дә бюрократ системасы аша узарга кирәк. Башта делянка сатып аласың, аннан соң гына агачларны кисеп утын әзерли башлыйсың. Кыш көннәрен катып утырасың килмәсә бер ел алдан чарасын күрү мәслихәт, яки кесә калынлыгы тиешле дәрәҗәдә булу зарури.

Соңгы вакытларда инвесторлар кертәбез дигән булып яисә тагын башка сәбәпләр табып, әкренләп җирләргә, күлләргә хуҗалар табылуы себер татарларын борчуга сала башлады. Урманнар да ияле булса, халык ничек туеныр, ничек гомер кичерер? Урман-күлләргә барып җиләк-җимеш җыю, җәнлекләр аулау, балык тоту кебек кәсебләре себер халкының акча эшләү ысулы гына түгел, ә ата-бабалардан мирас булып калган яшәү рәвеше дә бит әле. Ярый ла халыкның хәлен аңлап ярдәмгә килә торган милләттәшебез хуҗа булса. Күлләрне, җирләрне сатканда әлеге җирлектә нинди халык яшәвенә, милли үзенчәлеккә, үзләштерүченең нинди милләт булуына карап тормыйлар. Хуҗаның да төрлесе була, хирыс холыклы туры килсә әле бөтенләй урман байлыкларыннан кул юмагае. Табигать байлыкларын кулдан ычкындыру җирле халык өчен котычкыч булуы мөмкин. Тик бу мәсьәләгә төпләп караган кеше күренми.

Себер татарларының киләчәге хакында уйланучылар бар микән? Дүрт-биш елга бер, сайлаулар алдыннан гына мондагы халыкны искә алалар, чөнки халык тавышы кемнәргәдер депутатлыкка узар өчен сан буларак кирәк. Менә шул вакытта гына газиз якташларым үзләрен иң кирәк кеше итеп тоялар. Юклы-барлы татар җырчыларын ияртеп өлкә

хакимияте һәм татар җәмәгатьчелеге вәкилләре килеп күренеп, халыкның моң-зарын мыек очларына чормап, тау биеклегендәге вәгъдәләр биреп китәләр дә шуның белән тагын берничә елга югалып торалар. Халык модый күренешләргә күптән күнекте, хәзер инде артык исе китми, кайвакытларда җыелышларга йөрүне кирәк дип тә тапмый. Шунысы кызганыч, милли сәяси вәзгыятьнең кыйбласы кайсы тарафка юнәлә, шуны аңлатып, халыкны үз артыннан ияртүче юк. Үз чиратында «Яңарыш» газетасы татарлар тормышындагы яңалыкларны, төрле кызыклы вакыйгаларны яктыртып бара. Газетаны да укучылар саны мактанырлык түгел. Өлкәдәге 300 меңнән артык татарның ни бары берничә меңе генә газетаны укый. Болары да өлкә буын вәкилләре дип беләм, яңа буын газета укуны кирәк дип санамый, чөнки хәзер интернет заманы.

Халыкны интектергән социаль мәсьәләләр белән беррәттән башка төрле юнәлештәне сораулар да күз уңыннан югалмый һаман калкып тора. Бу очракта милли мәгарифнең ни хәлдә булуына күз салмасак хилафлык булыр сыман. Туган телдә тулаем белем алу бу якларда хыял гына. Шунысына шөкер итәбез, мәктәпләрдә фән буларак татар теле һәм әдәбият дәресләре укытыла. Форсаттан файдаланып, мин татар теле укытучыларына олы рәхмәтләремне белдерәсем килә. Чөнки, себерләтеп әйткәндә, «гүр заманында» нәшер ителгән, инде әллә кайчан кулланудан чыккан элеккеге татар теле дәреслекләре белән балаларны укытып, аларны башта өлкәдә, аннан соң Казанда уздырылган олимпиадаларда катнаштырып, елдалык дөньякүләм аренада татар телен белү буенча көч сынашалар. Яңа дәреслекләр, яңа программалар белән укыган балалар нинди булырлар икән? Шушы укучылар чып-чын татар язучының нинди икәнлеген күз алдына да китерә алмый торгандыр, чөнки Себернең тайга арасында сазлыклар урнашкан авылларга аларның беркайчан да барганы да, күренгәне дә булмады, гәрчә анда татарлар күпләп яшәсә дә. Экспедициягә дип килгән кайбер галимнәр дә Төмән арты авылларында гына йөреп кайтып китергә күнеккәннәр. Сазлыклар арасында урнашкан авылларга газапланып кем барып йөрсен? Авылдагы китапханәдәге татар китаплары мин мәктәптә укыган чактан калган. Ә мәктәпне бетергәнгә дә быел 30 ел булачак. Берничә ел элек «Яшь буын» Төмән өлкә татар яшьләре иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Фәрит Корманов Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министрлыгы ярдәмендә 3200 данә татар теле һәм әдәбияты дәреслекләрен алып кайтып таратты. Кайбер мәктәпләрдә исә ярты гасыр элек чыккан дәреслекләр, нәфис әдәбият китаплары кулланылган. Шунысы кызык тоелды, өлкәдә татар теле укытучылары, милли мәктәпләр белән эшләүче әллә нинди фәнни үзәкләр, институтлар бар иде. Аларда дистәләгән себер татар галимнәре

эшләде. Тик ник берсе мәктәпләргә яңа заманча программалар нигезендә басылып чыккан дәреслекләрне кайтарту турында кайгыртмады икән? Юкса бит Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министрлыгы инде ничәмә еллар төбәкләрдәге төрле җәмәгатьчелек оешмалары, милли-мәдәни мохтариятләр белән берлектә бу мәсьәләне хәл итү максатыннан даими хезмәттәшлек алып бара.

Соңгы елларны күзәтсәк, Төмән өлкәсе татарлары мәгариф өлкәсендә зур югалту кичерде: Төмән дәүләт университеты һәм Тубыл дәүләт педагогия институты каршында эшләп килүче татар теле укытучыларын әзерләүче бүлекләр ябылды. Бер төркем югары белемле, тәҗрибәле галимнәр урамда эшсез калды. Себернең иң зур төбәкләренең берсе ана телендә белем бирүче укытучыларны әзерләүдән мәхрүм булды. Димәк, берникадәр вакыт узу белән белгечләрнең бөтенләй булмавы да ихтимал. Казанга яки Уфага барып белем алырга теләүчеләр булуы икеле. Бу исә җирле татарларның милли мәгарифе таудан упкынга тәгәрәп баруын аңлата түгелме? Упкынга эләгүдән аны кем йолкып калыр?

2016 елда татар авылларындагы милли мәктәпләрнең юридик хокукларын бетерү өлкәсендә эш алып барылды. Ягъни авылларда мәктәпләр бар, әмма бернинди хокуксыз һәм исемсез. Алар исә чынлыкта рус мәктәбе булып йөртелә. Хәттә, мин үзем белем алган 90 елдан артык тарихлы татар мәктәбен 8 нче төрдәге рус коррекцион мәктәбе белән берләштерелде. Юридик хокуклы районда бер генә дә татар мәктәбе калмады. Өлкәдәге бернинди татар оешмасы да, татар җәмәгатьчелеге дә бу адымга каршы чыкмады, үз фикерен белдермәде. Әйтерсең лә ул шулай булырга тиеш иде.

Мәдәният өлкәсендә дә әллә ни алга китеш юк. Бүгенге көндә дә авыл саен җыр – биюгә сәләтле егетләребез, кызларыбыз шактый. Әмма, аларны туплап, әз-маз өйрәтеп, юнәлтеп җибәрүче профессиональ белгечләр юк дәрәҗәдә. Шуны да әйтергә кирәк, Себер татарлары үзенчәлекле фольклорга бик бай. Тик алар белән кызыксынучы һәм өйрәнүче дә юк диярлек була. Билгеле, «Түгәрәк уен» фольклор фестивале уздырыла башлагач, өлкәдә берникадәр хәрәкәтләнү күзәтелә башлады. Авылның тынгы белмәс үзешчәннәре үзләренчә тырышып-тырмашып җирле милли гадәтләрне саклап калырга омтылалар. Бу очракта Тугыз авылы үзешчәннәре турында берничә сүз әйтеп кимичә булмас. Үз тырышлыклары белән алар өлкә дәрәҗәсендә берникадәр күтәрелә алдылар. Бу авылдагы халык сәләтле, мәдәниятка гашыйк һәм бик һәвәс. Кирәк вакытта оешып, авылның данын яклар өчен барысына да әзер торалар. Күршедәш Казанлы авылы да калышмый иде. Заманында моңлы җырчылары, гармунчылары, биючеләре үз чыгышлары белән һәр чарага ямь өстәп, өшегән җаннарны

җылытып, сусауны баса иде. Әле хәтеремдә, берара Казанлы авылында халык уен кораллары ансамбле дә бар иде.

Әлеге авыллардагы тамашачы аеруча биючеләрне күтеп ала. Бу якларда «барабан суктырып» биюе гадәткә кергән. «Барабан суктыра» белмәсәң, ничек кенә яхшы биемә, син биюче түгел! Биючеләр ашыкмыйча аяк белән барабан суктыра-суктыра түгәрәк буйлап әйләнеп бии. Авылның биюче осталары бар иде. Хәтта ат чабышларын хәтерләтеп биләр иде. Биючеләргә килгәндә, алар һәр бәйрәмнең күрке булып торды. Туйлар беркайчан да мондый биючеләрдән башка узмады. Осталар өчен һәрзаман махсус бүләкләр әзерләнеп куелды.

Әлбәттә, берни эшләнми дип әйтерлек түгел. Хәрәкәт бар, тик нәтиҗәсе генә юк. Авыл халкын да аңларга була, ул иярүче генә. Кем арбасына утырсаң шуның җырын җырлыйсың, утыртучысы булмаса каңгырып тик йөрисең. Адашып кына калмаска яки башка чит-ят арбага атланып киттүдән Ходай сакласын!

Чәлперәмә килгән хыяллар...

Сүз арты сүз йөгерә, фикер арты фикер туа. Яза башлагач эчтә җыелган уй-фикерләрне бушатасы, чишелеш юлларының табыласына ышанасы һәм мәсьәләләрнең барлыгын ишеттерәсе килә! Себердә алар җитәрлек, ерак китәсе түгел. Берничә генә мисал китереп китәм.

Моннан 15 еллар элек Төмән шәһәрендә Татар мәдәният үзәге ачылгач, шатлыгыбыз эчкә сыймады. Ниһаять, сәләтле себерлеләр тупланачак. Шәһәр һәвәскәрләре тупланып, авыл үзешчәннәрен җыеп тәҗрибә уртаклашыр, Казанга кадәр моңнары ишетелер әле дигән хыяллар әлегә кадәр һавада эленеп тора. Куанулар артык булган күрәсең. Ярыйсы гына эшен башлап киткән, Себер татарларының сәнгать филармониясенә әйләнергә базасы булган үзәк һаман бер урында таптана. Берләшү, туплану, үсү дигән уй-фикерләр бөтенләй телгә дә алынмый. Менә дигән коллективларыбыз урамда чәчелеп калды. Авылларда күмпе сәләтле, җырга-моңга гашыйк яшьләребез тилмерә? Әкренләп борынгыдан калган гореф-гадәтләребез югала бара. Сөннәт туйлары, кышкы ат чабышлары барысы да еракта онытылып калды. Хәттә, моңарчы халык йоласыннан саналган урманга, суга, җиргә карата булган табынулар да онытылды. Ә бит болар халыкның яшәү рәвешен тәшкил итүче күрсәткечләр.

Төмәндә себер һәм өлкә татарларын берләштерүче мохтарият оешкан иде. Җитәкчелек кәнәфисенә дәгъва итүчеләр арасында иҗтимагый хәрәкәттә шактый «аунатылып» тәҗрибә туплаган затлар булуга карамастан, рульне халык белеп бетермәгән «зур урында» утыручы нәчәльниккә тапшырдылар. Ходайга шөкер, әзмәвердәй таза гәүдәле, чәчрәп тора, димәк шәп ашый. Себердә бит, «ашаган малда-өмет бар»,–

диләр. Халык та зурдан өметләр баглап ризалашты. Себер татарлары мәсьәләләрен дә чишәрләр, заманча юллар төзелер, авылларга газ кертелер, мәктәпләр терләкләндерелеп туган телдә белем алу мөмкинлеге туар, югалып барган татар авылларына да җан керер, бәлкем, сәнгатебез үсеп китәр дигән теләктә булды халык. Шәһәрләрдәге, районнардагы, өлкәдәге барлык татарларны берләштереп бердәм милләт буларак күтәреләчәкбез дип гөрләде җәмәгатьчелек. Бер катлы да инде безнең халык. Акча артыннан чапкан, байлык колы булган нәчәльниккә ниемә кирәк синең милләт мәсьәләләре. Аларның үз кайгылары – кайгы, милләтне гади халык кайгыртсын... Кызганыч. Өметләр акланмады, хыяллар кабат чәлперәмә килде.

Моннан берничә еллар элек Төмәндә икенче – бу юлы бары тик Себер татарлары мохтарияте оешты. Якташларым, белүемчә, кабат зур өметләр баглап, ышаныч белән карарга тырышты әлеге оешмага. Тик эшләренең алга китүе сизелми. Шәһәр мохите өчен нәрсәдер оештыралар, үзара кайнашалар. Әмма, чып-чын себер татарлары яшәгән районнардагы авылларга игътибар элеккечә юк. Әй, Раббым! Әллә инде болары да үзләренең эчке ихтыяҗларын гына кайгыртыр өчен генә оешты микән? Берүк өметләрне өзми тор! Туган телдән бизмичә, онытмыйча яшәргә насыйп ит милләттәшләребезгә.

Шуны да искәртеп үтәргә кирәктер. 2015 елның август аенда Тубыл шәһәрендә «Искер-җыен» дип исемләнгән себер татарларының тарихи-мәдәни мирасы халыкара фестивале кысаларында уздырылган «Искернең тарихи язмышы» исемле фәнни-гамәли конференция карарында себер татарларының телен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен өйрәнүче үзәк булдыру турында аерым пункт кертелде. Билгеле, мондый үзәкне булдыру өчен шактый чыгымнар сорала. Үзәкне булдыру өчен ярдәм сорап Себер татарлары мохтарияте Төмән өлкә хакимиятенә, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетына мөрәҗәгать белән чыкты. Әмма җавап бирүче генә булмады. Аның каравы моны ишетеп алган башкорт галимнәре ярдәм итәргә әзер икәнлекләрен белдерде. Алар исә Төмәндә Башкортстан фәннәр академиясенең филиалын ачырга тәкъдим ясады. Сәяси дулкында кайнаучылар чамалый торгандыр агымның кая таба баруын. Себер халкы ышанучан, бу адымга ризалашып ялгышмасылармы икән дигән шик-шөбһә бар иде. Ходайга шөкер, монысы да «юлчы» кебек узып китте.

Халыкны милләт буларак аның теле саклап кала. Халыкта үзаңлылык булмаса ул югалуга дучар. Күргәнебезчә, хәзерге вакытта себер татарлары авылларында гомер кичерүче халык аңында социаль мәсьәләләр өстенлек ала. Бу мәсьәләләр милли үзаңны икенче планга күчерә. Халык

өчен кәгазьгә үзен кем дип язсалар да барыбер: аның бүген бар теләге – сау-сәламәт, югалтуларсыз, тук көе тормыш алып бару.

Соңгы сүз...

Әйе, хәтер яңартып, якташлар, туганнар белән күрешеп, гапләшеп, фикер алышып йөри торгач атна вакыт узганы сизелми да калды. Урамда кар тузгытып уйнаган тайга җиленең сызгыруы җыенырга ишарә ясый кебек. Озакларга ярамый, Казанда ашкынып Себердән яңалыклар көтәләр. Тик нигәдер ашкынулы, ярсу күңел бик боек һәм моңсу. Шушы көннәрдә шактый гына сагыну-сагыш тулы хатирәләрне искә алып, бер-бер артлы кичерергә туры килде. Һәрвакыт ымсынып искә алырлык балачактан калган самими бер күренеш иң истәлекле мизгел буларак җанда уелып калды.

Без биш бала, өй алды баскычында тезелешеп, бер сәгать буе түземсезлек белән мичтән пешеп чыккан ипине көтеп утырабыз. Хуш исләре әллә кайчан тирә-юньгә таралды. Ашыкмыйча гына әни мичтән ипиләрне чыгара, ак май белән өсләрен майлый да бер мәлгә махсус сөлге белән каплап тора. Әнинең өйгә кереп китүе була, без, балалар, бер ипине кулга төшереп, кем ничек булдыра шулай сындырып каймакка манып, баздан чыккан салкын сөтне эчә-эчә, тәмләп-тәмләп туйганчы ашыйбыз. Бүгенге авыл өчен моны раритет күренеш дип атарга була. Ипи пешерә торгаен урам мичләре авылларда санаулы гына. Һәркемнең өендә газ плитасы басып тора, ипи кибеттә сатыла. Ирттә таңнан торып, йокы калдырып җиң сызганып беләкләрне талдырып камыр әзерлисе түгел. Менә шулай заманча рәхәт тормыш гаилә үзенчәлекләреннән, халык йолаларыннан, канга сеңгән яшәү рәвешеннән әкренләп читләштерә. Бер рәхәтнең бер михнәте була дип тиккә әйтмәгәннәрдер.

Их, каһәр суккан замана! Тәки авызын ыржайтып әкренләп барысын да йота бара бит. Ә халык бар дөньясына төкерә-төкерә тормыш нуҗасы арбасын тарта. Шәйхи Маннурны искә алырга вакыт юк әле....

ГОГОМАГОГИ: ТАТАРСКИЙ ГЕШТАЛЬТ И БОРЬБА ПОЛОВ

Р. В. Айсин

Безумный профессор филологии и русский классик о женщине

Без преувеличения, большой писатель – Максим Горький, сказал: «Мерило всякой цивилизации – способ отношения к женщине». Тезис интересный, ибо он обозначает, что мужчина – все же тот, от кого идет отсчет и «снимаются мерки». Мужчина первичен – женщина его производная. Или, как говорят, «спутница жизни». Тут же мимоходом заметим, что Горький был ницшеанцем, ратовал за сверхчеловека, большевики в этом смысле идеологически стояли к нему близко (или он к ним – вопрос дискуссионный) и полагали, что «ветхого человека» надо немедленного менять на нового. Горький был исполинской силы человек и громадного таланта, любимец женщин. Чего не скажешь о его кумире Ницше, подражая которому Максим Пешков отрастил пышные усы, ставшие его символом, или, как сегодня говорят,– фишкой.

Безумному профессору филологии, ставшему одним из последних интеллектуальных бунтарей ушедшего с ним XIX в. (напомним, что умер Ницше в 1900 г.), принадлежит ряд известных высказываний о женщинах. Хотя сам он имел неудачный опыт отношений с прекрасной половиной человечества, котороеон считал «иссохшим и потускневшим». «Мужчина создан для войны – а женщина для его отдохновения»: «Идёшь к женщине – бери с собой плеть» и т. д.

«Какое дело женщине до истины! Ее великое искусство есть ложь. Ее главная забота – иллюзия и красота»,– изрек гений Ницше. «От женщины, как и от судьбы, никуда не уйдешь»,– как бы парировал ему Горький.

Действительно, от женщины не уйдёшь, как и от её иллюзий и ее чарующей красоты. Но, как говорил тот же Ницше (да простит читатель за обильное его цитирование): не бывает прекрасной поверхности без ужасной глубины…

Женщина – это колоссальная бездна вопроса. Глубина, которая измеряется падением в неё мужчины.

Женское – повсеместно. Оно не только проявляется как физиологический аспект – антипод мужчины. Эзотерики говорили об андрогинности человека, то есть о наличии женского и мужского в каждом наследнике Адама. У каждого мужчины имеется «скрытая женщина», физический образ которой ищет подлинный мужчина.

То древность, скажут, а сейчас XXI в. – эмансипация, феминизм, «равенство полов», в конце концов! Но проблема в том, что это не снимает принципиального вопроса об извечных борьбе/притяжении мужчины и женщины.

«Зулейха всегда была с открытыми очами»

А что в этом вопросе у татар? Здесь есть где развернуться исследователю. Простор широтой в степь! Не будем повторять замызганные клише о том, что раньше у женщин прав не было, сейчас же – гармония, чуть ли не унисекс, то есть полное смешение половой дифференциации.

Глобализация – это настоящий каток, она уничтожает этнические различия, языки, моральные ценности, убивает женственность и мужские принципы, она смешивает всех в один пластилиновый комок и лепит что-то отвратительное, нечеловеческое. Ницше призывал человека преодолевать, но постсовременность, в которой мы живём, так и не смогла его преодолеть и возвыситься – она пошла путём деградации и сползла в историческую канаву.

Патриархальность – уже ругательство, призыв возвратиться к аутентичному – обвинение в мракобесии. Многие понимают возврат к истокам в прямом смысле: надеть читек, татарскую рубаху и ходить по улицам, напевая татарские мотивы. Это не так, ибо возврат к духовным истокам, прежде всего к национально-мусульманскому гештальту, а не карнавально-шутовское подражание симулякрам и химерам, вот что нужно.

Берусь утверждать, что не была татарская женщина закабалена. Не была она несчастна, как это утверждали учебники истории советского периода. «Зулейха всегда была с открытыми очами», как бы там кто-то ни писал. Пример наших бабушек, которые понимали жизнь и счастье несколько иначе – тому яркий образчик. Они не занимались разъедающей рефлексией на тему «что есть счастье?», они жили согласно религиозным канонам, смотрели на трудности как на неизбежность и были благодарны Всевышнему за всё.

Но таких людей уже больше не куёт «матушка-природа». Увы, увы.

Женщине не надо было (да и не нужно!) доминировать явно. Она берёт женской мудростью. Мудрость она женского рода. Когда же женской «мудростью» овладевает мужчина, тогда происходит смешение семантических полюсов внутри него самого. И получается то, что называется «мудрость мира сего – есть безумие пред Господом». А это и есть начальное смешение. Дальше смешение переходит на внешний план, женщина начинает овладевать мужскими качествами, навыками, профессиями даже штанами, и, наконец, – его экзистенцией.

Такую перверсию средневековые мыслители считали демоническим влиянием. Вряд ли случайно, что разговоры о средневековье, религии и морали вводят современных «женщино-мужчин» в судорожное неистовство горечи и смеха одновременно.

Татары – народ воинов и подлинных женщин, отступают перед натиском «современного Джаггернаута». Татарская традиционная семья еще недавно стояла на страже настоящих ценностей,именно она сохраняла архетипическую матрицу народа,женщина была женщиной, мужчина – мужчиной. Сейчас же поди разбери, кто есть ху!

Семья – это всегда договор между мужчиной и женщиной. Только в семье «война полов» снижает свои обороты и зачехляет пушки.Но теперь – это проходной двор, семья уже не крепость, не заводь, где муж и жена находили покой и уединение от несмолкаемой канонады общественного безумия. Теперь семья стала «стеклянным домом», куда каждый норовит сунуть свой нос: от социальных работников до СМИ и соседей, банально полагающих, что «открытое общество» – это когда нет приватной тайны личности.

Мужской полюс сместился

